www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 24 (1389) 24 июнь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



5

Г. Кариев театры премьерасы – “Йосыф” спектаклендә режиссер Ренат Әюпов милли җанлы иҗат иясе икәнен тагын бер кат раслады.

12

К.Тинчурин театрының тамашачыга тугры мөхтәрәм актрисасы, туры сүзле Әлфия Хәсәнова сәхнәгә буш сүз, бозыклык менүгә борчыла.

14

Үз илен шул чорның алдынгы дәүләтенә әйләндергән, Европаны яулаган Наполеонның гомер көзе дә бик гыйбрәтле.

Шыпырт кына таң капкасын ачып, Көнгә кереп килә бар җиһан!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия Президенты Владимир Путин июньнең соңгы якшәмбесендә Халык сәнгате һөнәрләре көнен билгеләп үтү турында боерыкны имзалады.
- Ульяновскида узган Федераль сабан туе мәйданында «Татмедиа»да чыга торган газета-журналлар, открыткалар тәкъдим ителде.
- «Смешарики» мультсериалының «Күчтәнәч» дип аталган яңа сериясе татарлар һәм аларның милли татлы ризыклары белән таныштыра.
- «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» республика конкурсында җиңгән ун мәктәпкәчә белем бирү оешмасына 500 мең сум күләмендә грант бирелде.
- РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тарафыннан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан махсус әзерләнгән затлы Коръән басылып чыкты.
- Казанның Дәрвишләр бистәсендә, Сәетгалиев исемендәге мәдәният йорты паркында ачык һавада кино күрсәтелә башлады.
- Татарстан Республикасы Аксакаллар шурасы Җәмигъ мәчетенә Олуг Мөхәммәт хан исемен бирүне яклап Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать юллаган.
- «Алтын каләм – Золотое перо» республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивалендә 170 журналист катнаша.
- К.Тинчурин театры балалар өчен «Тукай эзләреннән» дип аталган квест башлап җибәрде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Луиза ЯНСУАР, Кариев театры директоры:

«Милли классиканы сәхнәгә яңача караш, яңача тоемлау белән чыгарасы килә. Икенче мәсьәлә килеп баса – кайда ул яшь режиссерлар? Үзебезнең милли җирлектә үсеп чыккан, үзебезнең ракурстан күрә торган режиссерлар кирәк. Чакырылган режиссерлар да милли контекстны өйрәнергә, безнең атмосфераны тоярга тиеш була. Кыскасы, үзебезнең авторларны һәм режиссерларны үстерергә кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

26 июньдә кыяр чәчәргә ярамый, уңмаячак ● 29 июньнән күке белән сандугачтан кала барлык кош сайраудан туктый ● Бал кортлары дәррәү умарталарына таба очса, яңгыр ява ● Кырмыскалар ояларына кереп качса, көчле җил һәм яшенле яңгыр көтелә ● Урман җилсез шауласа – яңгырга.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **2 сәгать 59 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 32 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 33 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **5 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **1 июльдә 17 сәгать 28 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

26 июнь – техник фәннәр докторы, профессор, Татарстанның атказанган уйлап табучысы Әнәс Хафиз улы Җомагыйловка 85 яшь (1937).

27 июнь – язучы, тарихчы Газиз Салих улы Гобәйдуллинның тууына 132 ел (1887–1938).

28 июнь – фольклорчы-галим, «Манас» кыргыз халык эпосын язып алучы һәм өйрәнүче Каюм Гайнан улы Мифтаховның тууына 120 ел (1892-1948);

– шагыйрь, филология фәннәре докторы, җәмәгать эшлеклесе Әмир Гобәй улы Мәхмүдовның тууына 75 ел (1947–2018).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(21-29 июнь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә** кадәр йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 25 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Индус ТАҺИРОВ, академик

БЕЗ – чигенмәс халык

Татар бөгелеп, тезләнеп яши торган халык түгел, ул горур. Ул биш гасыр буе яшәү көчен саклый һәм ныклыгын раслый белде. Аның бүгенге теленә карата туктаусыз дәвам иткән һөҗүмнәргә дә җавабы шундый ук. Ул мәктәп программасында үз телен юк дәрәҗәсендә калдыруга җавап итеп, аны балаларына факультатив рәвештә һәм төрле курсларда өйрәтүен камилләштерү эшен җәелдерде. Казанда һәм Ульяновск өлкәсендәге кебек татарлар яшәгән башка урыннарда телебезгә багышланган конкурслар оештырыла, анда җиңүчеләр өчен премияләр билгеләнә. Чиләбе шәһәрендә балаларның татар әсәрләрен яттан уку конкурсы уза. Башкортстанның Татар Арсланы авылында балалар белән «Туган телем – назлы гөлем» исемендәге чаралар үткәрелә. Мондый мисаллар шактый һәм алар саны арта. Дөрес, әле җанлану җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Себер, Урал әле уянып җитмәде. Татарстан үзе дә әле тулы аңына килгәне юк. Ләкин бу процесс көчәя, чөнки татарның рухи дөньясы бай һәм тирән тамырлы. Аны күпме генә тырышса да, бер көч тә таптап китә һәм юкка чыгара алмый. Шулай да безгә бүгенге борчылулардан да зуррак, дәвамлы куркыныч яный. Илдә шовинистик дулкын көчәя. Мәскәү хакимияте барлык халыкара нормаларны, хәтта Россиянең үз Конституциясен дә таптап, руслаштыру сәясәтен төп вазифаларының берсенә әверелдерә.

Шушы шартларда татар нишләргә тиеш? Иң беренче нәүбәттә, әлбәттә, ул үзенең рух ныклыгын саклау һәм аны киләсе буыннарга тапшыру. Бу җиңел эш түгел, чөнки буын буыннан бик нык аерылып тора. Әгәр моңа кадәрге буыннар интернет системасын белми, компьютерларны кулланмый яшәгән булса, хәзерге алмашка килә торган буыннар бөтенләй башка рәвештә яши. Аларның күпчелеге китапны айфон-айпад кебек интернет җайланмаларына алыштыра. Китап бик сирәк рәвештә генә хәрәкәткә килә. Дөрес, китап сөючеләр дә юк түгел. Яшьләр белән актив эшли торган китапханәләребез һәм китапханәчеләребез дә бар. Аларның эшен «Китап», «Тәртип», «Болгар» радиопрограммалары да җиңеләйтә.

Шул ук вакытта без татарлар рухи байлыгыбызны киләсе буыннарга җиткерү юнәлешендә заманча барлык чараларыннан да файдаланырга тиешбез. Гуманитар белем ияләре, сәнгать әһелләре, язучылар, журналистларыбызның кулга-кул тотынышып яшь буынга үтемле чаралар булдыра торулары кирәк. Аларны башкаруда культурабыз махсус урында. Артистларыбыз, бигрәк тә аларның эстрадагылары җаваплылыкларының ни рәвештә зур икәнлеген аңлап эш итүләре зур әһәмияткә ия. Аларның концертлары булыр-булмас көйләргә һәм сүзләргә җайланган, «тыпыр-тыпыр» белән башкарыла торган җырлардан гына тормасын иде. Аларга Тукайның «хәйран булып» Сәгыйть Рәмиевнең тарихыбызны бөтен тулылыгы белән чагылдырган җырлавын тыңлавы мисал булсын иде.

Моның шулай икәнлеге аның «Милли моңнар»ында бигрәк тә ачык чагыла. «Болгар» нумерларындагы күршесе, аның дусты шагыйрь Сәгыйть Рәмиев, җырлый, ә шагыйрьнең күз алдына чал тарих килеп баса. Җыр аның күңелендә бөек чорыбызның һәм коллык упкынына төшкән «мескен» булып торган өч йөз ел арасындагы контраст картинаны тудыра. Күз алдына Агыйдел, дөньяга мисали һөнәрчелеге, сууткәргечләре, мәгълүм дөньяга кәрван юллары белән тоташкан Болгар килеп баса. Дустының җырлавы аңарда үткәнебезне сагыну хисләре тудыра. Әйтерсең лә аның үз күңеленнән дә «сызылып-сызылып» милли хисләр сугарылган әнә шул җыр чыга. Гүя ул үзе дә җырчыга кушылып җырлый, халкыбыз тарихын күз яшьләре белән барлый, «өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә татар күңеле ниләр сизгәнен.»

Татарлар, мөгаен, моңнан яралгандыр. Күрәсең, ул моң, төркиләр яшәгән Алтай гүзәллегеннән, татарны татар иткән дала киңлекләреннән барлыкка килеп, аның канына сеңгәндер. Нажар Нәҗми юкка гына «җирең кебек назлы, җырдай моңлы татар теле», дип язмагандыр. Татар җырының Александр Ключарев язганча, үзенә генә хас «музыка теле» бар, аңа «мелизм чәкәннәренең бик бай булуы характерлы».

Татар кешесе сәхнәгә, җырга-моңга мөкиббән. Шунлыктан бүгенге эстрадабыз халкыбызны милли рухта тәрбияләүдә, гасырлар буе тупланган музыкаль мирасыбызны киләсе буыннарга тапшыруда җаваплы. Тик ни кызганыч, эстрадабыз бу таләпкә җавап бирүдән ерак тора. Андагы йөзләгән «йолдызлар» буш сүзләргә көйләнгән милли традицияләребездән бик тә ерак торган такмаклар белән мавыга. Бу «йолдыз»ларның күбесе «Тәфтиләү», «Сәгать чылбыры», «Шахта», «Галиябану» кебек җырларны башкару дәрәҗәсендә түгел, кулларыннан микрофонны алсаң, тавышсыз-тынсыз кала. Зур чыгымнар белән үткәрелгән «Үзгәреш җилләре», «Татар моңы» кебек чаралар да уңышлы булды дип әйтмәс идем.

Ләкин шушы өлкәдә шактый әйбәт үрнәкләрдән Әлфия Авзалованың 85 еллыгына багышлап Татар филармониясе оештырган концертларны, дәүләт фольклор ансамбленең, Р.Ваһапов фондының эшчәнлеген күрсәтеп китмәү дөрес булмас иде. Мәдәният өлкәсенең җаваплы әһелләре шушы мисалларны рухи дөньябызны баетуга юнәлтә алса, бу зур алгарышка юл булыр.

Җыр-моң аша кешегә бай мирасыбыз сеңә, алар аның тарихи хәтерен уята. Ә бит ниләр генә сакланмый ул хәтердә. Монда Сөембикәнең фаҗигале язмышы да, Кол Шәриф хәзрәтнең шәкертләре белән бергә дошманга каршы Казан өчен ваемсыз сугышта баһадирларча шәһит китүе дә, татарның үз-үзләрен аямастан хан сараен дошманнан саклауда һәлак булган кызлары да саклана. Алар онытылырга тиеш түгел, аларны яңарта тору зарур.

Безне иң нык борчыган байлык – ул телебез, аның киләчәге. Соңгы вакытта безне телебезгә карата кылынган явызлыклар, аны дәүләт теле булу хокукыннан ваз кичтерергә тырышулар борчый. Чөнки тел – ул җан азыгы. Халыкны аннан биздерү милләтне бөтенләе белән юк итүгә юнәлтелгән.

Тагын сиңа кизәнәләр,
Сызлаталар бәгырьне,
Кагылмагыз туган телгә,
Ул җан кебек кадерле!

Шагыйрә Илсөяр Иксанова әчке кичерешләрен халкына җиткерү, аны уяту нияте белән язган бу юлларны. Ләкин сызланып, яшь түгеп яшәү татарга хас сыйфат түгел. Татар – горур халык.

Чуашстандагы Тукай авылы милли яшәешнең ачык мисалы. Монда балалар мәктәпкәчә әзерлекне яки уку-язуга өйрәнүне мәдрәсә бинасында уза. Алар үз телләре белән бергә гарәп графикасын да үзләштерә, намаз, дога укырга өйрәнә. Нәтиҗәдә авылда әчкечелек тә, наркомания дә юк.

Телебезне саклау һәм аны үстерүдә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин зур һәм актив эш башкарып яши. Ул мәчетләребездә вәгазьләр тик үз телебездә генә булсын дигән карар чыгарды. Мәчетләребез тирәсендә тел курсларының саны арта. Әгәрдә моңа кадәр андый курслар Казанның 22 мәчетендә эшләп килгән булса, тиздән аларның саны 100 дән узачак. Казанда ир һәм кыз балалар өчен аерым ике мәдрәсә эшли башлаячак. Гомумән, соңгы 10 ел эчендә Татарстанда 200 гә якын мәчет барлыкка килгән. Мөфтият журналистлар өчен «Динем – ислам, милләтем – татар» конкурс та игълан итте.

Татар теленә игътибар башка милләт кешеләре тарафыннан да арта. Мәскәүдәге Лилиана Сафина оештырган «Умарта» исемендәге татар телен өйрәнү дәресләренә руслар да йөри һәм кайберләре телебезне электрон чаралары кулланып, башкаларга да ирештерә. Шунысы да игътибарга лаек, берничә рус һәм удмурт егетләре татар теле дәреслекләрен хәстәрләп, аларны җәмәгатьчелеккә җиткерде.

Менә берничә мисал. Удмурт милләтеннән булган Алексей Арзавов 12-13 чит телне белүче 37 яшьлек егет. 17 яшенә кадәр ул үзенең удмурт телен дә белмәгән. Ләкин үткән гасырның 90 нчы елларындагы кайнап торган вакыйгалар аның канындагы туган телен уята. Аның туган теле башка телләрне өйрәнү ачкычына әверелә. Татар теле иң яраткан теле булып яши башлый. Алай гына да түгел татар телен өйрәнү дәреслеген әзерли. Ул тиз арада рус милләтеннән булган Петербургта яшәүче шулай ук татар теле дәреслеген әзерләүче Максим Петров белән таныша һәм алар аралашып яши башлый. Петров исә татар телен шулкадәр яхшы үзләштергән һәм шунлыктан горурланып «татарча өйрәтергә хакым бар», ди.

Төрки дөньяда, шул исәптән Төркиядә дә телебезгә игътибар арта. Төркиянең Искешәһәрендә яшәүче төрек кызы Гамзә Нур Налбант Сәрия Мифтахова белән радио аша үткәрелгән әңгәмәсендә «татарчаны ятлап түгел, җырлап өйрәндем», ди. Аның әңгәмәдәге түбәндәге сүзләре игътибарга лаек: «Татар теле – ул үзе мәхәббәт. Җыр, шигырь кебек... Минемчә татар теле төрки халыкларының уртак теле булырга тиеш, аңа хәзинәләр яшеренгән», дигән шушы төрек кызы. Ул Казанга күчеп килү теләге барлыгын да яшерми, «анда яшәргә, укырга телим», дип хыялын ярып сала...

(Дәвамы 4 нче биттә).

СОЛОМОН ПЛАНЫ ЧАЛЫМНАРЫ

Белгечләр әйтүенчә, адәми затта дөнья белән идарә итү хыялы әле борынгы Мисырда ук барлыкка килгән. Яшерен мәктәпләрдә (мистерияләрдә) гарифлар (жрецы) моның серләренә төшенгән, «хәбәрдар»лар җәмгыятенә тупланган. Тарихта исә дөньякүләм идарәне максат иткән тәгълимат вә планнар да җитәрлек. Алар арасында иң билгелесе һәм тормышчаны булып борынгы Израиль патшасы Соломон төзегәне санала. Давид (Давыт) патша улы Соломонның хакимлек чоры б.э.к. 1015-975 елларга туры килүе турында әйтелә. Аның борынгы Мисыр, Елга арасы һәм Финикия гарифларының күп меңьелллык тәҗрибәсенә таянып һәм 3000 елга исәп тотып төзегән планы дөньяда тыныч юл белән яһүдиләр хакимлеген урнаштыруны күздә тота. Хәтта аның исеме дә (ивритчә Шломо – «тынычлык сөюче» дигәнне аңлата икән) шуннан чыгып кушылган, дип фаразлыйлар. Жрецлар тәҗрибәсенә керү мөмкинлегенә ирешү өчен Соломон (ә милләтә буенча үзе ул хибер саналган) фиргавен кызына өйләнә. Димәк, аның фиргавен кызыннан туган балалары инде яһүди санала алмый, алар Мисыр жрецлары токымына керә. Тарихта билгеле кайбер фактларга да игътибар итик. Ханаанны Иисус Навин басып алган саналса да, иевусларның төп каласы Иевусны Давид кына буйсындыра һәм ул аның исемен Иерусалим дип үзгәртә. Шулай итеп, аларның баш каласы яһүдләр башкаласы булып китә. Сиян тавында 40 ел камалышта яшәгән кирмәнне исә Соломон гына ала һәм тиздән Иерусалимда яһүд алласы Яхвега храм төзүгә дә керешә.

Ә Соломон планына бүген игътибар артуы анда исәп тотылган вакыт җитүе белән дә аңлатыла. Бу җәһәттән бигрәк тә «күкләр сәясәте» («небополитика») тарафдарлары шәрехләве кызыклы («күкләр сәясәте» дигәндә, Хак Тәгалә ихтыяры белән үткәрелә торган хакимлек сәясәте күздә тотыла). Алар бүген бара торган сәяси вакыйгаларны Иске Гаһед (Ветхий Завет) Библиясендә (Тәүратта) язылган Ахырзаман Алышы белән бәйләп аңлата. Әйтик, Юрий Сокол атлы кемсә әле 2019 елда ук: «... образ победы в Битве Конца у пророков связан не с Сирией, а с Израилем. А поражение «царя северного» связано не с утратой территорий, но с идеологическим и моральным крахом «бездушной государственной тирании наследников Рима». Центральной фигурой Битвы Конца выступает "царь северный" с библейским именем «Гог, князь Роша, Мешеха и Фувала». Планировщик связывает пророчество о «Гоге из пределов севера» с лидером России и стратагемами (военной хитростью) признания политических успехов РФ во главе с В.Путиным. Мир приступил к возведению его в достоинство «царя северного» еще в 2012 году «черного дракона»», - дип язган иде (Юрий Сокол, https://proza.ru/2019/11/01/848). Ул гибрид сугышта Израиль халкы (1/4 е - элеккеге СССРдан) Россия һәм Украинага күченә башлар һәм Украинаның Кара диңгез буе өлкәләрендә, Соломон планына туры китереп, Одессадан Мариупольгә кадәр территориядә Яңа Хәзәр дәүләте корылыр, дип фаразлый.

Бүгенге кайбер тенденцияләрне һәм мәгълүм геосәясәтче Г.Киссинджерның әле 2012 елда ук әйткән «10 елдан соң Израиль дәүләте булмаячак» дигән сүзләрен дә искә төшерсәк, монда инде ирексездән уйлана башларсың. Ю.Соколның: «Что же касается России, то проигрыш «царя северного» как наследника бездушной государственной тирании наследников Рима, будет заключаться в крахе европейской доктрины «Москва – Третий Рим», смене режима, административной реформе и чистке элиты. Финальная часть Битвы Конца в библейских образах рисуется как военно-политическая катастрофа с массовой гибелью людей», - дигән фикере дә сагайта. «Күкләр сәясәте» Россиянең тулы уңышсызлыктан котылу юлын, Көнбатышның «сүнү егәре»ннән Көнчыгышның «арту егәре»нә күчеп, «Зур Евразия - Өченче Урда» проектына кушылуында күрә.

Гомумән алганда, тарихта Соломон планы чалымнары ярыйсы ук анык шәйләнә. Зурдан алганда, аның этапларын семит диннәренең туу һәм таралу хронологиясе һәм географиясеннән башлап (хәтта Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларын да кертеп) карарга була. Әлбәттә, бүгенге радикаль үзгәрешләрдә дә бу планның заманча чалымнары сизелә. Ә аның конкрет нәтиҗәләре инде дөнья тотучылар эшчәнлегендә күренә.

Фоат УРАЗАЙ.

Эшсез калмаячаклар

Казан федераль университетына быел татар теле укытучысы белгечлегенә укырга керүчеләр киләчәктә рус телен дә укыта алачак.

«Егерме елга якын без татар теленә өстәмә белгечлек буларак инглиз теле укытучыларын әзерләдек. Быел беренче тапкыр татар теле укытучысы белгечлегенә укырга керүчеләр ике төрле диплом алып чыгачак. Икенче диплом – рус теле укытучысы. Бүген Казаннан һәм районнардан рус теле укытучылары җитми дигән мөрәҗәгатьләр күп. Шушыны исәпкә алып, «Татар теле, әдәбияты һәм рус теле» дигән яңа программа ачтык. Бу программа буенча без 25 бюджет урынына укучылар кабул итәчәкбез», – диде КФУның Габдулла Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе деканы Рамил Мирзаһитов «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

«Татар теле, әдәбияты һәм рус теле» программасы буенча укыту Россия Федерациясе бюджетыннан финанслана. КФУның Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенә федераль бюджеттан барлыгы 110 урын каралган. Аларның алтмышы – магистратура, ә иллесе – бакалавриат өчен бирелгән. Бакалавриатның калган урыннары – «Гамәли филология, татар теле һәм әдәбияты, журналистика» программасы өчен бүленә.

Татар язучысын Төркиядә өйрәнәләр

Төркиянең Инөнү университеты чордаш төрки тел һәм әдәбиятлар бүлегендә татар язучысы Марсель Галиев әсәрләре буенча галимә Рамилә Яруллина җитәкчелегендә фәнни хезмәт якланды.

Гыйльми хезмәт «Хәзерге заман татар язучысы Марсель Галиев әсәрләрендә тел һәм өслүб» дип атала. Аны Инөнү университеты галимәсе, милләттәшебез Рамилә Яруллинаның аспиранты Фатма Җанполат-Җанал язган.

Фатма Җанполат-Җанал әдипнең поэзия тәреннән 20 шигырен һәм чәчмә әсәре буларак «Ак абагалар» лирик повестен тикшергән. Ул хезмәтендә чагыштыру методына өстенлек биргән. Яшь галимә хезмәтендә Марсель Галиевнең хис белдерү, бизәкләү чараларын куллану, фразеологизмнар, алынма сүзләр, метафоралар, сынландыру, чагыштырулар, эпитетлар, гиперболалар, теркәгечләр, бәйлекләр белән эш итү алымнарын анализлаган.

«Марсель Галиев иҗаты әдәбият белеме нигезендә өйрәнелгән. Әмма аның тел-өслүбе үзенчәлекләре бу көнгә кадәр тикшерелмәгән. Кул тимәгән шушы өлкә миңа кызыклы тоелды. Марсель Галиевнең тормыш юлын өйрәнгәндә аның рәссам булуы да ачыкланды, язучының ул сәләте әдәби иҗатына да тәэсир иткән. Әдип тел-бизәкләү чараларын шул хәтле оста башкара, әсәрләрен укыганда күз алдына якты төсләр белән сурәтләнгән картина килеп баса. Мин сүзләр белән картина ясауның серен ачыкларга тырыштым», – дип сөйләде Фатма Җанполат-Җанал.

Ф.Җанполат-Җанал Элазыг шәһәрендә туып-үскән, Фырат университетында чордаш төрки телләр бүлеген тәмамлаган, аспирантура белемен Малатия шәһәрендәге Инөнү университетында алган, татар телен Рамилә Яруллинадан өйрәнгән. Киләчәктә дә татар теле белән бәйле фәнни эшчәнлек алып барырга ниятли.

Рушания АЛТАЙ.

КАЛМАГЫЗ БЕРҮК СОҢГА!

«Мәдәни җомга»га 2022 елның II яртыеллыгына язылыр өчен санаулы көннәр калды.

Хәзерге заманда газетага почтада гына түгел, интернет аша podpiska.pochta.ru сайтында да язылып була. Соңга калмагыз!

«Мәдәни җомга»га Татарстанда язылу индексы – П2355.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә булды. Ул Кремль тарихы музееның сәнгать проекты белән таныштты һәм күрсәтмәләр бирде.

Кирмәндә тарихилек сакланырга тиеш

«Бу уникаль урынның тарихи йөзен мөмкин кадәр сакларга, биредә булган рухны саклап калырга кирәк», – дип белдерде Р. Миңнеханов.

Экспозициядә тарихи иконографияне, макетларны, документаль һәм архив материалларын, мультимедиа инсталляцияләрен куллану күздә тотыла.

Аннары Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган «Иман нуры» күргәзмәсен карады. Экспонатлар арасында сирәк кульязмалар һәм китап ядкярләре, Болгар һәм Алтын Урда тәңкәләре, гыйбадәт кылу өчен чигелгән келәмнәр һәм хатын-кызлар киемнәре һәм башка бик күп нәрсәләр күрергә мөмкин.

Киләсе тукталыш «Милли костюм театры» презентациясе булды. Анда тарихи киемнәр һәм бизәнү әйберләре урын алган. Татарстанда эшләнгән заманча кием-салым һәм аксессуарлар подиумда да күрсәтелде.

Моннан тыш, Рөстәм Миңнехановка гавами урыннар бинасының ишегалды территориясен үстерү концепциясен тәкъдим иттеләр. Биредә туристлар өчен ял итү зонасын төзү һәм төрле чаралар оештыру өчен шартлар булдыру күздә тотыла.

Казан Кремленә визиты барышында Рөстәм Миңнехановны Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова, «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесенең генераль директоры Гадел Хөснетдинов озата йөрде.

Алхәбәр

29 июньдә көндезге сәгать 2 дә Казанның Декабристлар урамындагы 2 нче йортта урнашкан «Әдәби кафе»да Ринат Мөхәммәдиевнең «Кыргый атауга сәяхәт» китабы тәкъдим ителә.

1 нче биттә – Казан янындагы Чабакса күле. Таң вакыты. Фото: И. Зәкиев

Эшмәкәрләр акчасына

Киров өлкәсенең Малмыж районы Яңа Йөрек татар авылында иганәчеләр һәм авыл халкы хисабына салынган мәдәният йорты һәм китапханә ачылды. Клуб ачылу тантанасы авыл Сабан туе белән дәвам итте.

«Әлеге йорт сезне һәм балаларыгызны бергә җыеп тора торган урын булсын иде. Бу әле эшнең башы гына. Алга таба без клуб тирәсен матурлап бетерербез. Барысы да сезнең өчен!» – дип авылдашларына мөрәҗәгать итте әлеге клуб һәм китапханә урнашкан йортны салуда төп эшне башкарган эшмәкәр Рамил Хәлиуллин.

Ул авылдашларын Сабан туеннан соң кичке концертка чакырды. Рамил Хәлиуллин авылга Татарстаннан артистлар – «Айфара» төркемен чакырган. «Бу бәйрәм сезгә ошаса, без аны ел саен кабатлаячакбыз», – диде эшмәкәр.

Рамил Хәлиуллин әйтүенчә, ул авылдаш дусты – авыл эшмәкәре Илнур Мәрданов белән бу клубны салу турында күптән хыялланган. «Мин акчалата булыштым, ул төзелеш эшләрен башкарып чыкты», – диде Рамил.

«Иске клубны яптылар. Кешенең барырга урыны юк. Уйладык-уйладык та тәвәккәлләдек. Мин башта дәүләт программаларына кереп, зурракны салыйк дип уйлаган идем. Егетләр әлегә монысын салып торыйк, диделәр», – диде иганәчеләрнең тагын берсе – «Сэвэли» агрофирмасының генераль директоры Зиннәтулла Хәйруллин.

Әлеге клуб дүрт авыл өчен уртак – Яңа Йөрек, Шаһбан, Үрнәк һәм Марс бер авыл җирлегенә карый, алар бер-берсенә якын урнашкан. Дүрт авылда 280 кеше яши.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Дини белем алыйм дисәң

20 июньнән Татарстан мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе башланды. Мөселман дини белемен алырга теләүчеләргә сайлап алу мөмкинлеге зур: Татарстанда 8 мәдрәсә, Россия ислам институты, Казан ислам университеты, Болгар ислам академиясе бар. Әлеге уку йортларының кабул итү комиссияләре дүшәмбедән җомгага кадәр эш сәгатьләрендә телефон аша татар һәм рус телләрендә консультацияләр бирергә әзер. Документлар июль ахырына кадәр кабул ителә. Август башында кабул итү имтиханнары башлана.

Мөселман уку йортларында белем бирү көндезге, читтән торып һәм көндезге-читтән торып уку бүлекләрендә алып барыла. Гомумән алганда, быел республика мөселман уку йортлары көндезге бүлеккә 400дән артык шәкерт кабул итәргә әзер, ә калган уку бүлекләрендә 750 кеше өчен урын каралган.

Татарстанда күп баскычлы дини мәгариф системасы гамәлдә. Башлангыч белемне мәчетләр каршындагы курсларда алып булса, урта һөнәри белемне мәдрәсәләр, югары белемне Россия ислам институты / Казан ислам университеты (бакалавриат, магистратура), академик дәрәҗәсендәге белемне Болгар ислам академиясе (магистратура, докторантура) бирә.

Эльмира СИРАҖИ.



Без – чигенмәс халык

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Рухи халәт һәм гамәли тормыш бер-берсенә бәйле. Күп вакыт татарларның икътисади тормышы алга бара һәм күпләргә үрнәк булып тора. Республикада бертуктаусыз яңа ширкәтләр туа, чимал эшкәртү арта. Хәзер Татарстан үзендә табыла торган нефтьнең 85 процентын эшкәртүгә ирешеп, чимал энәсеннән төшә алуы белән калган Россия өчен үрнәк тудырды. Үрнәк рәвештә яши торган авылларыбыз да бар. Пенза өлкәсендәге Урта Әләзән, Чуашстандагы Шыгырдан, Мордовиядәге Березовка, Татарстандагы Шәле, Имәнкискә, Сарабиккол авыллары шундыйлардан. Тик әле мондый авыллар күпчелек түгел. Авылларыбызның ташландык хәлдәгеләре дә, эшсезлек хөкем сөргәннәре дә бар.

Көн саен иртән Кукмара, Саба, Арча, Әтнә районнарының авылларыннан Казанга юнәлгән йөзләгән машинага тап буласың. Кичен алар ашыга-ашыга кабат авылларына кайта. Болар Казанда эш табып, анда эшләүче яшьләр. Авылларында аларга эш юк. Әлмәт, Лениногорск, Чаллы, Түбән Кама кебек шәһәрләр авырлыклар белән булса да эшсез яшьләребезне сыендыра тора. Бу район авылларының шактыенда мәктәп тә, культура һәм медицина учреждениеләре дә җитәрлек түгел. Алардан яшьләр китә. Ә бит авыл гомер-гомергә татар тормышының нигез ташы булды. Шунлыктан аны саклап калу - милләтебезнең үзен саклауга тәңгәл.

Бүгенге шартларда авыл үзенә яңа караш таләп итә. Чөнки ул совет чорындагы авыл да, анда яшәүчеләр кичәге колхозчылар түгел. Колхозларны бетерү күмәк хезмәтнең юкка чыгуы, эшсезлеккә китерде. Фермалар бушап, ташландык хәлгә килде. Җирне пай рәвешендә кичәге колхозчыларга өләштеләр. Ләкин кичәге мөстәкыйль хуҗалык алып баруга күнекмәгән, бер нинди техник мөмкинлекләре дә булмаган колхозчы, ул пай белән нишләсен? Һәркем фермер була алмый бит. Шунлыктан җир күп урыннарда инвесторлар кулына күчте. Аларның исә төп максатлары халык тормышын кайгырту түгел, ә үз кесәләрен калынайту.

Бездә, ни кызганыч, совет заманында эффектив рәвештә эшләп килгән кадрлар политикасы юкка чыкты. Шуның белән яшьләрне алдан күреп, сайлап алып, үстерү системасы да бетте. Уку йортларында бернинди системасыз рәвештә, яшәешнең нинди таләп итүе белән санашмастай белгечләр әзерләү хөкем сөрә. Шунлыктан шәһәрләрне беркемгә кирәкми торган эшсез юрист һәм икътисадчылар басып алды. Авыл хуҗалыгы белгечләрен әзерли торган уку йортларын тәмамлаганнарның күбесе, авылларда кирәк булмау сәбәпле, шәһәрләрдә теләсә нинди эшкә риза булып яши. Бүген югары белемле яшьләр арасында трамвай яки машина йөртүчеләрне, банк саклаучыларны, кибетчеләрне күпләп очратып була. Араларында сирәк булса да фән кандидатлары да бар. Аларны үстерү, укыту өчен күпме көч һәм акча коелган.

Базар системасы барысын да үзе җайлаячак, дип әйтүче галимнәр бар иде. Бүген исә без аның ни рәвештә җайланганын күреп торабыз. Җайланды, халык каны белән сугарылган милек олигархлар кулына күчеп, аннан килгән табыш чит ил банкларына кереп урнашты. Урлашып яшәү рәвеше бик тиз дәүләт органнарына да күчте. Анда урнашканнар арасында чит ил шәһәрләрендә сарайлар, диңгезләрдә утраулар сатып алучылар күбәйде. Кайберләренең кулга алынгач, өйләреннән акчаны йөк машиналары белән ташыйлар. Менә ул Россиядәге базар системасы! Аяныч ки, Россия алга бармый. Авыллары бөтенләй юкка чыга бара. Исән калганнарында карт-карчыклар гына. Шактыенда газ да, башка уңайлыклар да юк. Андагы проблемалар Татарстанга да тискәре йогынты ясый. Шунлыктан безгә кичектермәстән комплекслы рәвештәге авылны саклау программасын булдыру кирәк.

Ләкин республиканың Россия белән мөнәсәбәтләре шактый катлауланды. Бернинди аңлатусыз аның белән шартнамәле яшәешебезгә нокта куелды. Ни кызганыч, җитәкчелегебез аны дәвам итү өчен тиешле үҗәтлеген күрсәтә алмады. Җәмәгатьчелекне дә моңа җәлеп итмәде. Шуның белән үзенең көчсезлеген күрсәтте. Шушы йомшаклык Үзәкнең телебезгә карата дошмани гамәлләр кылуына юл ачты. Анысын да йоттык. Россия президентының үз прокурорыбыз аркылы җиткерелгән әмерен берсүзсез кабул иттек. Бәлки, бу күндәмлеккә чик куеп, аны Үзәк белән эшлекле һәм дәлилләнгән сөйләшүләргә алмаштыру вакыты җиткәндер? Мәскәүгә үзебезнең хокукый нормаларга таянып, курыкмастан әйтергә тиешле сүзебезне ишеттермәдек әле. Ә ишеттерергә кирәк!

Без хәтта Россия президенты тирәсендә буталучыларның Татарстанны нигезсез, ярым ялган рәвештә республикада яшәүче руслларның хокукларын бозуда гаепләү сүзләренә дә җавап бирә алмадык. Әйтерсең лә безнең әзерлекле юристларыбыз юк. Ни кызганыч, аларның авызларыннан хаклылыгыбызны исбатлаган ярым сүз дә чыкмады.

Әлбәттә, Үзәк белән аңлашу гуманитар өлкәдә генә булырга тиеш түгел. Аның беренче планга чыгуы шартнамәле яшәешебезгә нокта куюдан, телебезгә карата кылынган гамәлләр барлыкка килүеннән булды. Ә бит гаделсезлекләр икътисади мөнәсәбәтләребез тирәсендә дә җитәрлек. Аларга да чик кую вакыты җиткәндер.

Дөрес, бүген Россия өчен, бигрәк тә Украина һәм Россия низагы аркасында АКШ һәм Көнбатыш илләре тарафыннан санкцияләр бертуктаусыз арткан шартларда да Татарстанны илнең төбәкләрен өндәп баручы республика, аларга юл ярып баручы рәвешендә кабул итә. Чөнки ул тарихта чарланган, авырлыкларны җиңәргә өйрәнгән эшсөяр халык.

Йосыф тарихы кабат сәхнәдә

Республикабызда ислам диненең кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар байтак узса да, күбесенең шартлы, форсат чыкканга гына оештырылуын әйтмичә булмый. Шулай да арада тышкы сурәте белән генә түгел, эчтәлеге белән дә вакыйгага туры килгән чаралар очрап куя. Мәсәлән, ислам диненең асылы нәрсә һәм болгарларның ислам кабул итүе ни өчен шундый зур әһәмияткә ия, дигән сорауларга җавап итеп, һичшиксез, Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында әле яңа гына сәхнәләштерелгән «Йосыф» спектаклен мисал итеп китерү кирәк.

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрен XIII гасырда ук иҗат итсә дә, ул берничә гасыр дәвамында татар халкы тормышында зур урын тотып, бүгенгегә килеп җитә. Йосыф китабы, изге Коръән кебек үк, һәр өйдә кадерләп саклаган. Заманча тел белән әйткәндә, Йосыф тарихы – милли кодларыбызның берсе һәм зурысы. Глобальләшүгә йөз тоткан заманда әнә шундый рухи кыйбла булырдай язма мирасыбызга әйләнеп кайту аеруча әһәмиятле.

Театр режиссерларының Йосыф тарихы белән кызыксынулары аңлашыла. Соңгы утыз ел эчендә татар-башкортта ул бишенче тапкыр сәхнәләштерелде булса кирәк. К.Тинчурин театрында режиссер Рәшит Заһидуллин әсәрне традицион рухта сәхнәгә куйды. М.Гафури исемендәге Башкорт театрының музыкаль риваять итеп куелган «Йосыф-Зөләйха» спектакле жанры һәм сәхнә бизәлешләренең байлыгы, муллыгы белән истәлекле. Режиссер Ренат Әюпов үзе генә дә татар дөньясына Йосыф кыйссасы буенча өч тамаша иҗат ителсә дә, өч тамашаның бер-берсен кабатламыйча, өч төрле сурәттә булуыннан гына да Кол Гали әсәренең иҗатчылар өчен төпсез кое кебек бихисап мөмкинлекләр, бетмәс илһам чыганагы булып хезмәт итүе килгәндә ничек кирәк булса, дуслык-татулык, бердәмлек каккан, милләтне бүлгәләп тарату өчен зур мөмкинлекләр ачылган бүгенге көндә шундый ук зур әһәмияткә ия. Олы мәгънәле, көчле яңгырашлы Йосыф тарихы татар театр сәхнәсе өчен җитди сынау булса да, аны уйнау һәр труппа өчен зур мәртәбә. Театрларыбыз бүген әнә шундый колачлы, эпик әсәрләргә сусаган. Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек», «Сөннәтче бабай» спектакльләре янына килеп өстәлгән «Йосыф» тамашасы Г.Кариев театры репертуарының тәрбияви көчен тагын да арттыра.

«Йосыф» спектакленең үзенчәлеге музыкада һәм пластикада чагыла. Фәлсәфи яңгырашлы музыканы күренекле режиссерыбыз Фәрит Бикчәнтәевнең улы Йосыф иҗат иткән. Әмма спектакль егеткә иҗатын күрсәтү өчен бер форсат кына, аңа кадәр яшь композитор берничә ел буе Йосыф темасы башында йөрткән. Хореограф Марат Казыйханов яшь буынга күбрәк заманча биюләре, перформанслары белән таныш булса да, аның Йосыф темасына беренче алынуы түгел. Марат моннан берәр ел элек «Живой город» фондының «Город. Арт-подготовка» проектында «Кыйссаи Йосыф» темасына күренеш иҗат иткән иде. Рәссам Игорь Капитанов, костюмнар буенча рәссам Фәгыйлә Сельская, ут көйләүче оста Евгений Ганзбург Кариев театрының әлгәрерәк иҗат ителгән спектакльләре буенча да театр тамашачысына яхшы таныш. Мөфти шәех, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин дә Кариев театрына дин мәсьәләсендә киңәшләре белән әледән-әле ярдәм итеп тора. Бу юлы Равил хәзрәтнең ярдәме шулай ук зур булган. Аның теләген истә тотып, мәсәлән, спектакльдә мөнәҗәтләр, нәшидләр башкарыла. Алар вакыйгаларга оста үрелдерелгән һәм алтысы алты төрле төсмер биреп, дини эчтәлекле әсәрне һәм ерак үткәндә калган дәверне күңел белән тоярга мөмкинлек бирә. Сәхнә бизәлешләрендә кулланылган киез келәмнәр, аларга төшерелгән шәҗәрә агачы сыман бизәкләр шулай ук ерак дәверләргә якынайта. Спектакльдә сүзләр аз, әсәрдән аерым цитаталар гына яңгырый. Аның каруы тамашачыга уйланырга мөмкинлек зур. Юкса бу ыгы-зыгылы заманда күп тавышлар арасында адәм баласы үз тавышын да югалта. Тамашада символлар теле гаҗәеп бай. Иң башта кипкән кое Йосыф кардәшләренең миһербанлыкка коргаксыган җаннарын тасвирласа, ахырда ачлыкка тилмергән туганнарның Мисырга килеп егылгач су белән сыйланулары җаннарының чистарынуын күрсәтә. Бер күренештә олы ташлардан кое авызы хасил була. Кардәшләрнең коены «сүтеп», һәркайсы бөгелә-сыгыла шул ташларны күтәреп китүе күңеленә авыр йөк алуын билгели. Йосыф югалгач, атасы Ягъкуб башына бәйләнгән ак пәрдә сукыраюын һәм чәче агаруын аңлата. Спектакльдәге көчле хәрәкәт һәм ут рәссамы Е.Ганзбургның талантлы иҗаты нәтиҗәсендә әллә нинди заманча сәхнәләрнең күрке булырдай һәм бүгенге яшьләрне җәлеп итәрлек кызыклы тамаша килеп чыккан. Рольләрдә театрның бөтен актерлары диярлек катнаша. Кайсын гына алсаң да, юрганны үзенә тартмыйча, һәркайсы тулаем ансамбльне көчле итүгә үзеннән өлеш керткән. Йосыфны гәүдәләндергән Илсаф Нәҗиповның тышкы чибәрлеге генә түгел, самимилеге һәм һәр сүзендә, хәрәкәтендә шәйләнгән күңел сафлыгы да тамашачыны җәлеп итә. Яшь булуына карамастан сынатмады егет! Төп рольләрдә актерның да, спектакльгә җитди өлеш керткән композитор һәм хореографның да яшь булуы исә режиссер Р.Әюповның яңалыктан курыкмавын, яшьләргә хәерхаһлы, ачык булуын дәлилли. «Йосыф» спектаклендә Р.Әюпов чираттагы тапкыр үзен вак детальләрне дә нечкә тасвирлаучы, бер үк вакытта әсәрнең төп идеясен, фикерен югалтмыйча, эзлекле булып калучы, киң колачлы һәм иң мөһиме, милли җанлы иҗат иясе булуын раслады. 700 биттән артып киткән әсәрдән бер пәрдәлек җыйнак спектакль куюы гына да ни тора! Ислам диненең бөеклегенә мәдхия җырлаган бу тамаша – 1100 еллыкка олы, чын бүләк!

бүләк итте. Аның Чаллы драма театрында куелган спектакле әсәргә тиң киң колачы, эпик яңгырашы белән күңелгә кереп калган. Казандагы Яшьләр театрында куелган икенче спектакле Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтен генә эченә алып, матурлыгы, нечкә хисле булуы белән таң калдырган иде. Бу өченче тамашада Йосыфның күп сынауларга сабыр иткәннән соң пәйгамбәр булып ирешүенә, ислам диненең бөеклегенә игътибар юнәлтелгән. Бер үк режиссер тарафыннан аңлашыла. Спектакль динебезне зурлавы белән генә түгел, әдәби мирасыбызга карата кызыксыну уятуы җәһәтеннән дә кадерле. Тәрбияви әһәмияте зур булуы шулай ук Йосыф тарихын бәһасез итә. Ничә буын милләттәшләребез «Кыйссаи Йосыф»ны укып сабырлыкка, миһербанлы, киң күңелле булырга, нәфесне тәрбияләргә өйрәнгән. Кардәшләренең, көнләшеп, Йосыфны үлемгә дучар итүе турында тарих әсәр язылган XIII гасырда Чыңгыз хан яугирләре Болгарга яу белән

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Касыйм – татар тарихы шәһәре

Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Идел буе Болгарында рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу һәм Касыйм шәһәренең 870 еллыгы уңаеннан «Мөхлисә Бубый укулары» VI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Анда Россиянең 13 төбәгеннән тарихчы галимнәр, туган якларын өйрәнүчеләр катнашты.

Ислам дине тыныч юл белән таралган. Бу динебез традицияләренең үзенчәлеген дә билгели. Гыйльми җыенда РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов искәртеп үткәнчә, дин тоту өчен катлаулы заманнар да булды. Советлар иле җимерелгәннән соң, мөфти-шәех Тәлгать Таҗетдин башлангычы белән Россия мөселманнары шәһәрләрдә, авылларда ислам диненә, аның кануннары белән яшәүгә йөз белән борылды. Мәчетләр төзелә, мәдрәсәләр ачыла башлады, университетлар, институтлар беренче укучыларын кабул итте. Мөселманнарга, намаз укып, Аллаһка сәҗдә кылу урыннары барлыкка килде. «Бу – ренессанс чоры булды», – диде Д.Мөхетдинов. Мөфти-шәех Равил Гайнетдин ярдәме белән Касыймдагы Хан мәчете дә мөселманнарга кайтарылды. Хәзер Россия Мәдәният министрлыгы мәчетне реставрацияләү, Әфган-Мөхәммәд солтан һәм Шаһгали тәкыяләрен яңарту проектлары эшләнгән. «Бу дәүләт һәм иҗтимагый оешмаларның уникаль хезмәттәшлеге», – диде Д.Мөхетдинов.

Сәүдәгәрләр шәһәре Касыймда бөтен дөньяга сүзләрен ишеттергән нәселләр бар. Шакуловлар, Ишембаевлар, Кастровлар, Акбулатовлар, Вергазовлар, Мусяевлар, Девишевлар – шундыйлардан. Әйтик, 1887 елда дөньяга килгән Сара Шакулова – Париж университетында белем алган беренче математик. Зөһрә Байрашева татар профессиональ опера җырчысы, Разыя Котлыярова медицина буенча югары белем алган татар хатын-кызы булалар. Без күренекле дәүләт һәм партия эшлеклесе Фикрәт Табеевның да шушы яклардан икәнен беләбез. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков конференциядә Касыйм сәетләре Шакуловлар турында чыгыш ясады. Алар – Алтын Урда мөселманнары, бу нәсел башында торучылар-сәетләр XV-XIV гасырларда татарлар яшәгән җирләргә күчеп утырган. Фамилияләре сәет Шахколыйдан (Шакул) килеп чыккан. Д.Исхаков 1983 елда бу нәселне дәвам итүчеләрнең өендә булып, аларның татар дөньясында иң озын шәҗәрәләрнең берсе булган нәсел агачын күргән. «Анда 44 буын теркәлгән», – диде ул. «Әмма әлегә тарихи бәйләнешләр начар күзаллана, галимнәребез Шакуловларны әле тагын да өйрәнергә тиеш», – диде тарихчы.

Конференциядә чыгыш ясаган төбәкне өйрәнүче Энҗе Даутова да бу фикерне куәтләде. «Бәкләр, алпавытлар, кенәзләр, морзалар, гомумән, татар халкының алга китешендә әһәмиятле роль уйнаган аристократия начар өйрәнелгән», – диде ул. Ул бу уңайдан Касыйм ханлыгы тарихында искә алынган морза Дауд Бебиш турында сөйләде. Алар бу якларга Казан ханлыгы җирләреннән күченеп килгән. Зур тармаклы нәсел буларак билгеле. Бебишлар XVIII гасырның беренче яртысында Касыйм өязенең Полянка, Сәет, Высокая һәм Мунтово авылларында теркәлгән. Дауд Бебиш та Касыйм өязенең Шелдаис авылында нигезләнә. Бераздан аңа энесе Гәрәй дә килеп кушыла. Ике туган да кулга-кул тотынып эшли, балалар үстерә. Дауд алпавыт дәрәҗәсенә ирешә. Россия тәхетенә Романовлар династиясе утыргач, башка диннән булган халыкларга, аеруча йомышлы татарларга карата кырыс фәрманнар чыгарыла башлый. Әйтик, алар нәсара динен кабул итмәсәләр, үз биләмәләреннән мәхрүм калганнар. Ә инде чукындырылганнар салым түләүдә һәм рекрут җыемнарыннан азат ителгәннәр. Шушы рәвешле татар аристократиясе юк ителү дәрәҗәсенә җиткерелә, ислам динен тотучы бик күпләр туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр ителә. «Шелдаис авылыннан Дауд Бебишны да шушы язмыш көтә, аның биләмәләре тартып алына», – диде Э.Даутова.

● Дамир Мөхетдинов.

Конференция уза торган залда Санкт-Петербургта 1787 елда беренче булып нәшер ителгән Коръән дә күргәзмәгә куелган иде. Екатерина II фәрманы белән 1787 елда гарәп имлясында басылган тәүге Коръән Россия милли китапханәсендә саклана. Китапханәнең Азия һәм Африка илләре әдәбияты бүлеге мөдире Сергей Бычко Изге Китабыбызның китапханәдән беренче тапкыр чыгуы турында әйтте. Басманы Петербургтан – Мәскәүгә, ә аннан Касыймга алып килгәннәр.

● Сергей Бычко борынгы Коръән белән.

Әлбәттә, әлеге хәзинәне бүгенгә кадәр шундый яхшы рәвештә саклый алулары хәйран калдыра.

Беренче басма Коръәннең «Казан басмасы» дип танылган шрифты Казан имамы Госман Исмәгыйль тарафыннан ясалган. «1787 елда Петербургта басылган Коръәннең дә, 1803 елда Казанда басылганының да хәрефләре бердәй. Аерма шунда: Госман Исмәгыйль Петербург басмасының кырларында аңлатмалар биргән. Бу аның тирән белемле кеше булганын дәлилли», – диде Дамир Мөхетдинов. Санкт-Петербургта Коръән зур булмаган тиражлар белән биш тапкыр бастырылган. Аннары типография тупланмасы Казан университетына тапшырылган. Хәзерге вакытта Россия милли китапханәсе фондларында 240 борынгы кульязма һәм 600гә якын басма Коръән саклана. Китапханә вәкилләре Коръәннең электрон күчермәсен Россия Диния нәзарәтенә дә бирделәр.

● Әфган-Мөхәммәд солтан тәкыясе.

Күп кенә чыгышлар Сөембикә-ханбикәбезгә, Касыйм ханлыгына багышланган иде. Тарих фәннәре кандидаты Нурулла Гариф залдагыларның игътибарын Казандагы Сөембикә манарасын саклап калу мәсьәләсенә юнәлтте. Борынгы язмаларда Сөембикә манарасын татарлар Хан мәчете, ә руслар «Азия архитектурасы манарасы», «борынгы манара», «татар манарасы» кебек гыйбарәләр белән йөрткәннәр. «Ул 1832 елда гына беренче тапкыр Сөембикә манарасы буларак искә алына», – диде Н.Гариф. 1913 елда начар хәлттә булуына игътибар итәләр. Губернатор тарафыннан төзелеш оешмасына аның торышын билгеләргә һәм бу хакта җавап бирергә кушыла.

1917 елгы революциядән соң Хан мәчете манарасыннан 1730 елда куелган каракош сурәте алына һәм ярымай куела, 12 елдан соң ул кабат төшерелә. Бары 1980 еллар ахырында гына татар җәмәгатьчелеге үтенече белән Сөембикә манарасы реставрацияләнеп, аңа ярымай урнаштырыла.

Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшли торган «Татарстан төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, тарихчы-археолог Альберт Борһанов географик, археологик, архитектура һәйкәлләрен, кабер ташларын өйрәнүнең әһәмиятен искәртте. Ул бу уңайдан Касыйм шәһәренең Мещера шәһәрчеге, Хан кирмән, Касыйм ханлыгы атамаларын йөрткән тарихи урын булуын искә төшерде. «Биредә XV-XVI гасырдан калган истәлекле корылмалар, биналар бар», – диде ул. Әйтик, Татар бистәсе, Татар урамы, Татар тавы кебек атамалар, Хан мәчете, Шаһгали һәм Әфган-Мөхәммәд солтан тәкыяләре кебек гаять әһәмиятле корылмалар бар.

Альберт Борһанов шуңа да Касыймдагы ядкәрләрне өйрәнүләр барышында һәм һәйкәлләрне тәртипкә китергәндә дәүләт структуралары һәм җәмәгатьчелекнең дә катнашуы кирәклеген ассызыклады. Шушы максаттан Фәнни-методик советлар да булдыру сорала. «Төбәкнең күренекле шәхесләребезнең тормышын өйрәнү, мемориаль такталар кую, һәйкәлләрен урнаштыру – эшебезнең мөһим юнәлеше булырга тиеш», – диде А.Борһанов. Биредә шулай ук туризм инфраструктурасын үстерергә, тарихи биналарны төзекләндерү мәслихәт. Касыйм шәһәре тарихын һәм аның тирәлеген нечкәләп өйрәнү һәм тарихи биналарны саклау буенча дәүләти комплекслы программа кабул итү әйбәт булыр иде. Галим шулай ук Касыймны, аның татарларга бәйле һ.б. объектларын тарихи шәһәр-музей, музей-тыюлык итәргә, аны дәүләт саклау реестрында булуында ирешергә, шәһәргә Бөтенроссия тыюлыгы статусы бирергә, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасны саклау исемлегенә кертергә тәкъдим итте.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

ГАҖИЗ УЙЛАР

Золым үтәр. Исән булсак – яшисе бар,
Бик күпләрнең күзләренә карыйсы бар,
Күкрәк каккан империя колларының
Алда әле сәрхушлектән айнысы бар!

Золым тынгач – нәтиҗәсен татыйсы бар,
Кемнәрнеңдер батырлыгын таныйсы бар,
Яралысын, югалганын, тотылганын,
Дус-дошманын, шәһитләрне санайсы бар...

Дөньясына өр-яңача карыйсы бар,
Алга таба ни кыласын аңлыйсы бар,
Яңа шартлар кысасыннан кысылмыйча,
Җайлашасы, вәзгыятькә ярыйсы бар.

Золым тынып, без тынмасак – таңнар туар!
Дары исен, кан тапларын яңгыр юар.
Кемнең тәндә, кемнең җанда яра калыр,
Кемдер исә кешелеккә өмет җуяр.

Зәхмәттән соң элеккечә агар сулар,
Кемнәрнеңдер илдәшләре тынын буар.
Гавам кабат, гадәтенчә, баштанаяк
Үзе белгән мәшәкатькә кереп чумар.

Җаныңа сарылган кабырчык
Бормалы, катмарлы, күп катлы.
Без – әкәм-төкәмнәр сыңары,
Шуышып ашлаучы туфракны.

Сакчыллар, имеш, без, бөкрегә
Какшамас кабырчык кигезгән.
Йөз суын корытып, ут йотып
Йөрибез мүкәләп, бер эздән.

Яшибез яшереп бөкрене,
Турылар, төзләрдән кер эзләп...
Беркөнне юешең кибәр дә,
Куярлар җир белән тигезләп...

Күзләрне ачасы урынга,
Күз йомып шуабыз, капшанып.
Юатып, юмалап күңелне,
Мәхлукҗан булуга шатланып,

Акланып, сыенып шул җисем
Шәүләсе артына: «Без, дибез,
Дөньяны үзгәртер көч түгел,
Шөкер, бар шуышыр җиребез.

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Тол калырга теләп, чыкмагандыр иргә,
Күрмәгәндер нужа, җиргә күмәр өчен
Үсеп буйга җиткән улын – кадерлесен!
Бездән сорамыйлар: телибезме, юкмы
Ил ирләре ача бер-берсенә утны.
Илләр белән илләр, ирләр белән ирләр
Тынышалмый һаман...
Ә син ачмы, тукмы? –
Юк беркемнең эше. Уеннары – яулар!
Әйтерсең лә кеше – бер канечкеч
җанвар...
Барыбер үк түгел инде болар безгә,
Бу хәлләргә безнең фикер төптән үзгә.
Үзгә караш бездә бу хәлләргә, ләкин,
Милләтебез үги, шыр ялангач ятим!
Юк, барыбер түгел! Сыктый, әрни
күңел!
Тик барыбер беркем берни кылмый,
ләкин...
Бар кылганнар – дога: ярлыкасын
Ходa!
Шуннан узып тагын нәрсә диеп
әйтим?!

Безгә барыбер дә түгел инде, ләкин Бездән сораучы юк! Без бу илдә ятим...

Таңнар һаман офыкларны канга буяр,
Ирләр елкы, бәрән чалыр, корбан суяр;
Яшь киленнәр күмәчкә дип камыр куяр...
Яшәешнең ләззәтеннән кем соң туяр?!

Шаулап торсын тук игеннәр тулы кырлар,
Янграп торсын шат авазлар, моңлы җырлар.
Насыйп булсын сыйланырга – нинди сый бар,
Гөрләп үтсен күркәм мәҗлес – Сабантуйлар...

Күге аяз, тамагы тук, өсте бөтен,
Имин булсын җир йөзендә кыз һәм уллар!
Дәрман бирсен сулар һава, әчәр сулар,
Кунакларга сәфәр дәшсен олы юллар!

Җәбер-золым кайчан бетәр? кайчан тынар?
Кем вөҗданын саклап калыр? кемнәр сынар?
Кемнәр газиз җанын корбан – фида кылыр?
Шул сорауга җавап эзли гаҗиз уйлар...

ДӘШМӘГЕЗ

Әйтмәгез акны – ак, караны кара, дип.
Җигелик, күзләрне йомыйк та!
Җиңелдек без күптән, яуларда түгел лә,
Җандагы куркудан, коллыктан.

Әйдәгез, кулларны күтәреп укыйк та
Без «Ясин» сүрәсен... Онытыйк.
Онытыйк һәммәсен – үткәнен, хәзерен...
Онытыйк туганнар каберен.

Юк, диик, андый хәл булмаган, булмас та!
Безнең юл гел башка, тик – җиңү!
Безнең ил иң бөек, иң гадел, иң хаклы!
Тик алга! Тик туры! Юк чигү!

Йә шулай диик без, йә дәшмик бер сүз дә.
Күзләргә элик тә пәрдәләр.
Күрмәскә тырышыйк, ишетмик, сөйләшмик!
«Без, диик, җиңелгән бәндәләр».

Һәм шулай яшәве, сулавы җиңелрәк –
Вөҗданың тынычны бумаса.
Кулларны күтәреп, без «Ясин» сүрәсен
Укыйк һәм багышлыйк, булмаса...

ӘЛЕГӘ

1

Инкыйраз дигәне шушыдыр,
Инкыйраз – бусага төбендә!
Инкыйраз һәр типкән йөрәктә,
Һәр күндәм бәндәнең күңелендә.

Без, дибез, зур түгел, кечеләр,
Без, дибез, бәләкәй кешеләр.
Тик безнең нигезне тишмәсен
Күзләрен кан баскан күселәр.

Тик безгә тимәсен дөньяны
Айкаучы туфан вә гарасат,
Читләтеп үтәр бар золмәтләр
Мәңге дә күзләрне ачмасак.»

Һәм йомган күзләрне мәңгегә
Йомганчы без шушы халәткә
Риза күк, ни булса – шул булсын,
Тик безгә тимәсен, әлбәттә.

2

Кыенлык шулай да ишекне
Шакыса, үтмичә читләтеп,
Кардәше сыртына ябышып,
Бәгырен суырыр, бәдбәхет.

Күрмәс ул күзләрне кисүче
Нур тулы хакыйкать кояшын.
Күршесе, туганы сыртына
Өяр бар моң зарын, нужасын.

Дөньясын - һәммәсен гаепләр,
Тик үзе «гөнаһсыз, саф» калыр.
Инкыйраз сәбәбен аңламас,
Ак-кара үзара буталыр, –

Шул булыр җандагы инкыйраз,
Кайталмау истигъфар-тәүбәгә.
Шул булыр вөҗданның тәмугы,
Җәһәннәм – мәхлукҗан бәндәгә...

3

Гомерлек юлдашы инкыйраз
Булучы илемнең күгендә
Бүген дә куера болытлар,
Инкыйраз – бусага төбендә.

Агыла ике йөз мөһерле
Кургашын табутлар ташкыны.
Һәммәбез кабырчык эчендә –
Әлегә өс бөтен, ас коры...

Әлегә казаны күрүче
Син түгел, мин түгел, ул түгел,
Әлегә кабырчык исән-сау...
Әлегә! – Юану тәкъбире.

Әлегә без исән! Калганы
Эш түгел безнең дә, сезнең дә.
Һәр бәндә ялгызы сызлана,
Бикләнеп, кабырчык эчендә.

КЕШЕЛЕККӘ ӨМЕТ

Үтерелгән җаннар арткан саен
Җанны яктыртучы өмет китә.
Һәр гөнаһсыз корбан өчен йөрәк
Бәргәләнеп, тән читлеген өтә.

Сыкранамын, җасусларны тиргәп,
Иман сорап залим йөрәкләргә.
Бер-беребез җанын кыяр өчен
Түгел лә ул куәт беләкләрдә.

Бер-беребезне күрә алмас өчен
Парлап бирелмәгән безгә күзләр.
Телләр ярдәмендә чагарга дип
Табылмаган мәгърур асыл сүзләр.

Кеше үтерелгән саен җирдә
Кителәдер җанның яктылыгы.
Без Кешеме? Әллә бу исемгә
Лаек түгел адәм актыгымы?

Кешелекле булып калыр өчен
Ник бәндәләр куймый хәләл көчен?
Бүгенгемә инанырга кыймый
Юрап йөрим, бу дип, бары төшем.

Саташуым дип юравым юкка,
Дөнья ычкынган күк кендегеннән.
Безгә калыр, ахры, гарьлек катыш
Яшеренеп йөрү кемлегеңнән.

Тыеп була микән дөньядагы
Кешелексезлекне арттыруны?
Кешелекне саклап калу өчен
Максат итә алсак иде шуны.

ТҮГЕЛ, ЛӘКИН...

Барыберме безгә, сезгә барыберме?
Марсель Галиев

Безгә барыбер дә түгел инде, ләкин
Бездән сораучы юк! Без бу илдә – ятим!
Без бу илдә – мәхбүс, тавышы сансыз
коллар,
Безнең оранннарны күмә колоколлар,
Безнең оланнарны сорый заман җиле,
Шушы илдә бала табучысы – тиле.
Ул баласын, юкса, тапмагандыр илгә,

КҮНДӘМЛЕК

Без күнектек бугай. Без өйрәндек,
Йөрәкләргә якын алмый гына
Үткәрергә кеше хәсрәтләрен,
Үз яраңны ялмый-ялмый гына...

Без өйрәндек бугай залимнәрнең
Тәкъбиренә амин тотарга да,
Йодрыкларны төйнәп, йомып күзне,
Зәмзәм итеп хәсрәт йотарга да...

Без күнектек кебек хаксызлыкның
Хаклыгына ихлас инанырга.
Бастырылып, без оныттык бугай
Йокы сөременнән уянырга.

Без бүкиләр бугай... Бүкән сыман,
Чабып төпләнгәннән торып калган.
Тамырларың белән бер береккән
Җирдән кубарылу уе яман.

Казынуы авыр уеңда да,
Уйланмавың, сызланмавың – алтын.
Чабуларың җыеп, ялкынланмый
Җан асрый белү – яшәү хакың.

Яши алсаң... Яшәү, дисәң, шушы,
Шуышуың – очу, диеп атап,
Әгәр мәдхияләр җырлый белсәң,
Вөҗдансызлык хакын мең кат хаклап.

Иман терәүләрен җимердек тә,
Калдырмадык кадерләргә ядкәр.
Кимермик дип, җанны, җилгә каршы
Төкердек соң, йәгез, кайда кадәр?

Түшәлгәнме изге ният белән
Безнең юлларыбыз тәмугкача?
Өрәк сыман бәргәләнә Иман,
Нәүмизләнеп, җанга иңәлмыйча.

...Без җиңелдек бугай, яусыз гына,
Без бирелдек, ахры, әсирлеккә.
«Аһ, син заман, заман!» – дия-дия,
Төрдек үзебезне кәфенлеккә...

Без күнектек бугай җан сакларга,
Йөрәкләргә ялкын үрләтмичә.
Җан сакланды – Иман хисабына...
Фани Җирдән Сират кичә-кичә.

Тел белүчеләрне теләүчеләрне дә

КФУның татар теле белеме кафедрасы профессоры Фираз Фахраз улы Харисов үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Хатыны Чулпан Мөхәррәм кызы белән алар 150 дән артык дәреслек язган. Әңгәмәбез дә татар теле, аны укыту методикасы һәм дәреслекләр турында булды.

– Фираз әфәнде, бүген Сез – фән белән тирәнтен шөгыльләнүче галим. Татар теле белемен сайлау балачак хыялыгыз идеме?

– Мин – Башкортстан егете. Казанга килүем табигый хәл дип уйлыйм. Әнкәйнең энесе Мөнәвир абый Башкортстанның Яңавыл районыннан килеп, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеген алган. Шунда Рәшидә апа белән очрашып, гаилә корганнар. 30 елдан артык туган авылым Истәктә мәктәп директоры булып эшләде. Аннан соң аның эшен Рәшидә апа дәвам итте. Алар миңа беренче этәргеч ясады.

9 сыйныфта Казанда иҗат итүче татар язучылары, татар әдәбияты белән кызыксына башладым. Казанга килеп, үземнең атаклы якташларым – язучы-сәнгать әһелләре белән танышу турында хыялландым. Яңавыл районы матур әдәбиятка, сәнгатебезгә бик күп шәхесләр биргән: Риза Ишморат, Нурихан Фәттах, Илдар һәм Нил Юзеевлар, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Нәҗибә Сафина, Нәфкать Нигъмәтуллин, Радик Гәрәев һ.б.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Мөнәвир абый миңа татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләргә тәкъдим итте. Бер ел эшләдем, бик ошады. Аннан соң рәсем дәресләрен дә бирделәр. Кичке мәктәптә сызым дәресләрен укыттым. Шулай итеп, укытучылык һөнәре бик ошап китте, икенче елны да мәктәптә эшләргә булдым. Ниһаять, Казанга укырга китәм дигәч, өйдәгеләр – әткәй белән әнкәй берсүзсез риза булды. Ләкин май аенда мине Совет Армиясе сафларына алдылар. Бу 1971 ел иде.

Армиядә хезмәт иткәндә, кайтырга бер ел калгач, әнкәйгә хатымда татар теле, татар әдәбияты, тарих һәм рус теленнән дәреслекләр җибәрүен сорадым. 4-5 китап җибәрделәр. Шул китапларны укып, кичләрен кызыл почмакта утыра идем. Командир күрә дә: «Кире татар, тагын монда утырасыңмы?» – дип төрттерә иде. Тарихи ватаныма кайтырга теләгем булуы турында әйттем. Имтиханнарга әзерләнә башладым, конспектлар ясадым.

Хезмәт срогын тутырырга дүрт ай кала полк командиры үзенең янына чакырды. Казанда укып, татар теле укытучысы булырга теләвемне ишеткәч, көлемсерәп куйды. «Китчәле, КПСС Үзәк Комитеты Мәскәү университетына бушлай укыту турында карар чыгарган, әнә. Фәлсәфә факультетында! Шунда кер, танылган сәясәт белгече булачаксың!» – ди бу. Уйларга бер атна вакыт бирде. «Кирәк булса, әниеңә шалтыратып аңлат. Бер атнадан соң синнән уңай җавап көтәм», – диде ул шунда ук. Әнкәй нәрсә әйтсен инде... Аптырап китте. «Улым, үзең хәл ит инде»,– ди. Бер атна – ун көн үтте, командир чакыра. «Ну, как?» – дип кырт кисте. «Казанга кайтырга телим бит. Йөрәгем шунда тарта», – дидем аңа. Командир тагын бер атна уйлап карарга вакыт бирде. «Монысы инде бөтенләй оятсызлык», – дип уйлап куйдым эчтән. Үзем кереп әйтмичә булмый! Кабинетына кергәч, командир телсез калды. Күзләремә карады да: «Аңладым мин сине. Куйган максатың ошады. Максатыңа ирешү өчен танк кебек барасың», – ди. Үземә дә кызык: улчакта татар теле укытучысы белгечлеген сайлау теләге шулкадәр көчле булган!

– Казан педагогика институтында, – дип дәвам итте сөйләвен Фираз абый, – мине доцент, әдәбиятчы Мәдинә Җәләлиева беренче курстан ук үз канаты астына алды. Башкортстаннан икәнемне белгәч, Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» романының тел-стиль үзенчәлекләрен тикшерергә киңәш итте. Ул вакытта әсәр басылып кына чыккан иде. Диплом эшем дә Нурихан абыйның шушы әсәренә багышланды. Фәнни-гамәли конференцияләрдә докладлар белән чыгышлар ясадым, призлы урыннар да алдым. Фәнгә аяк басуым әнә шулай башланды.

...Төп максатым – якташларым белән танышу иде бит. Беренче курсның ахырында безнең төркем Илдар абый Юзеевны очрашуга чакырды. Илдар абый ул вакытта ук танылган шагыйрь иде. Очрашу тәмам булганнан соң, барысы да аның янына – автограф алырга агылды. Мин дә шуларга иярдем. Аның «Карурман» дигән куен дәфтәре формасындагы китабын алып килгән идем. Сабыр гына алдагы кешеләрнең киткәнен көтеп тордым. Ләкин «Мин Сезнең якташыгыз бит! Автограф бирә алмассызмы?» – дип, янына барырга батырчылык итмәдем... Шул вакытта ул китапка: «Мин Илдар абыйдан автограф алырга теләгән идем, ләкин кыюлыгым җитмәде, янына барырга оялдым», – дип язып та куйганмын. Китап миндә әле дә саклана.

Еллар үтеп, Илдар абый белән якыннан аралаша башлагач: «Бер кызык язма күрсәтимме?» – дим. Китапны кулына тоттыргач, язуны күреп алды да, тыйнак кына елмаеп, автограф язып бирде. «Нигә шул вакытта ук яныма килмәдең, танышкан да булыр идек», – диде.

1977 елда педагогика институтының ректоры Мирфатыйх Зәкиев иде. Мин бишенче курста укыган чакта, үзенең кабинетына чакырды. Хәлләремне сорашты. Комсомол оешмасына сәркатип урынбасары эзлиләр икән, мине куймакчылар. «Тулы ставкага эшләп, көндезге бүлекне ничекләр укып бетерермен?» – дип аптырап калдым. Күп сөйләшми торган Мирфатыйх абый: «Укырсың, син булдырасың!» – дип кырт кисте. Ул мине яхшы белә иде: 4 ел дәвамында студсовет рәисе буларак та һәм «Синтаксис» фәнен укыткан галим буларак та.

Бишенче курсны тәмамладым, тик фатир мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Ел ярым эшләгәннән соң, минем яныма татар теле кафедрасы доценты Рүзәл Юсупов керде дә, Казанның Ленин районы Башкарма комитетында эш урыны бар, иң мөһиме – өч елдан соң фатирлы буласың», – дигән хәбәр җиткерде. Минем өчен бу күктән төшкән бәхет кебек иде!

Ләкин айдан артык мине Мирфатыйх Зәкиевич җибәрмичә «җәфалады». Комсомол комитетында эшең әйбәт бара, диссертация темасы өстендә эшләвеңне дәвам ит, дип ике тапкыр борып чыгарды. Шул ук вакытта райисполкомнан шалтыратып: «Килсәң кил, бер атнадан артык сине көтә алмыйбыз», – дип йөрәккә шом салдылар.

Өченче тапкыр кергәч, кыюрак булырга тырыштым: «Мирфатыйх абый, зинһар, дөрес аңлагыз! Минем өйләнәсем бар, яшем дә бара», дип өстәгәч, ул шунда ук: «Кемгә?» – дип кызыксынды. Чулпанга, дидем.

Ул Чулпанны бик яхшы белә иде. Әле дүртенче курста укыганда ук үзенең синтаксис буенча язган монографиясен Чулпан белән Гөлназ исемле студент кызларга укып корректурасын тикшерергә кушкан булган. «Алай булгач, нигә аны башта ук әйтмәдең, кире әйләнеп кайту шарты белән җибәргән булыр идем», – диде. Шулай итеп, комсомол комитетында ел ярым эшләдем дә, «фатирлы» эш урынына күчтем. Җиде елдан артык шунда эшләргә туры килсә дә, күңел һаман педагогика институтына тартты. Ниһаять, Рүзәл Абдуллович чакыруы буенча (ул ректор итеп билгеләнгән иде), мин анда кире әйләнеп кайттым һәм акрынлап яңадан фән юлына кереп киттем.

– Фираз абый, Чулпан апа белән Сез – татар теле дәреслекләре авторлары. Бу гамәл ничек башланды икән?

– 1992 елда рус мәктәбендә укучы балалар өчен беренче кулланмабыз Чаллыдагы

генә түгел, аны өйрәнергә югалтабыз

КамАЗ нәшриятында басылып чыкты. Аңа кадәр шактый фәнни мәкаләләр язып өлгергән идек инде. Көннәрдән бер көнне күренекле педагог, ул чакта Мәгариф министрлыгында милли бүлек җитәкчесе булып эшләгән Әнвәр Хуҗиәхмәтов үзенең кабинетына чакырып алды. «Фираз Фахразович, Сез нишләп дәреслекләр язмыйсыз!?» – дип җитди тон белән әйтте дә, кычкырып көлеп тә җибәрде, безгә дәреслекләр яза башларга киңәш итте. Ул вакытта Чулпан белән Казан дәүләт педагогика институтында укыта идек.

Беренче дәреслегебез 1994 елда рус телендә белем бирү мәктәпләренең 3 сыйныфында укучы татар балалары өчен басылып чыкты. Шуннан соң актив рәвештә дәреслекләр язарга алындык, 1-11 сыйныфлар өчен программалар төзедек. Ул елларны искә алам да, җиң сызганып, ару-талуны белмичә (әле ике балабыз да бар, җитмәсә, күп еллар буе мин җитәкчелек эшендә дә!) эшләгәнбез икән, дим.

1-4 һәм башка сыйныфлар өчен 60 лап дәреслек, методик кулланма, сүзлекләр төзедек (дәреслекләрнең һәм сүзлекләрнең электрон вариантлары дөнья күрде). Алар күп тапкырлар яңадан басылып чыкты.

2012 елдан башлап «Перспектив башлангыч мәктәп» концепциясенә туры килә торган 1-4 сыйныфлар өчен рус телендә гомуми белем бирү мәктәбенең татар балалары өчен заманча дәреслекләр чыгардык. Ул дәреслекләрнең төп идеясе – тел һәм сөйләм материалын укучыларга геройлар ярдәмендә тәкъдим итү. Анда мәкаль-әйтемнәр, ребуслар һәм рухи байлыкларыбызны чагылдырган башка материаллар да күп. Дәреслекләр җанлы һәм кызыклы итеп эшләнгән иде.

Аннары, моңарчы татар телен балаларга кызыклы итеп өйрәтү өчен, рәсемле сүзлекләр төзелмәгән иде. Бу эшкә дә Чулпан белән тотындык. Барлыгы 11 сүзлегебез дөнья күрде. Алар Россиядә куллану хокукына ия иде.

– Эштә дә, өйдә дә дәреслек төзү белән мәшгуль булгансыз...

– Без генә түгел, балаларыбыз да. Беренче апробация алар белән узды! Әле дә хәтерлим, 5 сыйныф өчен дәреслек язганда, улыбыз Илшат яныма килде дә, бала күзлегеннән чыгып: «Бу күнегү авыррак кебек, алыштырмыйсызмы, эти», - дип әйткән иде. Гаиләдә икең дә бер юнәлештәге белгеч булу – зур бәхет дип саныйм. Ирешкән уңышларыбыз да шуңа бәйле.

Икебез барысы 150ләп китап яздык. Аның күбесе – югары уку йорты, мәктәп өчен дәреслекләр, кулланмалар, монографияләр.

Телләр турында закон кабул ителгәннән соң, 2000 елның башларында, гыйльми совет барлык педуниверситет студентларына да ике семестр буе татар телен укытырга дигән карар чыгарган иде. Хезмәттәшләр белән уйлашып, аның программасын төзедек, ике кисәктән торган махсус дәреслек тә чыгардык. Шулай итеп, татар һәм башка милләт балалары ел буе мәктәптә алган белемнәрен вузда камилләштерү мөмкинлегенә ия булды. Шундый чын алгарыш чоры булган ул чакта! Хәзер аны күз алдына китерүе дә кыен.

Чулпан Мөхәррәмовна белән шушы эшчәнлегебез Мәгариф һәм фән министрлыгы кушуы буенча чит регионнарда яшәүче милләттәшләребез өчен махсус программа төзүгә этәргеч бирде, безгә шактый еллардан бирле Мордовия педагогика университетының филология факультетында студентларга лекцияләр уку, гамәли дәресләр үткәрүдә, гомумән, анда татар мохитен булдыру һәм үстерүдә якыннан торып катнашу насыйп булды. Шуның белән бергә Саранск шәһәрендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен махсус оештырыла торган курсларда да фәнни-методик казанышларга багышланган лекцияләр укырга, мастер-класслар үткәрергә туры килә.

– Бөтен студентлар өчен? Бу сүз экияттәге кебек яңгырый.

– Әйе, әйе, бөтен Татар гуманитар педагогика университеты, ә кушылгач КФУ студентлары да берничә ел татар телен өйрәнде. Математиклар да, физкультура бүлеге студентлары да... Уйлап карагыз, ике семестр! 186 сәгать. Чагыштыру өчен, мәсәлән, хәзер морфологиягә 54 сәгать каралган.

– Татарстанда телне белү тенденциясе, динамикасы нинди? Үзгәрәме ул?

– 2017 елга кадәр татар телен башка милләт вәкилләренә өйрәтү җайлашып киткән иде, чөнки хөкүмәт тарафыннан тиешле шартлар тудырылды. Телләр турындагы закон нигезендә татар һәм рус телләренә тигез күләмдә вакыт бирелде, методикасы эшләнде, программалар, дәреслекләр төзелде. Ыгы-зыгылар да беткән кебек иде. Төрле олимпиадаларда катнашып, зур күрсәткечләргә ирешкән укучылар тәрбияләде бит татар теле укытучылары! Мин 30 елга якын республика олимпиадасының жюри рәисе буларак та әйтәм моны.

Ә безнең татар филологиясе факультетында рус милләтеннән булган студентлар укып чыкты, без аларны дәреслек авторлары составына да керттек (мәсәлән, Екатерина Панова). Телебезне өйрәнү – яшьләр өчен тәрбия чарасы да бит әле ул: киләчәк буын милләтебезнең рухи, милли-мәдәни байлыгына якыная, аны үзләштерә дигән сүз.

Бүген ситуация тамырыннан үзгәрде. Без тел белүчеләрне генә түгел, аны өйрәнергә теләүчеләрне дә югалтып барабыз. Сәгатьләр саны да кыскарды. Шуңа ана телен белүче балалар саны да кими башлады. Бу бик аяныч хәл!

Статистик мәгълүматлар буенча, бик күп татарлар әби-бабасы телен балаларына өйрәтергә теләми. Бу – зур фаҗига. Ләкин мондый шартларда да без оптимизмны югалтмыйча, белем бирүне яңача оештыру өчен, заманча метод-алымнардан, технологияләрдән актив файдаланып эшләргә тиеш булабыз, чөнки Россия кануннарын гамәлгә ашырмыйча булмый. Мин барыбер ни өчен безнең илдә ана теленә мөнәсәбәт шулай үзгәргәнен аңлый алмыйм. Тормыш алга бара, киләчәктә замана җиле тагын бер тапкыр безнең якка таба борылыр әле, дигән теләктә калам.

– Болай булгач, телнең киләчәге ничегрәк булыр икән?

– Беренче ышаныч Марат Әхмәтов һәм Васил Шәйхразиевлар җитәкләгән комиссияләрнең актив, максатчан эшләвенә кайтып кала, дип уйлыйм.

– Үзегезнең оныклар татарча беләме соң?

– Иң зур оныгыбыз Гайшә Казан шәһәренең 80 нче мәктәбендә укый. Каюм Насыйри исемендәге балалар укуларында беренче урынны алды. Оныгыбыз Йосыф та татар бәйгеләрендә беренче урыннарны яулый.

Балаларыбыз Илшат белән Гөлшат рус мәктәбендә укыса да (өебезгә рус мәктәбе якын иде), гаиләдә татарча аралаштык, беркайчан да русча сөйләшү булмады. Мәктәп «нуль»дән башлап, камил дәрәҗәдә ана теленә өйрәтә алмаска мөмкин. Аның өчен гаиләдә тиешле мохит, аралашу булырга тиеш. Балаларыбыз татар теле олимпиадаларыннан еш кына җиңүче булып кайта иде.

Илшат хәзерге вакытта Америкада яши, оныклар да шунда туды. Илшат та, киленебез Венера да гаиләдә татарча сөйләшә. Оныклар татарча сөйләшкәндә, инглиз сүзләрен кыстырмый. Барысы да фәкать гаилә тәрбиясеннән тора. Кайбер ата-аналар: «Дәреслекләр һәм укытучылар начар, балам сөйләшергә өйрәнә алмады», - дип зарлана. Хәтта кайбер зыялылар да шулай ди! Ә син өеңдә балаларың белән татарча сөйләшмәгәч, мәктәп кенә өйрәтә алмый ич!

– Фираз абый, Татарстанда киң җәмәгатьчелек Сезне мәгърифәтче Харисовлар дип белә. Ни өчен шулай?

– Безнең гомуми эш стажыбыз 300 елдан артып китә. Мине һәм тормыш иптәшемне беләсез инде. Энекәшләрем дә – шөкер, мәгариф өлкәсендә билгеле шәхесләр.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

intertat.tatar

УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

«Каршы таулар» повестеннан

(Дәвамы. Башы 23 нче санда).

Гыйниятнең таза гәүдәсенә Прохоров ачулы караш ташлады да кырт борылып китеп барды. Икесе кире килгәндә Басыйр абзый соңгы бурычын үти иде инде:

– Кашафетдин углы Бәдретдин белән Туктар углы Сәмигулла әйбәт кешеләр идеме?

Арттан гөрләшеп шаулаштылар:

– Әйбәт кешеләр иде, хәзрәт, әйбәт кешеләр иде! Ике якка хушлашу сәламе биргәч, бит сыпырып дога кылдылар. Кузгала башлаганнар иде, Учак Сәлахетдиненең тавышы ишетелде:

– Тукта инде, Басыйр абзый, мин хәер таратырга тиеш идем бит.

Күңелләрендә моңсулык булса да, елмаештылар.

– Вәт ичмаса, Учак дигәч тә Учак. Тарат әйдә!

– Миңа да бир, Сәләх, үтеп китә күрмә.:. Каберне уратып тезләнеп утырдылар. Сәләх йөреп вак акча таратып чыкты. Тик Басыйрга гына өчлек кәгазь акча бирде. Исән-имин калган ир-егетләрнең күңелләре нечкәргән иде. Сәләхетдин хәер өләшкән чакта зиреклебашларның барысы да авылны һәм анда авыл зиратында мәет күмгән көннәрне исләренә төшерде.

...Мәчеттән мәетне алып чыкканда урамда байтак малай-шалай җыйнала. Валдай калкулыкларына үлем эзләп килгән ирләрнең дә бар иде ваемсыз малай чаклары. Алар да картларның мәетне алып чыкканнарын күтеп мәчет янында уралалар иде. Аннан соң, ирләр янына басып, йөзләренә кайгы билгеләре чыгарырга тырышып зиратка юнәләләр. Аның матур итеп кызыл кирпечтән эшләнгән капкасыннан атлап кергәндә инде теге дөньяның башы шуннан башланганына аларның шиге юк. Мәетнең килгәнен көтеп торган ачык кабер авызына малайлар карамаска тырышалар. Аларның күбесе, үзләрен бу дөньяга мәңгегә килгәндәй хис итсәләр дә, күңелләрен шом биләп өлгергән була. Бабайлар, мулла артына тезелеп, аның моңлы тавышын тыңлап тавыш-тынсыз гына басып торган чакларда малайлар да тыналар. Бу мизгел алар әле аңлап бетерә алмаган бер вакыт булып, яшь күңелләрендә үзенә генә хас моңсу бер кичереш тудыра...

...Блиндажларга кайткач, ирләр тынып калдылар. Уен-көлке белән окоп казып, сугышырга әзерләнеп йөрүләренең юк эш икәнен аңлый башлаган кебек иде алар. Ә сугыш – сугыш икән шул. Уен эш түгел. Башның хакы монда өч тиен дә тормый, юкка чыга да куя икән...

Дүртенче ноябрьдә аларны төнлә тревога белән торгызып чыгарып тезделәр дә, исемлек буенча барлап чыккач, җәяүләшеп, кар ерып урман юллары аша көнчыгышка алып киттеләр. Егерме–егерме биш градуслы салкында бару баштa авыр булды. Элеккеге урыннарында иллеләп кенә кеше калды. Аларны блиндажлар саен тараттылар да, окопларга ешрак чыгып, күренеп йөрергә куштылар. Фронт бу тирәләрдә ачык диярлек хәлдә калды. Чөнки инде монда немец һөҗүме көтелми, аның барлык көчләре Мәскәүне алыр өчен ыргытылган һәм ул шунда капкынга эләккән бүре кебек китә алмыйча канлы һөҗүмнәр алып бара. Бөтен нәрсәгә үз фикере булган Гыйният калган солдатларны кызганып куйды:

– Нимес безнең моннан киткәнне белеп калса, бу калган халык аңарга бер сәгатьлек кенә, ходай сакласын инде үзләрен.

Калганнар арасында күрше авыл чуашлары да бар иде. Алар киткән татар дусларын елап озаттылар:

– Сестән пашка пес нишлипес инде хәзер. Хушыгыс, пелешләр. Кайтып күрешергә яссын...

Биш көн буена аларга йөкларга җиде сәгать кенә вакыт биреп, урман юллары буйлатып, җәяүләтеп кудылар да кудылар. Зур командирлар юкка чыкты. Алар, күрәсең, машиналар белән киттеләр, кызылармеецлар янында вак-төяк лейтенантлар гына атлый иде. Алар кар ерып тәүлеккә илле чакрым чамасы юл үттеләр. Тик шунысына рәхмәт, төн кунарга һәркөн бер авыл булды. Андагы халык аларны кайнар аш белән каршы алды. Инде андый ашларны чучкаданмы, түгелме дип тикшереп торучы булмады. Басыйр абзыйның аш өстендә «гөнаһны алып ташлау» догасын укуы була, бернichә минуттан аш та юкка чыга.

Юлда атлаганда бернichә җирдә машинага да утырткаладылар. Тик җәяү бару кулайрак иде. Чөнки өсте ачык машинада җилдә ыжгырып бару әчтәге җылыны тиз ала, күн итек кигән аякларның туңуы үзәкләрне өзгәли, машинадан төшеп йөгерәсене китерә. Ике-өч сәгать карлы юллардан бата-чума барган машина өстендә бер-берсенә кысылып, бөрешеп утырган солдатлар өстеннән пар күтәрелә, аларга бәс куна, салкынлык шинель эчләренә кереп, йөрәкләргә кадәр барып җитә, кысып ала.

Шаяру, уен-көлкеләр бетте, халыкны кара, җирән, тагын әллә нинди төстәге сакал-мыек басты. Арада иң куе сакал-мыек Учак Сәләхнеке булып чыкты.

– Син, Учак, үстерүең үстерәсең сакалыңны, берәр атнадан аңа басып йөри башлыйсың бит инде, – диде Гыйният үзенең сирәк кенә сакалын чеметкәләп.

Сәләх тә аптырап тормады:

– Бу куу белән кусалар, битеңә түгел, арт ягыңа да үсәр әле ул.

Юлга чыкканнарына алты көн дигәндә зур гына бер урыс авылына килеп керделәр. Көянтә-чиләк күтәреп урам буйлап барган урта яшьләрдәге бер хатыннан сорадылар:

– Какая деревня, тетка-а?

– Волга, родимые, Волга.

– Как Волга?

Марҗа солдатларга күзләрен майландырып елмайды:

– Авылыбызның исеме шулай, Волга.

Монда Волга елгасының башланган җире.

Сафлар эчендә татарлар шаулашты:

– Иделнең башы, ди бит бу марҗа.

– Карале, әй, туган якларга якынлашабыз түгелме соң, алай Идел булгач...

Барысын да саф белән китереп, класс бүлмәләренә күп итеп салам тутырылган авыл мәктәбенә урнаштырдылар. Күрәсең, болар килгәнче бу мәктәп бинасы аша күп халык үткән булгандыр. Чөнки салам тапталган, оешкан, аның арасында байтак тәмәке төпчекләре аунап ята. Икенче көнне иртән аларны алып чыгып тагын сафларга тезделәр дә авылдан ерак булмаган окопларга илтеп тараттылар. Землянка эчендә битләрен сакал-мыек, үзләрен бет баскан аз санлы солдатларны күреп, килгәннәрнең башын шомлы уйлар биләде. Землянкадагы сәндерәләрдә алмаш көтеп яткан солдатларга ике дөнья бер морҗа иде. Алар көн-төн сугышудан, ачлыктан, немец һөҗүменнән шулкадәр туйганнар ки, хәтта тылга чыгып китүләренә дә әллә ни зур шатлык күрсәтмәделәр. Чөнки беләләр, өч-дүрт көн үтүгә аларга яңа солдатларны өстиләр дә тагын фронтның бер янган тишегенә илтеп тыгалар. Бер атнага элгәрәк киттең ни бу дөньядан, соңрак ни, язмыш аларны барыбер яшәтми инде. Шунлыктан, аларга бу дөнья вакытлыча гына. Шулай да солдатларның берсе, землянкадан чыгарга боерык булгач, үзенә бер кисәк ипи сузган Гыйнияткә немец автоматы белән ике обойма патрон һәм авылда бәрәңге изә торган тукмакка охшаган озын саплы өч гранат бирде:

– Тот! Исән калсаң – сугыш!

Яңа урында, землянка сәндерәләрендә урнашканда Сәйфулла Лаваренко дигән украин кешесе белән бергә туры килде. Кырыкны узган, зур гәүдәле, җырлагандай итеп моңлы сөйләшә торган бик таза кеше иде ул. Хохоллар кебек азрак «о»га басым ясап сөйләп тә китте:

– Мин үзем Бирски өязеннән, Мишкә районыннан. Сигез балам бар. Тик менә бу сугыш комачау итте аларны үстереп бетерергә. Зурысына унҗиде тулып килә, кечесе өч айлык. Аякларым аютабан минем, тиз йөгерә алмыйм.

Ул Сәйфулладан кем икәнлеген сорашты да тәкъдим итте:

– Әйдә, бергәрәк булыйк. Мин 1928 елда Кытай белән булган сугышта катнаштым. Байкал артында. Командующийдан алган бүләгем дә бар.

Сәйфуллага шикле күзләре белән карап торгач, сагая төшкән тавыш белән сорады:

– Син беләсеңме, кем иде анда безнең командующий?

– Юк, каян белим инде мин аны. Мин укырга да бик чамалы. Грамут юк бит минем.

– Шулаймы? Ярар, бик әйбәт. Белмәгәнең хәерле, икебез өчен дә.

– Кем булып сугыштың анда?

Лаваренко пышылдауга күчте:

– Пулеметчы идем мин, «максим» дигән пулеметта.

Сәйфулла да нигәдер сагая төште.

– Нигә пышылдап сөйләшәсең?

– Белеп калсалар, хәзер пулемет артына яткыралар монда. Ә мин сугышканрак солдатлардан белештем – немецның минометлары бик күп икән. Шулардан мина очырып, иң башта пулеметларны юк итә икән. Бик осталар ди немецлар минометтан атарга. Ә миңа исән-имин кайтырга кирәк, балалар күп минем. Аларны бит үстерергә, кызларны кияүгә бирергә кирәк. Озакламый немец тагын һөҗүмгә күчәчәк. Киткән солдатлар әйтте. Безгә ничек тә исән калырга иде. Ә пулеметчылар иң тәүгеләрдән һәлак булачак...

Иртән взвод командиры белән Лаваренко арасында ызгыш чыкты. Сәйфулла белән Гыйният взводка тиешле ботканы кухнядан күтәреп кайтып җиткәндә Лаваренко белән лейтенант арасында җәнҗал башланган иде инде. Лейтенант Прохоров каты тавыш белән Лаваренкога боерык бирә:

– Кабатлап боерам, мин кушканны йөгереп үтәргә тиешсең!

– Йөгерә алмыйм мин, иптәш лейтенант! Аютабан мин. Поход белән килгәннән соң чак йөрим, ике аягым тәүлек буена сызлый.

– Мин сине ничек терелтергә белермен, симулянт! Йөгер хәзер үк!

Лаваренко авыр итеп көрсенде:

– Булдыра алмыйм.

Лейтенант кобурасын ачып пистолетын чыгарды:

– Боерыкны үтәмәгән өчен Советлар Союзы исеменнән...

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН

Арыслан йөрәкле нәфис зат

Кыш азагында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, мөгаллимә, музыка белгече, журналист Филүсә Арслан матур гомер бәйрәмен билгеләп үтте.

Әмма күпме тырышсак да, редакциябезнең күптәнге дусты Филүсә ханым белән күрешеп, юбилеена мәкалә чыгару бәхетенә ирешеп булмады. Вакытым тыгыз, туган көнемә бүләк әзерлим, дип акланды. Ә күптән түгел редакциябезгә балкып үзе килеп керде. Кулында калын гына китабы да бар. Ф.Арсланның музыка проблемалары һәм күренекле җырчы, музыкант, композиторлар турында китаплар язганы газета укучыларыбызга мәгълүм, әлбәттә. Яңа гына табадан төшкән китабында да шулай ук музыкаль мирасыбыз тупланган. Ул элеккеләренә караганда да саллырак. «Моң эчендә асылташ» дип исемләнгән мәҗмуганы чын мәгънәдә татар музыка энциклопедиясе дип әйтергә мөмкин. Биредә авторның төрле елларда матбугатта басылган иҗат портретлары, әрнеп язылган мәкаләләре урын алган. Барысын бергә җыйсаң, XX гасыр музыка сәнгате бик җанлы булып күз алдына баса. Ф.Арслан геройларының байтагы фани дөньяда юк инде. Китап музыка сәнгатендәге зур шәхесләребез белән «очрашырга» мөмкинлек бирүе белән кадерле. Тыштан тыйнак, салмак хәрәкәтле күренсә дә, чынлыкта, Ф.Арслан эштә бураннар уйната. Аңа тынгысызлык, үҗәтлек, башлаган эшен ахырына җиткерү хас. Республикабызда Ф.Арсланның аягы басмаган берәр архив бармы икән? Китапта еллар буе архив фондларыннан тупланган сирәк фактлар, уникаль фотоматериаллар урын алган. Менә нинди бүләк турында әйткән ул! Бушка мактану булыр, дигән сыман, юбилей мәкаләсен китабы өлгергән вакытка калдыруы да галимәнең эш сөючән кеше булуына бер мисал.

Филүсә ханым Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты гына булып калса да, милләтебезгә зур файда китерер иде. Аның саф татарча яңгырашлы, аһәңле тавыш белән башкарылган җырлары бүген дә Татарстанның аудиофондында саклана. Башкортстанның Яңавыл районы Асауды авылында ишле гаиләдә туып-үскән кыз өчен татар сәнгатенең йөзек кашы булган ансамбльдә җырлау да олы мәртәбә, зур җиңү түгелмени? Әмма ул барган юлында тукталасы килмичә, Казан мәдәният һәм сәнгать институтына укырга керә. Аннары күренекле хормейстер Җәвид Абдураим улы Котдусов талантлы, эзләнүчән кызны консерваториянең хордирижер бүлегенә керергә әйди. Консерваториянең дүртенче курсында укыганда ук, Ф.Арслан Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтына укытырга килә һәм берничә дистә ел яшьләрне хор белән җырлауга өйрәтә. Аннан киткәч, музыка өлкәсендә мәгърифәт тарату эшен Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы фольклор үзәгендә дәвам итә, татар телендә хор белеме буенча программалар төзи, музыка дәреслекләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Музыка белгече Ф.Арсланның иҗат бакчасында иң саллы җимешләрнең берсе – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең 70 еллыгына әзерләнгән китаптыр.

Ансамбль тарихындагы бердәнбер китапны Филүсә ханым 1970 еллардан бирле, кырык ел буе күңелендә йөртә. Бик яратып эшли. Беренче канат куйган коллектив аңа ата-әнкә кебек кадерле. Ансамбль тарихында ничә җырчы, биюче, концертмейстер, оркестр музыканты эшләсә дә, бары Филүсә Арсланның гына китап язу кулыннан килгән икән. 1970 елларда җыр һәм бию ансамбленең байтак ветераннары исән була әле. Ф.Арслан 1930 елларда эшли башлаган Салих Әхмәров һ.б. ветераннар, әйтик, Нажия Гатиятуллина, Мансур Гатиятуллин, Сөләйман Йосыпов, Мөршидә Сафиуллина белән очраша. Китапта коллектив тормышындагы һәр чорның үзенчәлеге бирелгән, гастрольләр турында бай мәгълүмат тупланган. 70 ел буе халкыбызга хезмәт иткән ансамбльнең һәр афишасы, һәр фотосурәте зур кыйммәткә ия. Филүсә ханым шуларны бөртекләп җыйган.

Ф.Арслан кебек рәхмәтле шәкертләр сирәк очрый. Ансамбль тарихыннан соң ук, ул мәдәният һәм сәнгать институтында остазы Җәвид Котдусовның 80 яшьлеге уңаеннан китап нәшер итә. Җәвид әфәнде – халык дошманы баласы дип гаепләнеп, байтак җәбер-золым татыганга нибары 46 яшендә фани дөньядан киткән талантлы җырчы Шәфыйка Котдусованың улы, алтмыш елдан артык гомерен Татарстанда хор артистларын, хор дирижерларын тәрбияләүгә багышлады. Рәхмәтле укучысы монографиядә аның тормыш хәлен дә, фәнни мәкаләләрен дә, үзенең истәлекләрен дә туплап чыгарды.

Моның белән генә чикләнмичә, әнисе Татарстанның атказанган артисты Шәфыйка Котдусова турында аерым басма әзерләп, бөтен нәселләренең фаҗигале язмышын бәян итте. Олыгайган көнендә Җәвид Абдураим улы туган җире Кырымга кайтып китә һәм ул фани дөньяны ташлап киткәнче шәкерте Кырымда, Симферопольдә эзен суытмады. Еш йөри торгач, Кырым һәм Идел-Урал татарлары арасында багланышларны, андагы мәчет, мәдрәсәләр тарихларын өйрәнеп, тагын бер китаплык бай материал туплады һәм аларны укучыларыбызга ирештерде.

Мәгърифәт тарату эшен алга таба дәвам итеп, музыка белгече Ф.Арслан консерваториядәге остазы күренекле хор дирижеры, мөгаллим Әзһәр Абдуллинның фәнни хезмәтләрен, мәкаләләрен һәм үз истәлекләрен туплап китап бастырды. Әзһәр ага озак еллар консерваториядә шәкертләр тәрбияли, татарча җырларга өйрәтә. Композиторыбыз С.Сәйдәшев иҗатын торгызуга күп көч куйган кеше ул. Мәсәлән, «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе», «Наемщик», «Сүнгән йолдызлар» спектакльләренә иҗат ителгән музыкаларын яңадан халыкка кайтаруы белән татар сәнгать, мәдәниятендә гасырлар үткәч тә җуелмаслык тирән эз калдырды. Татар радиосына Сәйдәшев музыкасын яздырырга Мәскәүдән бригада килгәч тә, аранжировка эшләргә Ә.Абдуллинны чакыралар, бу җаваплы эшне бүтән берәүгә дә тапшырмыйлар. Ул гына Сәйдәшнең һәр интонациясен, һәр фикерен аңлый, диләр. «Эшче» беренче татар операсыннан Нигъмәт ариясен дә бары Ә.Абдуллин белән яздырганнар икән, димәк ул Габәши, Әлмөхәммәдов, Виноградов заманындагы музыканы да тоемлаган. Күренекле дирижер Натан Рахлин аның турында «Мөкәммәл ишетү сәләтенә ия беренче татарны очратам», дип тикмәгә генә әйтмәгән. Ләкин бездә кеше кадерен беләләрмени? Кагылгач, Ә.Абдуллин вакытсыз арабыздан китеп барды. Аннан соң консерваториядә милли җанлы хор дирижеры булганы юк. Көллияттә татарча җырларга өйрәнгән яшьләр дә консерваториягә килгәч татар моң, аһәңен оныта. Китабында Филүсә ханым әнә шуларны әрнеп язды.

Галимәнең тагын ике китабы хор белән җырлау нигезләрен

өйрәтү программалары, хор өчен халык җырлары, композиторлар әсәрләрен үз эченә ала. Татар хорларының аз булуына йөрәге әрни аның. Аларны җитәкләрдәй милли кадрлар юклыгына җаны сыза. Аз сандагы татар коллективларының да чиркәү хорлары сыман җырлавын ишетеп ничек тыныч калсын белгеч? Дәүләт дәрәҗәсендәге профессиональ хорыбыз була торып та һәм аны тотуга байтак акча сарыф ителүгә карамастан, репертуарында татар җырлары мактанырлык күп түгел бит. Татарстан акчасына яшәгән коллектив барыннан да бигрәк милли репертуарны ирештерергә тиеш түгелмени? Әллә татар халкының хор сәнгате юк дип уйлыйлармы? А.Ключарев, Ә.Фәйзи, Х.Вәлиуллин башка композиторларыбызның музыкалары, халык җырларыбыз ник күпләп башкарылмый? Аеруча балалар хор коллективлары борчуга сала. Аларның чыгышларында балаларга хас яңгыраш, самимилек, яктылык, темперамент ишетелми-сизелми диярлек. Укытучылары инглиз, алман телендә җыр өйрәтсә, тел белгече чакырып, җырның һәр иҗеген, сүзен дөрес яңгыратырга тырыша. Инглиз, алман бөек тә, безнең татар бөек түгелмени? Ни өчен балалар хор коллективлары татар җырларын «әйдә, ярар» дип кенә башкара, газиз телебезне гарипли, мыскыл итә? «Сөям» сүзе урынына ниләр генә җырламыйлар! Тыңлавы оят. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле мәктәбен үткән музыка белгече Ф.Арслан, әлбәттә, бу хәлләргә битараф кала алмый, күңелен тырнаганнарның һәммәсен китапларында ярып сала.

Галимәнең кызыксыну даирәсе хор сәнгате белән генә чикләнми, гомумән җыр башкаруны эченә ала. Композиторларыбызның әсәрләрен һәм бигрәк тә татар халык җырларын кем ничек булдыра, шулай башкаргач, алар танымаслык үзгәрде. Татар җыр башкару мәктәбен кайтарырга, аның фәнни нигезләрен эшләргә кирәк, дип галимәбез күп еллар инде җан атып йөри.

Музыка белгече Ф.Арсланның Тукай энциклопедиясендә «Тукай һәм музыка» бүлегенең редакторы буларак кырыклап мәкалә язуы, биниһая язмаларны тәрҗемә итеп, редакцияләп басма өчен әзерләве үзе генә дә нинди зур эш!

Галимә, мөгаллим буларак Филүсә ханым эстрада сәхнәсенә килгән яшь буынның азынып-тузынып, әтәч тавышлары чыгарып йөрүенә дә битараф кала алмый. Затлы классик музыканың кадере югалмаса, яшьләребез шулкадәр түбән дәрәҗәдә булмас иде, дип һәр мәкаләсе саен чаң кага. Италиядә урамдагы юл салучыларга кадәр опера арияләрен җырлый белә, чөнки анда бәләкәй чактан опера сәнгатен өйрәтәләр, дип мәдәният җитәкчеләрен аңга китерергә тели. 1933 елда ук бөек җырчы Федор Шаляпин бер хатында Американың һәр авылында оркестр булуы турында язган, дип затлы музыкага күбрәк игътибар итәргә чакыра. Башкортстанның һәр музыка мәктәбендә курайда уйнарга өйрәтәләр, гомуми белем бирү мәктәпләрендә беренче сыйныфтан Башкортстан мәдәнияте дәресләре укытыла, дип мәдәният һәм мәгарифнең берләшүенә әйди. Нәфис бу затның кыю рәвештә фикерен белдерүенә ничек сокланмыйсың?!

Төкерекләр чәчә-чәчә, ялкынлы чыгышлар ясаучы галимнәребез бар. Ф.Арслан бүтәнчәрәк. Ул беркайчан тавышын күтәрмәс, берәүне дә рәнҗетмәс. Мөгаллимнәргә хас күркәм сыйфатлар, затлылык аның канына сеңгән. Музыка белгеченең әдәбе, урынына туры китереп сөйләшә белүе, киенү-ясанудагы зәвыгы, җыйнаклыгы да күпләргә үрнәк булырлык.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
24 июнь
№24, 2022

ТУРЫ СҮЗЛЕ

Ниһаять, көтеп алынган ямьле җәй җитте. Табигатьнең яшәргән чагы. Гүзәл җәй аенда дөньяга килсә дә, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының күренекле артисткасы Әлфия Хәсәнованы уйлаганда, күзгә көн күз алдына баса да, бер вакыйга искә төшә. Ел саен сентябрьдә уза торган К.Тинчурин исемендәге театр фестиваленең берсе заманча драматургиягә багышланып, анда язучылар Шамил Идиатуллин, Олжас Җанайдаров белән очрашулар оештырылган иде. Әлфия Хәсәнова турында, кырыс холыклы, гаделсезлеккә карата аяусыз, дигәннәрен элек тә ишеткән булгалады. Сентябрь очрашуларының берсендә исә Әлфия ханымның шул сыйфатына шаһит булырга туры килде. Россия театрларында әсәрләре шаулап барган кунак егетләрнең теле телгә йокмый, авызларына каратып тоталар. Очрашулар тыныч, тәти генә үткән булыр иде, берничә артистыбыз башлап сүз алмаса. Барыннан да бигрәк нәкъ менә Ә.Хәсәнованың чыгышы истә калган. «Яңа драма, дигән булып дөньяның бөтен шакшысын сәхнәгә күтәрү килешә торган эшме? Тормышта әшәкелек болай да җитәрлек ләбаса! Нигә геройларыгыз урам телендә, сүгенү сүзләрен кыстырып сөйләшә, нигә телне яклау урынына, чүпләүгә юл куясыз. Олжас энем, ни өчен Казахстан тормышыннан милләттәшләрең турында матур әсәрләр иҗат итмисең? Ватандашларыңа синең казахча язылган әсәрләрең кадерлерәк бит. Яңа драмаларың үз ватаныңда куелмый диярлек. Сәбәпләрен үзең дә беләсең булыр», – дип сорауларны бер-бер артлы тезде артистка. Үз гомерләрендә байтак очрашуларда чыгыш ясаган язучы дөрес сүзгә җавап таба алмыйча каушап калды...

Бүген Әлфия ханымның гомер бәйрәмендә нәфис иңнәренә, кыз баланыкы сыман кечкенә назлы кулларына, нечкә йөз сызыкларына игътибар иттем һәм батыр йөрәгенә соклану тагын да артты. «Гомерем буе «ә»гә «ә», «җә»гә «җә» дип яши алмадым, чөнки мин бу дөньяга су өстендә күбек сыман агу өчен килмәгән. Аллаһ безгә аң индергән икән, без фикеребезне курыкмыйча әйтергә тиеш. Алдан тартучы, арттан этүчем булмады, шулай да әйтәсем килгән сүземне һәрвакыт кәнфит кәгазьләренә төрмичә генә җиткердем», – дип Әлфия ханым үздерен әйтеп куйды.

Аңа дөреслекне сөю хисе башкаларга караганда артыграк бирелгән, күрәсең. Әти-әнисенең дә өлеше зур. Әнисе – авылларында беренче мөгаллимә, 46 ел укыткан. Әлфия туган авылы Чәбки-Сабада башлангыч белемне әнисеннән алган. Әтисе – беренче колхоз рәисе, 50 ел коммунист булган, ә элеккеге коммунистлар хәзерге чорныкыннан нык аерылган. Шуңа күрә кызлары да ялганны күтәрми, бер ялган икенчесен тудыра, ялганчыны кызганам, ди. Гаиләдә биш ир туганына бердәнбер сеңел булып кадер-хөрмәттә үскәнгә, аңарда иркәлек тә бардыр. «Иркәлекне бәреп чыгарыр өчен, Аллаһ миңа каршылыклар китереп тудырадыр. Җырчы Вафирә Гыйззәтуллинаның бер җыры гел истә: «Җиңел килгән бәхет бәхетмени? Җиңел алган бәхет кадерле», – дип җырлый иде ул. Нәкъ миңа атап җырлаган, диярсең. Каршылыклар аша килгән бәхеттән тәм табып яшәүче кеше мин», – дип Әлфия ханым фикерен тәгаенли төште.

Ул сөйләгәндә бүлдерәсе килми, аның кебек төзек сөйләүчеләрне сирәк ишетәсең. Теле искитмәле тәмле, мантыйгы көчле. Мәдәният һәм сәнгать институтында укыганда ук сөйләм теле укытучысы, күренекле артисткабыз Асия Хәйруллина Ә.Хәсәнованың шигырь укуын аеруча яраткан. Бүген дә Әлфия ханымның шигырьләре бәгырьгә үтә. «Елак» шигырьләр, сөю-сагышлы туры куплетлар аның холкына туры килми. Милли каһарманнарыбыз, милләт, республика, туган телебез турында әрнеп язылган шигырьләрне ярата. Сибгат Хәкимнең «Бер горурлык», Георгий Ибушевның «Телең бетсә» шигырьләре Ә.Хәсәнова башкаруында Ютубка язылган һәм аларны тыңлаган саен күңелеңдәге ялкынга көч өстәлә сыман.

Ә.Хәсәнова хәзерге яңа драма авторларын бәреп егарлык язучы булырга мөмкин иде. Әнисе Мәгафүрә апа Әлфиясен укытучы, йә булмаса журналист итәргә теләсә дә, нияте тормышка ашмый. Кечкенәдән башбирмәс булып үсә кызы. Башта туган авылларыннан чакрым ярым ераклыкта урнашкан Сатышка кино караргга качып китә торган була. Йөгереп бара, йөгереп кайта, әнисе кызының киноганга баргавын сизми дә кала. Спектакльләр карарга исә Мәгафүрә апа кызын үзе ияртә. Бүтән балаларны тамашаларга кертмиләр, укытучы баласы булгач, Әлфиягә бәхет елмая, иртәгәсе көндә спектакльгә качып кергән укучыларны «линейка»да чыгарып сүккәндә дә, Әлфиягә эләкми. Шул елларда ул Исламия Мәхмүтованы «Чит кеше баласы» спектаклендә күреп кала һәм аның алма кебек тулган битләрен бүгенгедәй хәтерли. Соңрак исә Исламия Мәхмүтова һәм Әлфия Хәсәнова бер бригадада гастрольләрдә йөриячәк... Ә бер көнне Казанга артистлыкка укырга качып китә. Еллар үткәч, әнисе кызының һөнәре белән килешәчәк. «Театрда эшләвең белән бәхетлесең, кызым, син йөргән юлларны акча түләп барып карыйлар, шулай да син йөргән кадәр узып бетерә алмыйлар», диячәк. Баксаң, үзе дә яшьлегендә артистка булырга хыялланган икән...

Ә.Хәсәнованың тимергә чүкеч белән суккандай чатнап чыккан һәр сүзендә рух ныклыгы сизелә. Ул сөйләгәннәрдән көченең чыганагын эзлим.

«Адәм баласына көч туган җир туфрагыннан, табигатьтән килә. Авылыбыз кечкенә генә булса да, оҗмах бакчасыдай гүзәл бер урында урнашкан. Бакча башында гына Мишә елгасы. Кояш чыгышында Кытай, Баварна таулары. Аларның итәкләре кып-кызыл җиләк белән тулган. Тау башына менеп «э-һә-һәй» дип бер кычкырсаң, әллә каян яңгырап әйләнеп кайткан тавышың да сиңа көч бирә. Бүген дә табигатьнең билгеләрен тоеп, файдаланып яшәргә тырышам», – дип Ә.Хәсәнова туып-үскән җирен тәмләп сурәтләде.

Язмыш җилләре актрисага бөтенләй кагылмаган, битеннән үбеп, чәчләреннән иркәләп кенә үткән кебек. Чибәр хатын-кызлар шулай көчле, кою була, күрәсең. «Гүзәл табигать почмагында туып та, ямьсез булу мөмкинмени? Безнең авылда бөтен кеше матур», – дип куя Ә.Хәсәнова. Шулай да Гаделбану әбисе бөтен авыл халкыннан да чибәррәк булган, күрәсең, юкса ул килен булып төшкәч, кояштә-чиләк асып – суга, кер чайкарга төшкәндә, күрик әле, дип артыннан җыелышып төшмәсләр иде.

Заман адәм баласын үзе шулай кырысландырадыр, бәлки. Хәзер кырыс кешеләр заманы. Елап, күз яше агызып утырганы өнәмиләр. «Көчсезлектән елап утыра икән, димәк, ул кешенең кыйбласы, умыртка баганасы юк», – дип әйтеп куя Әлфия ханым үзе дә.

«Абыстай булмасам да, динебезне хөрмәт итәм, изге Коръәндә язылганнарны үтәргә тырышам, ураза тотам, намаз укыйм. Әмма ялгышкан чакларым да була. Спектакльдән әсәрләнеп кайтканнан соң, мәсәлән, озак вакыт үзеңне кулга ала алмыйсың, тәртәгә кереп булмый. Теләкләрең тормышка ашмаса, күңелне чарасызлык, көчсезлек, ачыну билән ала. Бу да – хаталануның бер билгесе. Бүгенгесе үтәлмәсә, иртәгә, аннан ары ялварганың кабул булыр, дип ата-бабаларыбыз өметне югалтмаска кушкан», – дип Ә.Хәсәнова диндарлык мәсьәләсен дә бераз шәрехләп үтә.

Әти-әнисе дә аңа әйбәт сабак биргән. «Бер кайтып елаганда әнием, син нәрсә, үзеңне кем баласы икәнеңне оныттыңмы, кем каны акканын белмисеңме», диде. Әйтергә онытып торам икән, әтием – сугыш ветераны, разведчик. Беренче һәм икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары кавалеры, Ленинградны яклап сугышканы өчен медаль белән бүләкләнгән. Миндә данлы ата-бабаларымның каны акмыймыни?! «Күз яше түгеп утырасы түгел. Менә сиңа акча, билет, әнә Мәскәү, шунда барасың да, дөреслекне йолып алып кайтасың», – диде әнием шул чагында. Һәм чыннан да, дөреслекне таптым. Әниемнең сүзләре исә гомерлек сабак булды», – дип үткәннәргә кайтып сөйләде әңгәмәдәшем.

«Ә иң зур көч үземне рәнҗеткән итеп сизгәндә, көчсезлегемне тойганда барлыкка килә, – дип тә өстәде. – Рәнҗетүчеләргә җавап итеп көчемне исбат итәсем килә. Табигать тә шулай бит. Яшен яшьнәп күк күкрәмәсә, җир кабарып китми, чикләвекләр уңмый, җир белән күк кавышмаса, яшәү булмый. Күк күкрәтеп яуган яңгырдан соң дөнья икенче төрлегә әйләнә, җиргә көч иңә. Мин дә шулай...»

Аннары үткәннәргә кайткандай, уйга бирелеп, шигырь сөйләп китте:

«Җир белән күк
бергә кавышкандай,
Иреннәрең тиде иренемә.
Акыл белән яшьлек
бергә килми,
Кайтыр юллар да юк кирегә.
Ә иреннәр синсез тилмерә...»

Бу шигыре тәүге сөю турында. «Күк күкрәп, яңгыр яуса, шул шигырь искә төшә», – ди. Аннан соң байтак еллар үтеп, исәпсез-сансыз яңгырлар яуса да, күңелнең бер читендә шушы нәни генә шигырь калган икән, беренче саф хисләр, ярсу мәхәббәт кебек, ул да авыр чакларда бер юаныч булып көч өсти, күрәсең...

Актриса Ә.Хәсәнова тормыш арбасына җигелеп япа-ялгыз калганда, улына нибары сигез яшь була. Бүген Искәндәр – бөтен тирә-юнь кызыгырлык чибәр егет. Аракы эчми, тәмәке тартмый. Әнисе кебек үк бер рус сүзе кыстырмыйча, тәмләп татарча сөйләшә, төрек, инглиз тел-

СӘХНӘ ОСТАСЫ

● «Өметсез хыяллар» спектакленнән күренеш.

ләрендә иркен аралаша. «Тыштан кырыс булсам да, улымны бик яратып үстердем. Яратып баланы бозып булмый, бала игътибар җитмәүдән бозыла. Улымны кечкенәдән үз-үзенә ышанырга, мөстәкыйльлеккә өйрәттем, кемнеңдер аяк астында чүпрәк булуын теләмәдем. Шуңа күрә укырга да үзе керде, эшкә дә үзе урнашты», – дип шатланып туя алмый Әлфия ханым.

Нәселеңнең нык, ышанычлы булуы үзе көч бирә. Һөнәреңне дәвам итүче туганнарың булуы исә икеләтә шатлык, мәртәбә. Ә.Хәсәнова «Голос» бәйгесендә җиңгән күренекле җырчы, туганының кызы Эльмира Кәлимуллина белән горурлана. Туганнан туганының оныгы Нәргизәнең «Апуш» беренче татар балалар театр труппасында спектакльләр уйнавы, йолдыз булырга хыяллануы шулай ук йөрәгенә сары май булып ята.

Һәм, әлбәттә, театр, спектакльләр, рольләр Ә.Хәсәнованы көчле итә. Туфан Миңнуллин әсәре буенча куелган «Кырларым-тугайларым» спектаклендә Мөслимә, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә Сәлви, Зөбәрҗәт, И.Грековның «Тол хатыннар көймәсе»ндә Аида, К.Тинчуринның «Американ»ында Разия, «Җилкәнсезләр»ендә Оркыя, «Назлы кияү» спектаклендә Шәмсия, А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ендә Хәдичә һ.б. рольләр һәркайсы күңелне җылытып, яңа үрләргә илһамландырып тора. 1979 елдан башлап 43 сезон эчендә башкарылган рольләрне санап бетерә торган түгел. Әле шуларга телефильмнардагыларын, әйтик, Аманулланың әсәре буенча төшерелгән «Кешечә яшик» киносында Саимә, Р.Шәрифнең «Яланаяклы кыз» күп серияле фильмындагы Сәгыйдәне һ.б. өстәсәң, артистка Ә.Хәсәнованың иҗат бакчасы бик бай, мул җимешле булуын күрербез. Әлфия ханым һәрвакыт чибәрлеге, эчке мантыйкка һәм нечкә сиземләүгә корылган камил сөйләме, артистлык осталыгы, шәп тавышы белән сәхнәбез күрке иде. 43 сезон милләтебезгә тугрылыклы хезмәт иткән артисткабызның әлегәчә «атказанган» булып йөрүе, биш тапкыр тәкъдим ителеп тә, «Татарстанның халык артисты» дигән лаеклы исемгә ия булмавын бары гаделсезлеккә битараф калырга ирек бирмәгән рухи көчennән һәм талантларыбызны кадерли белмәүдән күрергә кирәктер. Куштаннарны түгел, тыйнак кына үз эшләрен башкаручыларны, яки Ә.Хәсәнова кебек бернәрсәгә карамастан дөреслекне яклаучыларны бәяли, кадерли башлаган көн милләтебезнең вакчыллыктан арынып, элекке затлы исемен кайтаруга юл алган көне булыр, мөгаен. Әмма аңа кадәр гадел, туры сүзле, талантлы иҗатчыларыбызның Ә.Хәсәнова кебек байтак каршылыклар кичәкичә күп көч туплыйсы бар әле...

Ләкин актриса бернигә дә карамастан тормышыннан тәм табып яши. Әле күптән түгел Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган рекламага төште. Кинога төшәргә чакырулы. Өченче елны мөселман киносы халыкара фестивалендә «Тамашачы мәхәббәте» дипломына лаек булган «Үксезләр» фильмын да әле бөтен сәнгать сөючеләр күреп өлгермәгәндер.

Сүз башына кайтып, әңгәмәдәшемнән татар театрының бүгенге хәле турында фикерен сорыйм.

«Республикабызда театрлар күп, һәркайсының еллар буе калыплашкан традицияләре, тамашачысы бар, – дип башлады ул сүзен. – Хәзер театрларыбызга чикле генә вакытка килеп, режиссерлар төрле тәҗрибәләр үткәрергә һәвәсләнде. Ләкин бездә буш торган заллар хәттин ашкан. Нигә эксперимент

● «Алтын көз» спектакленнән күренеш.

яратучы режиссерларга буш залларны файдаланмаска? Нигә гасырлардан килгән мирасны, гореф-гадәтләребезне җимереп, йөзьяшәр мактаулы татар театрының асылын үзгәртеп, бөтенләй бүтән якка алып кереп китәргә? Шушы глобальләшүгә барган заманда безгә, киресенчә, аһәңле телебезне, гадәт-йолаларыбызны күрсәтә торган тамашалар куеп, бөтен төрки дөньяны шаулаткан элеккеге даныбызны кайтару кирәк. Ата-анасын хөрмәт итмәгән кеше хөрмәткә лаек булмаган кебек, традицияләрне саңга сукмаган режиссерларның да киләчәктә уңыш казануы бик икеле. Мин бу хакта фикерләремә белән мәдәният министрлыбыз Ирада ханым Әюпова белән уртаклашыр идем. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та, Россия илбашы Владимир Путин да артистлар белән очрашулар үткәреп, әледән-әле хәл-әхвәлләрен белешеп тора. Шундый очрашулар министр белән дә оештырылсын һәм анда кыю рәвештә фикерен әйтә алган артистлар, иҗат әһелләре катнашсын иде...»

«Тәҗрибәләр үткәрмичә генә, яшьләрне театрга ничек җәлеп итәргә», дигән булам.

«Тузга язмаган мәзәк сөйләп гомер буе шуның белән тамак туйдыручылар хәттин ашкан. Әмма Рәшит Сабиров, Нәҗия Минкина кебек затлы сүз осталары да бар. Затлы әйберне яхшы итеп сөйлисе була, тузга язмаганны исә ничек сөйләсәң дә ярый, халык көлә, кул чаба. Яхшы киемнеке кебек үк, затлы әсәрнең дә бәясе төшми, югалмый, ул олыны да, кечене дә җәлеп итә. Шулай булгач, нигә яшьләрне арзанлы әсәрләр белән тартырга? Хәзерге яшьләрнең мөмкинлекләре зуррак. Андый талантлар белән гел затлы, яхшы әйберләр генә куясы. Шул чагында спектакльгә түгелгән акча да кызганыч түгел. Бернечә сезон дәвам итәрлек, зур, колачлы тамашалар яклы мин. Яшь буынны затлылыкка ияләштерик. Затсыз нәрсәләр телевизор экраннарында да тулып ята. Бигрәк тә К.Тинчурин театрының якынлашып килгән 90 еллыгын югары дәрәҗәдә олпат татар язучыларының әсәрләре буенча куелган тирән фикерле, милли эчтәлекле спектакльләр белән каршыларбыз дип ышанам...»

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Наполеонның

Бонапарт Наполеонга нисбәтле дип саналган афоризмнарда кыюлык та, нечкә ирония дә, идарәче психологиясе чагылышы да бар. Әйтик: «Әгәр сез армияне йөз арысланнан төзесәгез, ә аларның җитәкчесе эт булса, теләсә кайсы сугышта арысланнар эттәй үләчәк, ләкин әгәр сез армияне йөз эттән төзесәгез һәм аның юлбашчысы арыслан булса, бар этләр дә арысландай сугышачак»; «Җиңүне сан белән алмыйлар. Александр өч йөз мең фарсыны егерме мең македонлы белән җиңгән»; «Дошман хата ясаганда, аңа комачауламаска кирәк. Бу – ихтирамсызлык»; «Мине һәлак итәчәк пуляга минем исем язылган булыр»; «Минем кебек кеше өчен берничә миллион кеше тормышы ни соң ул?»; «Һәрбер солдатның букчасында маршал таягы ята»... 1802-1812 елларда җиңелү белмәгән, кызып китүче, импульсив, дан сөюче хәрбигә бик хас философия бу...

...Англия корабы «Нортумберленд» вертикаль кыяташлы урынга килеп туктый. Мундир сәдәфләре артына кулын тыккан адәм аларга төксе генә карап ала. Атлантика океанындагы Изге Елена хөрмәтенә аталган бу таш табут-утрау шушы көннән башлап аның өчен төрмә булачак. Ватерлоо янында башын салса, яхшырак та булыр иде аңа. Армия тар-мар ителгәннән соң, Америкага качар план кормас һәм «инглиз халкы кануннарына буйсынып яшәргә» дип, Англия белән идарә итүче принц-регентка хат язмас өчен, ул хәзер барын да эшләр иде, ләкин соң инде... Англия – иң куәтле һәм гадел дошман, һәм ул үз карьерасын тәмамлаган сәяси шәхеснең үтенеч кире какмас дип уйлаган шул...

Аңа чыннан да һич каршы килмиләр, ул инглиз корабына утыра һәм Портсмутка кадәр бара, ә анда кораб бортына адмирал Кейт күтәрелә һәм генерал Бонапартка союзниклар тоткыны булачагын һәм Изге Елена утравына озатылачагын хәбәр итеп, рәсми фәрманны укый. Наполеон кунакчыллык кануннары бозылуы хакында тавыш күтәрә, бу карарның илгә кара тап булачагын искәртә. Адмирал җиңелгән императорны җәлләп тыңлый, әмма әмер шул көе кала. Шушы мизгелдән башлап Наполеон – тоткын.

Франциянең элеккеге императоры үзенең соңгы тукталышына юл тота. Ул һәм аның егерме алты хезмәтчесе күп вакыт сөйләшми дә. Һәрберсе үз киләчәге хакында уйлана. Аларның берсе дә Изге Елена утравында тормыш итәчәген күзалламаган бит. Мең солдатлы тугыз кораб саклап барганда, юл утрауга илтәчәк, билгеле, качу турында сүз дә була алмый.

1815 елның 17 октябрендә офыкта утрау күренә. Кораб Джеймстаунга туктый һәм Наполеонны Лонгвуд-хаус җирлегендәге кыялы урынга алып килләр. Бу җирнең үзе өчен кабер булачагын ул бик яхшы аңлый. Аның җилләрне һәм юеш урыннарны җене сөйми. Өстәвенә, Бонапарт әле астмадан да җәфалана. Шунлыктан утрау климаты аның өчен үлем белән бер була. Йортына һәрьяклап җилләр исә. Аның кырында бер үсемлек тә, бер агач та юк – илле ел элек биредә маллар ябып тотканнар. Кыя шулкадәр биек, ул янәшәдә узып баручы болытларны үзенә «эләктереп-тартып» тора, шуңа күрә Лонгвудта һәрчак яңгырлар коя. Коточкыч юешлек йортны черетә бара. Түшәм багананары күгәрек белән капланган, диварлар юеш, түбәне күптән төзеклəндермәгәннәр, ямамаганнар. Наполеон бүлмәләрендә көне-төне камин яна, ләкин хәтта мондый ут та аларны ни җәен, ни кышын җылыта алмый. Китаплар бозыла, аның язмалары череп, юкка чыга бара. Берчак ул Англия хөкүмәтенә: «Сез мине әкрен үлемгә дучар иттегез!» дигән җөмләне әйтеп яздыра. Әмма бу хөкемдар өчен иң авыры – улыннан һәм хатыныннан хатлар ала алмау булгандыр. Утрау губернаторы тоткынның качуыннан куркып, Европадан бер кәгазь дә керттерми. Наполеонга бу да ошамый: «Сезгә минем тормышым белән идарә итү йөкләнде, әмма минем йөрәгем белән түгел. Истә калдырыгыз, йөрәгем бар Европа әмерләремне тыңлаган чактагы кебек үк горур». Тирә-юньдәгеләр аны «галиҗәнап» дип йөртә, ә инглизләр аны «йөкләмәләре булмаган генерал» дип атый. Бу да Наполеонның кәефен боза. «Мин сезгә мондый титул тагарга рөхсәт итмим! Минем өчен тәхет һәрвакыт бәрхет белән тарттырылган агач кисәге булды. Ләкин мин титулны бер күч епископлар тарафыннан түгел, ә француз халкыннан алган Европадагы бердәнбер монарх!» – дип җикеренә ул.

Наполеонның һәр адымы инглиз солдатлары тарафыннан күзәтелә. Аның янына хәл белешергә һәр иртә бер офицер килә. Үз хәле хакында Бонапарт: «Бу Тимерлан читлегеннән дә яманрак», – ди. Һәм шул ук вакытта ул үз язмышын тулысы белән кабул итә. Бу вакыйгалар аның планының бер өлеше, диярсең. «Минем тормышымда бар да булды. Бары бәхетсезлек кенә җитми иде...»

Тоткынлыгының беренче елларында аның көнкүреше сәгатьләргә бүленгән режим белән оештырыла. Уяна, озаклап юына, кырына, мундирын кия, тамагын туйдыра һәм үзе белән алган француз картографы һәм әдәбият белгече Лас Казга берничә сәгать үз мемуарларын әйтеп яздыра. Ул барысын да искиткеч төгәллек белән истә тота – даталарны, һава торышын, һәлак булганнар санын, сугышта батырлыклар күрсәткән генераллар һәм солдатларның исемнәрен, кабул ителгән стратегик адымнарны... Барысын да нечкәлекләр белән тасвирлый. Барлык сугышлар, орышлар аның хәтерендә яши, әйтерсең лә алар әле кичә генә булган. Тулон камалышы, Вандемьер бунты, Италия кампаниясе һәм Мисыр походы, Маренго янындагы орыш, Эльба утравына сөрелү, Йөз көн чоры һ.б. киләчәк буынга язылып кала. Ул тиз һәм өзеп-өзеп кенә яздыра, әйткәннәрен беркайчан да яңадан төзәтми. Лас Каз аның артыннан көч-хәл белән язып өлгерә... Бу мемуарлары өчен хәзер аны XX гасыр кешесе дип тә атыйлар, чөнки ул начар хәбәрләрне яхшы итеп, ә яхшыларын триумфаль итеп күрсәтә белгән дәһи. Ул үзе хакында киләчәк буыннарга калачак дастанны үзе яза. Бу вакыт аның өчен үзенә күрә бер сугыш булып тоела, Лас Каз калын кәгазь төргәген, кульязмаларны күтәреп утраудан киткәч, ул инде аңлый: бу сугышта ул – җиңүче.

Наполеонның хатлары һәм Лас Казның хикәяләре үзенекен эшли – даһины җәфалаучы, аннан үч алучы инглизләр хакында сөйли башлыйлар, ә Наполеонга шул гына кирәк тә. Үзе ул бер дә язарга яратмый һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр француз телендә хаталар белән яза. Һәрвакыт үз янында йөргән көндәлекләренең берсендә үзе хакындагы мондый юллар бар: «Париж хәрби училищесын тәмамлаганда, миңа шундый характеристика бирделәр: «Тәкәббер, ялгызлык ярата, чиктән тыш үз-үзен сөя. Аның үз-үзен сөю чикләр белми». Әнә шул тәкәбберлек аңа хәрби юлны сайларга этәрмәдеме икән?! Аның белән бергә укыган яшүсмерләр Наполеоннан бер сәбәпсез көлгән, мыскыллаган һәм ул алардан өстен чыгар өчен, бик нык тырышып гыйлем җыйган.

...1788 елны булачак император Осонга хәрби хезмәткә китә. Үзенә түләнгән акчаның бер өлешен әнисенә юллый. Бонапарт бик ярлы яши, көненә бер тапкыр гына ашый, әмма үз фәкыйрьлеген беркемгә дә күрсәтми. Шул ук елны Наполеон Госман империясе белән сугышырга теләүче чит ил кешеләрен җыйнаган Россия империясе армиясенә, яхшы хезмәт хакы түләнә торган офицерлык хезмәтенә күчәргә омтылып карый. Әмма шул көнне чит ил хәрбиләренең чины бер дәрәҗәгә түбәнәячәк дигән карар чыга һәм ул моның белән һич килешә алмыйча, әлеге уеннан кире кайта...

Бик вак хәреф белән язылган көндәлекләренең берсендә буш калган диярлек бит бар. Анда болай дип язылган: «Изге Елена, кечкенә утрау. Үлем». Аның үлеменә кадәр... утыз сигез ел кала язылган юллар. Бу табышмак хакында хәзерге галимнәр арасында бәхәс әле дә тынмый. Алдан күргәнме?! Наполеон магнетизмга, оккультизмга, астрологик әйтемнәргә, язмышка ышанган иң. Ни өчен буш битләр калган, бу язма ничек барлыкка килгән... Әлегәчә бу хакта беркем дә төгәл генә әйтеп бирә алмый.

Мемуарлар төгәлләнгәч һәм Лас Каз утраудан киткәч, Наполеон әкрен генә үлемен көтә башлый. Аның бер эше дә калмый. Үз көндәлегенә болай дип яза: «Бу эшлекле тормышның бөтенләй хәрәкәтсезлеккә күчүе мине тулысынча җимерде». Әгәр ул моңа кадәр өч кенә сәгать йокласа, шул арада инде көч җыеп торса, хәзер ул ятагыннан ничек тә соңрак торырга тели. Зәңгәр сукно ябынып ята, күзләре тәрәзәгә төбәлгән. Аннары йорт эчендә, кырынмыйча гына, арлы-бирле йөренә башлый, күлмәк изүе ачык, башында кызыл шакмаклы яулык... Нидер уйлый, исенә төшерә. Аның бик тиз уку сәләте бар. Ул һәрвакыттагыча күп укый, аннан китапларны тартып алучы юк. Алар бар

Соңгы тукталышы

жиргә чәчелеп ята, өстәл өстендә, идәндә... Битләре тузган, юешләр, әмма китаплар императорга беразга гына булса да тынычлык хисе бирә.

Мөмкин булганда, төшке аштан соң урамга чыга һәм шушы күралмас утрауны күзәтә. Ялгызлыкны ул бер дә яратмый, шуңа күрә кичләрен хезмәтчеләре аш бүлмәсенә җыела. Аларның да кыяфәтләре шәүләләр төсле. Җыелышып шәраб эчәләр, узган мәшһүрлекләре турында сөйләшәләр, шахмат, домино уйныйлар, кәрт сугалар. «Тиздән мин онытылачакмын, – ди император. – Әгәр Кремльдә мине туп ядрәсе үтергән булса, мин дә Цезарь яисә Александр кебек мәшһүр булыр идем... Ә хәзер мин беркем дә түгел». Хәрби хезмәтен 16 яшеннән кече лейтенант дәрәҗәсендә артиллериядә башлаган, 24 яшендә генерал булган, 35 яшендә тәхеткә утырган император нишләргә дә белми, ул акылдан шашар дәрәҗәдә... Ул үз үлеме якынлашуын сизә.

Эльбадагы тугыз айлык сөргендә аның алты йөз кешедән торган шәхси сагы һәм утрау императоры дәрәҗәсе бар иде. Ул икътисадны үстерә, юллар төзетә, бакчалар, театр, сәүдәне контрольгә ала, казармаларны төзекләндерә, аның артыннан күзәтергә билгеләнгән инглиз капитаны Кэмбелл Наполеон артыннан йөреп, аяксыз кала... Җирле халык Бонапартны данга күмә! Аның генералларының кайсы министр, кайсы губернатор, кайсы гвардия башлыгы итеп билгеләнә. Аңа 1649 кешедән торган армия һәм сигез кораблы флот буйсына. Теләсә кайсы вакытта ул кунаклар кабул итә ала, аңа почта да китерәләр... Ә биредә, Изге Елена утравында, ул – кеше-шәүләләр белән уратып алынган тере мәет. Аның үзе белән алган агуы да булышмаячак, чөнки саклау вакыты күптән чыккан. Әмма бу агуның тәэсире императорның эчке әгъзалары өчен эзсез үтми. 1817 елны аяклары шешә, уң ягы чәнчи. Утрау губернаторы белән ызгышканнан соң, аңа урамда йөрү тыела, бу да аның сәламәтлеген начарайта. Авыру хакында уйламас өчен, ул тирә-юнендә бакча үстерергә була. Аңа үсентеләр китерәләр, Кытай эшчеләре артелен бирәләр, ул тырышып шушы эшен башлап җибәрә. Чәчәкләр, аллеялар, газоннар, агачлыклар – биредә Версальдән бер дә ким булмаячак! Ләкин яңгыр үсентеләрне черетә, кояш аларның яфракларын көйдерә, һәм Наполеон агач үсентеләрен берничә тапкыр утыртып карап та, уңай нәтиҗәгә килә алмагач, бу уйдан кире кайта. Көннәр буе караватта ауный, укый, йоклый. Авыруы көчәя. Табибләр төгәл диагнозны белми, чирен гепатитка охшаталар. Үзе исә ул моның ашказаны яман чиредер дип шикләнә. Аның әтисе дә шушы чирдән үлгән була. Франциядә Наполеонның авыр хәле турында беләләр һәм дуслары аңа качу юлларын әзерли.

1816 елның мартында дәвалаучы табиб Наполеонга нефрит шахматлар алып килә, Кытайдан бүләк. Аның бер фигурасы эченә утраудан качуның төгәл планы тыгып куелган була. Уйлап табучы Фултонның су асты аппараты утрауга төнлә киләчәк тә, аннары җиде сәгать буе су астында йөзәчәкләр. Аннары качкынны америкалы контрабандист Джонсон корабы көтеп торачак. Иң кыены – йорт сагын узып чыгу гына. Кемдер Наполеонның караватына ятса, сак аны Бонапарт дип уйлаячак. Наполеон бу планнан баш тарта: «Минем тагын унбиш ел яшисем калды. Боларның барысы да кызыгырлык, ләкин бу – акылсызлык. Мин монда үләргә тиеш. Франция мине алырга үзе килергә тиеш...»

1821 елның апрелендә Наполеон күктә комета күрә һәм: «Бу минем арттан», – дип әйтә. Шундый ук комета күктә аның туарына җиде көн кала пәйда булган. Ул инде озак вакыт күңел төшенкелеге кичерә, үлем көтә һәм бар җирдә аның билгеләрен күрә. 15 апрельдә васыятьнамәсен яздырта һәм тынычланып кала – бары да үз чираты белән бара. Табибләр өчен аның үз махсус бирем-үтенече була. Тәнен ярырга әмер бирә, йөрәген алырга, аны спиртлы бокалга салырга һәм Мария-Луизага алып китәргә куша. «Аеруча ашказанымны тикшерергә киңәш итәм һәм аның нәтиҗәләрен бик җентекләп, аңлатып язып, улыма тапшырыгыз... Мин сорыйм, таләп итәм, бу тикшерүләрне бик төгәл итеп башкарыгыз... Бар хакимлек итүчеләргә мин тормышымның шушы соңгы көннәре куркынычын мирас итеп калдырам...»

1821 елның 5 маенда Изге Елена утравы өстендә коточкыч җил чыга. Тәрәзәләрне яңгыр камчылый, давыл агачларны йолкый, үз юлындагы бар нәрсәне себерә. Наполеон аңын югалта һәм саташулы сүзләрне пышылдый: «Баш... армия... Бөек Көч!» 17 сәгать 49 минутта ул тынып кала, күзләре дымлана. Табиб императорның үлемен раслый. Гәүдәсен тар поход караватына салалар, зәңгәр плащ каплыйлар. Аягы янына – шпагасын, күкрәгенә – хач куялар. Аны үзе алдан күрсәткән Яраннар үзәнлегенә җирлиләр.

Соңрак яру нәтиҗәсе аның ашказанында ике җәрәхәт булуын, берсенең үтәли чыгып, бавырга җитүен күрсәтә. Аны бу авыруыннан беркем дә дәваламаган була. 19 елдан соң эксгумация үткәрелә һәм табибләр шакката: аның тәне бәлзәмләнмәгән булса да, бүген генә күмгән кебек сакланган. Шул вакытта фараз да туа: бәлкем, императорга мышьяк биргәннәрдер, чөнки ул гәүдәнең таркалуын тоткарлый. 1961 елны Наполеонның чәчләрендә мышьяк табыла. Әмма иң соңгы нәтиҗәләр ашказанына кан саву, яман чир белән бәйләнә. Аның авырулары бихисап була: кечкенәдән үк эпилепсия өянәкләре, соңрак каты баш авырту, салкынны начар кичерү, тән кычыту, пульс тибеше акрынаю, геморрой, хәлиткеч зур һөҗүм вакытында кинәт кенә йоклап китү галәмәте, соңрак инде аяклары шешү һ.б. Авырулары аның шөһрәте өчен түләнгән бер бәһа дә кебек... Утрауда исә инде сәламәтлеге тагын да начарлана, тозлы ризыклар күп ашала, җиләк-җимешләр булмау сәбәпле, цинга килеп чыга... Психикасы какшый... Үзенә карата игътибар булмау, абруен югалту, утрау губернаторының аның качып китүеннән бик тә куркып, аны күрәлмавы... барысы да моңа сәбәп.

Наполеон кабере 19 ел билгесез булып кала, биредә аның ташына исемен дә чокып язарга рөхсәт итмиләр.

Бонапарт үлеп, ике ел узгач, Лас Каз аның «Изге Елена мемуарлары»н дүрт томда нәшер итә. Бу китаплар XIX гасырның иң күп укылган басмаларына әйләнә һәм бонапартизм идеологиясенең нигезен тәшкил итә.

Шулай да Бонапарт алдан күзаллаучы булып чыга. Франция аны алырга үзе килә: 1840 елны король Луи-Филипп I, үз хакимиятенең абруе, дәрәҗәсе төшкәч, француз халкына императорны кайтарып бирергә була. Императорның соңгы теләген үтәү өчен, ул Изге Елена утравына делегация җибәрә. Император сөякләре салынган табут казып алына һәм Франциягә кайтарыла. 15 декабрьдә тантаналы рәвештә җиргә иңдерелә. Салкын, буранлы көн булса да, аны бар Париж озата. Табутны Франциядәге хәрби тарих һәйкәле булып саналган Инвалидлар соборына куялар. 1859 елны анда 35 тонналы гранит саркофаг та урнаштырыла. Гранитны рус императоры Николай I бүләк итеп юллый һәм: «Наполеон өчен бездә таш һәрчак табылачак», – дип шаярта. Архитектор алсу төстәге рим императорлары ташын озак эзли, әмма алсу ташны таба алмый, алар инде беткән була. Язмыш шаяртуы: таш нибары Россиядә табыла. Саркофаг ике ел иҗат ителә. Саркофагның биек пьедесталы караңгы-яшел граниттан ясала. Кайчандыр Европа язмышын үз кулында тоткан шәхеснең җирләнүе дә башкалардан аермалы: императорның кабере бер-берсе эченә урнаштырылган алты табуттан тора: аларның беренчесе – калайдан, икенчесе – кызыл агачтан, өченчесе һәм дүртенчесе – цинктан, бишенчесе – кара агачтан һәм алтынчысы – имәннән. Аның мәңгелек йокысын унике хәрби кампаниядәге уңышларын күрсәткән, мәрмәрдән уеп ясалган унике Ника (җиңү алиһәсе) сыннары саклый, таш идәндә бу җиңүләрнең кайсы шәһәрләр тирәсендә булуы да язылган...

Наполеонның, имеш, Мисырдагы Зур сфинкска төбәп, туплардан атарга кушуы яисә аның артиллеристларының борынгы сынга атып күнекмәләр үткәрүе хакындагы риваять дөреслеккә туры килмәсә дә, әлегәчә очрый. Имеш, сынның борыны һәм сул колагының яртысы шул рәвешле кителгән... Әйе, 1798-1799 елларда 29 яшьлек Бонапарт Мисырга хәрби экспедиция оештыра. Әмма ул башка мәдәниятләрне хөрмәт итүче була, бу экспедициягә үзе белән 167 француз галимен дә ала һәм алар килеп күп белән үк фәнни эшкә керешә. Каһирәдә Наполеон Мисыр институты төзи, галимнәр борынгы язмаларны өйрәнеп, укып чыга. Берчак поход колоннасына төрек кавалеристлары һөҗүм итә һәм Наполеон: «Ишәкләрне һәм галимнәрне уртага!» дигән легендар командасын да бирә. Аннары 1755 елда 1737 елны ук рәссам Фредерик Норден ясаган рәсем нәшер ителүе һәм бу рәсемдә үк инде Сфинксның борыны булмавы да билгеле. Һәм хәтта Мисыр галимнәре дә шуны раслый: Сфинксның борыны 1436 елда, ягъни Наполеон походына кадәр 362 ел элек үк дини фанатизмга бирелгән бер шәех әмере белән җимертелә...

Гайре табигый хәлләргә килгәндә... Билгеле, тәхеткә утырганчы ук, Наполеон Мисырга килгәч, аның язмышына йогынты ясарлык бер вакыйга килеп чыга. 1799 елның 2 августында Бонапарт Хеопска килә һәм биредә берүзен генә калдыруларын үтенә. Бу мистик урында төн куна һәм аннан иртән генә китә. Ул бик агарган була, тәне калтырый. Сорауларга җавап бирми һәм бу вакыйга турында башка беркайчан да искә төшермәскә әмер бирә. Император белән булган гайре табигый хәлләр моның белән генә чикләнми. Бервакыт, Марсельдә аның янына таныш булмаган бер адәм килә. Ул Наполеонга бик үзенчәлекле таш тапшыра һәм: «Россиягә сугыш белән барма», – дип киңәш бирә. Чинтамани дип йөртелгән теләк үтәү ташы моңа кадәр дә күпләргә бирелгән: Сөләйман пәйгамбәргә, Александр Македонскийга, Кытайның Цинь династиясе императорына, Тимерланга... Әмма Наполеон Россиягә юнәлә. Нәтиҗә мәгълүм: таш югала, ир бала тапкан императрица аңа битараф була, Россия җиңелми, тәхетнең өсте аска килә, аны кечкенә Изге Елена утравы көтә.

...Наполеонның буе хакында бәхәс тә әлегәчә тынмый. Күп очракта аның буе 151-155 сантиметр дип билгеләнсә дә, соңрак императорның буе 169 сантиметр дип күрсәтелә. Әмма шундый олы җиңүләр яулаган шәхес буларак, ул бу нисбәттән күңел төшенкелегенә бирелми. Үзенең буена бәйле рәвештә, Наполеон бер тапкыр гына әйтеп куя: «Әнием шулай ди иде: «Кешенең чын буе – җирдән башка кадәр түгел, ә баштан күккә кадәр».

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА әзерләде.

(Дәвамы. Башы 22-23 нче саннарда).

Гаяз ИСХАКЫЙ:

Зәки Вәлиди кемдер?

Әүвәл Петербургка барып, кырык километрга кадәр якын килгән чуд эстоннары һәм руслардан торган генерал Юденич (Николай Николаевич Юденич (1862 –1933), патша Россиясе хәрби эшлеклесе) гаскәренә каршы бу башкорт-татарны каршы куйдылар һәм, монда егерме биш мең татар-башкорт балаларын корбан итеп, Петербургны сакларга тырыштылар. Бу хәрәкәт тәмам булганнан соңрак, үз байрагын калдырмаса, Украинага каршы (Г.Исхакый бу урында Кызыл гаскәрләрнең А.Деникин гаскәренә каршы сугышын искә ала. Генерал Деникин гаскәрләренә каршы көрәш 1919 елның көзендә башлана. Совет гаскәрләре Тула шәһәренә кадәр чигенә. Кызыл гаскәр 1919 елның ахыры, 1920 елның башларында гына уңышлы һөҗүмгә күчә, бу сугышта З.Вәлиди оештырган башкорт гаскәре дә катнаша) большевиклар сугыш ачтылар. Һәм Сибириягә дә татар-башкорт балаларын меңнәрчә корбан иттереп, украиналыларның кулыннан Харьков вә Киев шәһәрен алып, Мәскәүгә куштылар. Бу сугышларга каршы З.Вәлиди Мәскәү большевик хөкүмәтеннән күп тапкырлар рәхмәтләр алып, вә сәгать, вә медаль кебек артык әһәмияте булмаган бүләкләр белән бүләкләнмешдер. Һәм шул заманда Совет Башкортстаныннан З.Вәлидинең иптәше Шәриф Манатов Башкортстанның вәкиле сыйфаты белән элек Кавказга, соңрак бәйсезлек турында сөйләшүләрне дәвам иттерү мәҗбүриятендә булган З.Вәлиди имзасыйла корылган большевик пропагандасы өчен җибәрелмештер. Мәскәү тарафыннан кулына бирелгән акча белән Шәриф Манатов Төркестан якларында коммунист оешмаларын барлыкка китерә. Коммунист журналларын, гәзитәләрен нәшер итәргә башламыштыр. Анкараның милли бәйсезлекне идарә иткән Милләт Мәҗлесе хөкүмәте (Мостафа Кәмал җитәкчелегендәге Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесе, 1920 елның 16 мартында Госманлы Төркия парламенты таратылганнан соң, 1920 елның 23 апрелендә Анкара шәһәрендә беренче утырышын уздыра) Шәриф Манатовны иптәшләре белән кулга алып һәм хәрби трибунал төрмәсендә дошман буларак хөкем ителмештер. Шәриф Манатов, качып китеп, тормышын коткармыш, вә Россиягә кайтып, З.Вәлиди белән берләшеп, Бохара, Хива ханлыкларын Россиягә кушу өчен [патша Россиясе протекторатында булган Хива ханлыгы, Кызыл гаскәрләр басып керү белән, яшәүдән туктый. Бохара ханлыгы исә 1920 елның 2 сентябрендә М. Фрунзе җитәкчелегендәге Кызыл гаскәрнең һөҗүменнән соң тулысы белән мөстәкыйльлеген югалта] гамәлгә кую мәсьәләләре белән төрле тәкъдимнәр ясый башламышлардыр. Фәкать З.Вәлидинең руслар мәнфәгате өчен татар-башкорт яшьлеген юк иттермәс өчен башкорт илендә үзенә каршы дошманлык догмасына сәбәп бирде, вә башкорт гаскәре баш күтәрде.

Зәки Вәлиди әфәнде дә Мәскәүгә качып китте. З.Вәлиди большевиклар кулланачак [нигез] калмаганнан, аңа каршы большевик даирәләрендә мөгамәлә үзгәрде, һәм З.Вәлиди, моңа кайгы-хәсрәткә төшеп, элек Кавказга, соңрак Төркестанга китмеш (З.Вәлиди 1920 елның 29 июнендә, большевик хөкүмәтеннән качып, Кавказ аша Төркестанга китә. «Хатирәләр» китабында бу хакта: «Мин үзем Мәскәүдән Әстерхан һәм Баку аша Ашхабадка китәчәкмен. Аннан кабат Бакуга килергә, «Шәрекъ халыклары съезды»нда катнашырга, ә соңыннан көнбатыш Казахстанга үтеп, Үстйорт аша Харәземгә һәм Бохарага юл тотарга тиешмен», – дип искә ала) вә монда ярым яшерен, ярым ачык яшәп, Төркестанның яшерен җәмгыятьләре эченә керергә тырышты. (Г.Исхакый язганча, З.Вәлиди Төркестанда, аерым алганда Бохара һәм Хива җирләрендә оешкан басмачылар хәрәкәте белән тыгыз элемтәдә тора, Үзбәкстандагы «Җәдит», «Социалистик ирек» фиркаләре белән дә мөнәсәбәттә була. 1920 –1923 елларда – «Төркестанлылар милли берлеге» рәисе. Бу елларда Төркестанның милли азатлык хәрәкәтенә җитәкчелек итә һәм Совет хөкүмәтенә каршы актив көрәш алып бара). Бу вакытларда Төркестан исеме [астында] баш күтәрү хәлендә булган вә Төркестанның бөтен шәһәрләр, кышлаклары шундый яшерен җәмгыятьләр белән тулы булгандыр. Ялгыз З.Вәлидинең иминлеге юк ителеп, бер үз файдасын кайгыртудан эшләнгән, ул һәм бервакыт дәүләт оешмасында яшәү бирә белмәмештер. Россиягә әсир төшкән госманлы халкының рекруты белән большевиклардан качкан татар солдатлары вә кече офицерлары кулында булды. Вә бу күтәрелешнең максаты бөтен Төркестанны (үзбәк, төркмән, казах-кыргыз) берләштереп, бер мөстәкыйль төрек дәүләте кору булып һәм монда советлашкан Идел буеннан качкан бик күп татар зыялысы бу теләкнең нигезле юлыннан китте.

Төркестанлылар, Россия гаскәренә алынмаганлыктан, коралдан куллануны белми иде вә гаскәри тәртипләрне аңламый иде, моннан тулаем төрек-татар солдаты һәм кече офицерлары бу күтәрелеш хәрәкәтенең иң югары гамәлләре вә тормышлары иткән З.Вәлиди Төркестан җәмгыятьләренә кушылып, бу теләкгамәленә һәм бирелеп, һәм төрек-татар дошманлыгы тудырырга күп тырышты. Бөтен Төркестанның күтәрелешендә татар нурландыручы төркемнең күп өлеше иң бөек хәрәкәткә китерүчесе булганнан, бу татар дошманлыгы фикеренең таралуы бөтен Төркестан хәрәкәтенә каршы бер көчле удар булачак иде. Шул заманда баш күтәрүче бер кавемен [чигендерү] өчен большевиклар да элекке пропагандага ябышкан иде. Бу икейөзлелек пропагандасының нәтиҗәсе бик тиз мәйданга чыкты. Төркестан күтәрелешенә катышыр өчен, Уфадан качып килгән басмачыларга кушылган унҗиде татар офицеры бер кичтә лакийлар тарафыннан һәлак ителде вә башка урыннарда моңа охшаш гамәлләр дә ясалды. Унҗиде татар офицерының үтерелүе Төркестандагы барлык татар зыялысына нык авыр тәэсир ясады, вә бу кара хәбәр, колактан колакка сөйләнеп, Идел буена кадәр таралды. Большевик матбугаты моннан бик оста файдаланды. Моннан башка Төркестанның җирле халкы арасында берлек нигезенә корылган бу җәмгыятьләр З.Вәлиди нигезен кую инициативасында булынды, һәрбер аерым кабиләнең – үзбәк, төркмән, таҗик, казах, кара кыргыз, каракалпакның – аерым-аерым оешмалары төзергә кирәклеген алга сөрде. Большевик матбугатында шул фикерне ташлап торуларның нәтиҗәсендә Төркестанның сәясәтен җимерергә алынган яшьлекнең фикере бер анархия дәверенә керде. Вә басмачы хәрәкәте аерым-аерым корбашларның (янә яшьләре) кулларында калып, милли гаскәрлек – талауны мәйданга чыгара. Шул заманда З.Вәлиди большевиклардан туюын, үзенең коммунист фикереннән ваз кичкәнен игълан иткән хатлар язудан туктады. Вә, чынлап, Мәскәүләр белән бәйләнешен өзмәде.

1924 елдан З.Вәлиди әфәнде Әфганстан, Һиндстан аша Төркиягә килә. (Г.Исхакый мәкаләсендә азрак төгәлсезлек бар. З.Вәлиди 1923 елның февраль ахырында Иран дәүләте чиген узып, 24 апрельдән Әфганстан җиренә аяк баса. «Хатирәләр» китабыннан күренгәнчә, З.Вәлиди Кабулга 1923 елның 18 июнендә барып җитә. Әфганстаннан турыдан-туры Төркиягә китми, ә бәлки Европага юл ала). Фәкать Әфганстандагы Төркия илчелеге З.Вәлиди хакында туплаган мәгълүматының җавабынча Әфганстандагы Төркия илчесе Фәхри паша виза бирмәгәнлектән (З.Вәлидинең «Хатирәләр» китабында төрек илчелегеннән виза сорау турында мәгълүмат очрамады. Әфганстанда Төркия илчесе Фәхретдин паша белән очрашу вакытында үзенең Европага барырга, соңыннан кабат Әфганстанга әйләнеп кайтырга теләге барлыгын җиткерә. Истәлектән күренгәнчә, 1923 елның 23 июлендә Бохара илчелегендә үзенә һәм юлдашы Габделкадыйрга Һиндстан аша Европага китү өчен паспорт алуын искә ала), Төркиягә бара алмыйча, Франциягә китә. Вә монда мөһаҗирәттә булган бөтен төрек-татарның бөекләренә язган хатларында «агай, агам», «бөек агам» сүзләре белән башланган гаять тыйнак хатлар аша үзенең язган хатларыннан тәүбә итә. Кабиләчелек сәясәтеннән ваз кичкәнен сөйләр вә төрек берлеге нигезендә ялгыз милли киңлектә эшләячәген вәгъдә итеп, искедәге гөнаһлары гафу ителүен үтенә. Барысы да Төркестан хөкүмәтенең рәисе Мостафа Чокай углын (Мостафа Чокай (1890 –1941), казах җәмәгать һәм сәяси эшлеклесе, публицист) ышандыра вә Парижның Идел буе Милләт Мәҗлесе рәисе Садри Максудига (Садретдин (Садри) Низаметдин улы Максуди (1878 –1957), 1923 –1924 елларда Сорбонна (Париж) университеты каршындагы Ислам белгечләре институтында татар-төркиләр тарихын укыта. Париж шәһәрендә ул Г.Исхакый белән берлектә Милләт Мәҗлесе эшчәнлегендә) З.Вәлидинең «Хатирәләр» китабында төрек илчелегеннән виза сорау турында мәгълүмат очрамады. Әфганстанда Төркия илчесе Фәхретдин паша белән очрашу вакытында үзенең Европага барырга, соңыннан кабат Әфганстанга әйләнеп кайтырга теләге барлыгын җиткерә.

Истәлектән күренгәнчә, 1923 елның 23 июлендә Бохара илчелегендә үзенә һәм юлдашы Габделкадыйрга Һиндстан аша Европага китү өчен паспорт алуын искә ала (дәвам иттерә) ике тапкыр визит ясап, шул юлда сүз сөйли һәм үзен яклауны тели. Берлинда урнашкан Гаяз Исхакыйга, элек [бердәм төркилек идеясын] тараткан Фуад Туктар бәкләргә (1919 елда Версаль тынычлык килешүенә катнашу нияте белән Европага юнәлгән Г.Исхакый һәм Ф.Туктар 1923 –1925 елларда Берлин шәһәрендә яши) мөрәҗәгатьләр итә вә үзенең иптәшләреген кабул ителүен сорый. Берлинда ул вакытларда бик күп Төркия студентларыннан башка Идел буйлы, әзәри, төркестанлы йөз иллегә якын студент бар иде. Боларга башка һәрбер төрек кабиләсенең нурландыручы мөһаҗирләре дә ирексезләү хикмәте рәвешендә монда яшиләр иде, вә боларның күбесе мөһаҗир булганы хәлдә бер өлеше Совет Россиясендә совет паспорты белән калган студент иде. Боларны төреклек һәм төрек берлеге нигезендә тәрбия итү өчен аерым бер эшчәнлек алып бару кирәк иде. Моны Төркия төрекләре белән Шималь төрекләренең бөекләре «Туран» исемендә бер оешма («Туран җәмгыяте» – 1920 елларда Берлинда төрек-татар мөһаҗирләренең милли күтәрелеш юнәлешендә эш йөрткән җәмгыять) барлыкка китермешләр вә төрекче клубында урнашып, «Туран» җәмгыяте бөтен төрек кабиләләренең яшьләрен җәлеп итәргә, алдатырга башламышлар иде.

● Субидәй Тоган әтисе Зәки Вәлиди кабере янында.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 13 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. 244 б.

(Дәвамы киләсе санда).

Хуш, Болонья!..

Россия югары белем өлкәсендәге халыкара килешү – Болонья мәгариф системасыннан рәсми рәвештә чыгарга теләгән белдерде. 7 июньдә ил вузларының бөтенесенең дә бу системадан аерылганлыгы хәбәр ителде. Белгечләр бу студентларның чит илләрдә уку мөмкинлеген нык киметәчәк һәм Россия дипломнарын читтә тану кыенлыкларын тудырачак дип кисәтә.

Май азагында Россия фән һәм мәгариф министры Валерий Фальков Россиядә Болонья мәгариф системасыннан чыгу теләген белдерде.

– Болонья системасына инде үтелгән этап буларак карарга кирәк. Киләчәк үзебезнең уникаль мәгариф системасында, аның нигезендә илебез икътисады һәм һәр студент өчен мөмкинлекләр киңлеге ятарга тиеш, – диде ул.

Киләсе елны Россиянең Болонья системасына кушылуына 20 ел тула. Бу система нәрсәдән гыйбарәт һәм аннан чыгу Россия мәгарифе өчен нәрсәне аңлата?

Болонья системасы дип Европа илләренең уртак мәгариф киңлеген булдыру өчен кабул ителгән концепцияне атыйлар. Ягъни, ул Европа илләрендә югары белемнең уртак стандартларын булдыра.

Югары белемне бу стандарт икегә бүлә: бакалавриат һәм магистратура.

Моннан тыш бу системага ярашлы рәвештә:

• Европа илләре өчен уртак фәнни дәрәҗәләр системасы кабул ителә. Алар төрле уку йортларында бер-берсенә туры килергә тиеш.

• ECTS дип аталган махсус баллар системасы кертелә. Һәр фән, һәр дәреснең билгеле күләмдәге баллары бар.

• Мөгаллимнәр һәм студентлар өчен Европаның башка югары уку йортларында белем һәм тәҗрибәне алу мөмкинлеге.

• Халыкара студент проектларында актив катнашу.

Кыскача әйткәндә, Болонья мәгариф системасы студент (һәм мөгаллим) өчен дөньяны ачык итә, бер университеттан икенчесенә күчүне җиңеләйтә, махсус программалар тәкъдим итә.

Болонья декларациясен башта 4 ил имзалады: Бөекбритания, Германия, Франция һәм Италия. Хәзерге вакытта бу килешү 48 илне берләштерә. Европа илләреннән тыш аңа Әзәрбайҗан, Төркия, Казахстан, Грузия, Кипр, Әрмәнстан керә. Россия Болонья килешүенә 2003 елның сентябрендә кушылды.

Россиянең Болонья мәгариф системасыннан чыгуы нинди нәтиҗәләргә китерәчәк?

1. Студентларның чит илдә уку мөмкинлеге чикләнә

Болонья системасының төп нигезе – Европа илләре һәм уку йортлары арасында ачык бәйләнешләр булу. Ягъни студентлар җиңел генә башка илдәге университетка тулысынча яки вакытлыча күчә ала, төрле стажировкаларда катнаша ала. Бу юнәлештә эшләгән иң танылган программа – Erasmus – Россиядә һәм, аерым алганда, Казанда да эшләп килде.

Бу студентлар өчен иреклек һәм үз үсешен үзләре теләгәнчә билгеле алуны аңлата. Сәясәт белгечләре фикеренчә, Россиягә бернинди ирек һәм чит ил студентлары белән аралашу кирәкми.

Болонья системасыннан чыгу очрагында Россиянең бакалавр һәм магистр баскычларыннан баш тарту ихтималы бик зур. Европа илләрендә, гадәттә, студентлар 4 ел бакалаврга укыса, шуннан соң тагын 2 ел магистрга укый. Россиядә исә мәгариф элекке системага кайтырга мөмкин. Совет елларында һәм 90нчы елларда Россиядә студентлар 5 ел белгечкә укый, инде шуннан соң аспирантурага керә ала иде.

> **Санкт-Петербург дәүләт университеты ректоры Николай КРОПАЧЕВ:**
>
> ***«Уку-укыту процессының озынлыгы түгел, ә сыйфаты мөһим... Бәлки, кайдадыр дүрт, биш һәм җиде түгел, ә 11 ел, әгәр вертикаль дөрес төзесәң. Тик акча турында да онытмаска кирәк. Әйдәгез, хәзер безгә бөтенебезгә дә акча бирегез һәм без совет чорындагы сыйфатлы белемне тәэмин итәчәкбез, дип әйтеп буламы? Әллә безгә акча да күбрәк һәм уку вакытын да озайтырга киркәме? Сүз дә юк, уку вакытын ректорлар гына түгел, бизнес, дәүләт структуралары да билгеләргә тиеш. Менә безнең заказчылар.***
>
> ***Хәзер дистә яки йөз меңләгән итеп әзерләп торган бакалаврларны икенче сортлы диплом ияләре дип уйларга ярамый. Бу алай түгел».***

Болонья системасыннан чыгу Россия белем баскычларының Европа уку йортларыннан аерылачагын аңлата. Димәк, уку еллары тәңгәллеге бозыла, университетлар арасында хезмәттәшлек һәм студентлар белән алышу авырлаша. Моннан тыш, Россиянең хәзерге изоляция шартларында, гомумән, студентларның ирекле рәвештә чит илдә укуын да күзаллау кыен.

2. Россия дипломнарын чит илдә тану кыенлыклары туа

Башка төрле мәгариф системасына күчү Россиянең белгечлек дипломнарын чит илләрдә, аеруча Европада тануда кыенлыклар туарга мөмкин. Болонья системасы күпмедер күләмдә бу процессны җиңеләйткән булган.

Рособрнадзорның элекке башлыгы Виктор Болотов фикеренчә, Россия Болонья килешүеннән чыкса, бу башка илләр аның дипломнарын танудан баш тартачак дигәнне аңлатмый, ләкин процесс катлауланачак.

– Безнең дипломнарны әле Болонья процессына килешкәнче үк таныганнар иде. Ләкин процедура озак дәвам итте һәм шактый чыгымнар сорады. Хәзер дә (килешүдән чыккан очракта) танырга тиешләр. Ләкин без Болонья конвенциясендә катнашканда бу күпкә җиңелрәк уза, – дип аңлатты ул.

Башка белгечләр дә бу фикер белән ризалаша. Дипломнар чит илләрдә автоматик рәвештә танылмаячак, аларны расларга кирәк булачак. Бу чит илләрдә эшләргә теләгән россиялеләргә дә, Россиядә эшләргә теләгән европалыларга да кагыла.

3. Россиягә чит ил студентлары күпкә әзрәк киләчәк

Болонья килешүеннән чыгу очрагында Россиядә Европадан укырга килгән студентлар булмаячак диярлек. Россиягә дустанә караган башка илләрдән дә студентлар килүен киметәчәк, дип саный Санкт-Петербургтагы Европа университеты хезмәткәре Алексей Железнов.

Болонья системасы Европа һәм Америка студентлары һәм мөгаллимнәренә генә түгел, Африка, Азия, Латин Америкасы илләренә дә зур файда китерә. Россиянең алдынгы уку йортларына бу илләрдән дә килүче студентлар агымы нык кимергә мөмкин, чөнки кешеләр алган белемне башка илләрдә дә танысыннар дип уйлый. Аеруча уку өчен акча түләгән очракта. Шулай итеп, Россиянең Болонья системасыннан чыгуы бөтен ил белән студентлар алышуына тискәре тәэсир итәчәк, дип саный А. Железнов.

Соңгы елларда Россиянең, аеруча Казан университетының Кытай студентлары белән алмашу программалары эшләп килде. Аның нигезендә Казанга укырга Кытайда яшәүче татарлар да йөрде, алар еш кына үзләре түләп укыды.

> **Н.Э.Бауман исемендәге МДТУ ректоры Михаил ГОРДИН:**
>
> ***«Болонья моделеннән баш тарту совет системасына тулысынча кире кайтуны аңлатмый, чөнки кайбер очракларда ике дәрәҗәле әзерлек форматы – бакалавриат һәм магистратура – эш бирүчеләр һәм студентлар мәнфәгатьләренә җавап бирә. Әзерләү траекториясен сайлауда сыгылмалырак система булдыру көчебездән килә. Күп кенә очракларда элекке кебек «белгечлек» алу системасын кайтару мөһим. Шулай ук югары уку йортын тәмамлаучыларга диплом алганда бирелә торган квалификацияләр исемлеген дә киңәйтү әһәмиятле».***

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

25 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 0.47 сәгатьтә калка,17.05 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Теш дәвалату өчен начар вакыт. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Сырганак дәвалый

Тамак бакасы (ангина) интектерсә, 1 чәй кашыгы сырганак маен ярты литр җылы суда эретеп, 1,5-2 сәгать саен шундый ярты стакан эремә белән тамакны чайкыйлар. Шул ук сырганаклы суга берничә кат бөкләнгән марляны манып алып, муенга куялар, полиэтилен, аннары җылы шарф белән урыйлар. Мондый компрессны көненә 1-2 тапкыр 2-3 сәгатькә куялар.

26 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 27 нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,1.01 сәгатьтә калка, 18.22 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Яраткан ризык

Нинди дә булса ризыкны бик тә ашыйсы килә икән, организм җибәргән бу сигналны игътибарсыз калдырмаска кирәк. Немец диетологлары фикеренчә, ниндидер бер ризыкка ихтыяҗ кайбер авырулар барлыгына ишарәли. Мәсәлән, даими рәвештә лимон ашыйсы килү теләге - үт куыгы һәм бавырның нормаль эшчәнлеге бозылу билгесе. Кәбестә яратучыларның, гадәттә, эчәклек, ә зәйтүн җимешенә битараф булмаганнарның калкансыман биз авыруларыннан интегүе ихтимал. Кальций җитмәгән кешенең гел туңдырма ашыйсы килә. Алмасыз тора алмаганнарның канында холестерин дәрәҗәсе югары була, бу исә кан тамырларында атеросклероз китереп чыгарырга мөмкин.

27 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 1.20 сәгатьтә калка, 19.36 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.32 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Кәбестә чәе

Кәбестәне эре итеп турап, эмальләнгән кәстрүлгә тутыралар, өстенә кайнар су агызалар. Капкачын томалап, бераз төнәткәннән соң, кайнар килеш көненә берничә

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

тапкыр эчәләр. Мондый чәй – ютәлдән иң шәп дәваларның берсе.

28 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 1.48 сәгатьтә калка,20.39 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Тамырлар киңәйгәндә

2 аш кашыгы чүп үләне – борыч кырлачын (горец перечный) ярты литр кайнар суда 2 сәгать төнәтәләр, көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. Болай дәваланганда, аяктагы кан тамырларындагы шешләр һәм геморрой бер атнада юкка чыга.

29 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 30 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кысла йолдызлыгында, 2.28 сәгатьтә калка, 21.29 сәгатьтә бата. 5 сәгать 52 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 17.30 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Радикулиттан – тоз

100 г тозны 1 литр кайнар суда эретәләр, сигезгә бөкләнгән марляны шушы тозлы эремәгә манып алып, авырткан урынга куялар, компресс ясагандагыдай җылы итеп урап, 8 сәгать тоталар. 10 көн буе шулай дәваланганда, бил авыртуы бетә.

30 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 3.24 сәгатьтә калка, 22.04 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.29 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

1 июль (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 4.32 сәгатьтә калка, 22.28 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.28 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Ширбәт

100 мл сөт, 150 г атланмай, 400 г шикәр, 200 г кыздырылмаган арахис, 100 г какао порошогы һәм 200 г коры сөт кирәк. Арахисны газ мичендә җиңелчә генә киптереп алып, кабыгыннан чистарталар. Сөт, шикәр һәм майны сүрән утта куерганчы пешерәләр, шуңа коры сөт һәм какао порошогы, чикләвекне салып болгаталар да, формага салып, суыталар. Силикон форма булса бик яхшы, башка форма булса, аңа башта полиэтилен пленка җәяргә кирәк.

Космонавт дусты

Шагыйрь, язучы, тәрҗемәче, публицист Кави Латыйп (Кави Таһир улы Латыйпов) татар, рус, чуаш телләрендә иркен сөйләшә иде. Ул әсәрләрен дә өч телдә язды, бер телдән икенче телгә тәрҗемәләр кылды. Мөгаен, моңа Кавиның Чуашстанда тууы, җирле халык белән аралашып, хөрмәт итеп яшәве йогынты ясагандыр.

К.Латыйпов 1927 елның 1 маенда Чуашстанның Батыр районы Убей Чишмә (хәзер Кызыл Чишмә) авылында туган. Бөек Ватан сугышында катнашкан.

К.Латыйповның армиядән соңгы тормышы тулысынча Татарстан белән бәйле. 1955 елда энергиясе ташып торган егетне ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты инструкторы итеп билгелиләр. Биредә бераз оештыру һәм тормыш тәҗрибәсе туплагач, аны Татарстан АССР мәгариф министрлыгы инспекторы итеп күчерәләр.

Биредә дә җиң сызганып тырышып эшли Кави Латыйпов. Тотынган һәр эшне җиренә җиткереп башкара.

Шул чорда республиканың өр-яңа оешмасы – Казан телевидение студиясе эшкә керешә. Кави шунда «Яңалыклар» редакциясен җитәкли.

Армиядә хезмәт иткәндә үк, каләм тибрәтергә керешкән Кавига эш шактый җиңелдән бирелә. Ул көндезләрен әзерләгән фактларны кичләрен, еш кына төннәрен дә кәгазь битенә сала. Әмма әле бу чорда телевидениедә эшләүчеләрнең тиешле әзерлеге дә, белеме дә булмый. Казан уку йортлары телевидение өчен кадрлар әзерләми.

Кави Латыйпов Казан телевидение студиясендә озак эшләми. Мәскәүгә укырга китү мөмкинлегеннән файдаланып, Кави 1971 елда М.Горький исемендәге бөтенсоюз әдәбият институтына китеп бара. Укып кайткач, Казан дары заводының «Ленинчы» газетасын чыгарырга керешә. Күрәсең, анда хезмәт хакы һәм башка мөмкинлекләр югарырак булгандыр.

1978 елда ул СССР педагогика Фәннәре академиясенең профессиональ-техник Казан фәнни тикшеренү институтына өлкән фәнни хезмәткәр булып урнаша. Пенсиягә чыкканчы шунда хезмәт итә.

Гомере буе Казанда эшләсә дә Кави туган ягын бик ярата, Чуашстанга еш кайтып йөри. Якташы Николаев космоска очкач, аның белән дуслашып даими очрашып йөри башлый. Андриан Николаевка үзенең күп кенә әсәрләрен дә багышлый.

Кави Латыйпның беренче әсәрләре сугышчыларга багышланган була. Авторның беренче шигырь җыентыгы китабы да «Солдат эзләре» дип исемләнә. 1973 елда Кавиның Мәскәүдә рус телендә «Краски жизни» җыентыгы чыга.

Авторның «Иркен сулыш» (1991), «Иман караваны» (1997), шулай ук, «Хәтер йомгагы» (2002) шигырь җыентыкларын бүген дә укучылары яратып укыйлар.

Кави талантлы прозаик та. Аның сугыш чоры халкыбыз тормышын чагылдырган «Мизгел» (1972), «Ефәк әрем» (2002) җыентыклары дөнья күрде.

К.Латыйпов сүзләренә язылган «Ватан чакыра» дигән җыр бүген дә еш яңгырый (музыкасын композитор Әнвәр Бакиров язган).

Кави Таһир улы Латыйповның тууына 95 ел тулды. Бу дата шагыйрьнең туган ягы Батыр район китапханәсендә зурлап билгеләп үтелде. Китапханәче Гөлфисә Шәрәгыва тантанада катнашучыларны юбилярның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. «Йолдыз тапкан егет» повестеннан татар һәм чуаш телләрендә өзекләр дә укылды, шигырьләре яңгырады.

Кави Латыйп 2008 елның 14 апрелендә безнең арадан китеп барды. Ул үзенең туган авылы Чуашстанның Батыр районы Кызыл Чишмә авылы зиратында җирләнде.

Мин бу кыска гына язмамны заманында бик нык аралашып яшәгән Кави дустымның бер шигыреннән өзек белән тәмамларга булдым:

Мин – Кави сабый җанлы кешемен,
Шигърият минем бишегем.
Төнге күлгә мин карыйм:
Атылган йолдыз табыйм,
Ул атылган йолдыз белән
Язмышым бер дип саныйм.
Хәер, мине эзләмәсләр,
Суларга атылсам да.
Ниндидер бүтән йолдызлар
Балкырлар якты таңда.
Мине, бәлки, су кызлары,
Бергәләп, үз итәрләр
Башка берни дә кирәкми,
Ир-егеткә шул җитәр.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Кроссворд



Сулдан уңга:

1. Күңел ачу кичәсе. 5. Исерек түгел. 7. Хөрлек, бәйсезлек. 8. Муенга урый торган юка шарф. 9. Бөтеннең дүрттән бере. 11. Якынның киресе. 12. Имтихан. 13.Урманда яши торган кимерүче җәнлек. 16. Баһадир. 17. Авыл йортларында ягылмый торган кечерәк бүлмә. 18. Дәүләт тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри җыем. 20. Им-томчы. 26. Алпавыт җире. 27. Кырда ашлык көлтәләренең зур озынча өеме. 28. Ягулык. 31. Олы юл. 32. Х.Вәлиуллин операсы. 33. Чүп үләне. 34. Ял итү шөгыле. 35. Океаннарда яшәүче зур имезүче хайван.

Өстән аска:

1. Үзәк шәһәр. 2. Татарстандагы район. 3. Суык. 4. Ихтирам күрсәтү. 5. Доллар, крона. 6. Киндер яки тактага ясалган буяулы рәсем. 8. Озынча күн тасма. 10.Сәнгать төре. 14. Туздан ясалган савыт. 15. Ишетү органы. 19. Бергә катнашып китү, буталу. 21. Үзлегеннән тиз ата торган кул коралы. 22. Физик эш-хәрәкәт ясау сәләте. 23. Матросларның озын чабулы курткасы. 24. Күркәле музыка коралы. 25. Кыйммәтле йонлы кечкенә ерткыч җәнлек. 29.Углеводород (газ). 30. Шома кайрылы, киртләч яфраклы агач.

Нияз БИШБАЛТА төзеде.

ҖАВАПЛАР

Сулдан уңга:

1. Бал. 5. Аек. 7. Азатлык. 8. Кашне. 9. Чирек. 11. Ерак. 12. Сынау. 13.Тиен. 16. Батыр. 17. Чолан. 18. Салым. 20. Шаман. 26. Утар. 27. Зурат. 28. Утын. 31. Тракт. 32. «Самат». 33. Алабута. 34. Уен. 35. Кит.

Өстән аска:

1.Башкала. 2. Лаеш. 3. Салкын. 4. Олылау. 5. Акча. 6. Картина. 8. Каеш. 10. Кино. 14. Тырыс. 15. Колак. 19. Аралашу. 21. Автомат. 22. Куәт. 23.Бушлат. 24. Гармун. 25. Янут. 29. Этан. 30. Усак.



Дин һәм заман таләбе

(Дәвамы. Башы 23 нче санда).

Шунысы кызык, дин әһелләре (шул исәптән безнекеләр дә) моңа зур каршылык күрсәтмәгән. Ник дигәндә, менә шулай, Коръәнне башка телләргә тәрҗемә итүне тыеп ва гыйбадәт кылуны гарәпчә генә рөхсәт итеп, мөселман руханилары, нәсари чиркәү үрнәгендә, кешене Аллаһтан читләштергәннәр һәм, алар арасына арадашчы куеп (Хак Тәгалә сүзен гавамга теләгәннәренчә генә җиткереп), үз хакимиятләрен ныгытканнар. Аңлашыла булса кирәк, бу инсаннарның иманын ныгытмый (аларны Аллаһка якынайтмый), ә какшата, димәк, ул – көферлек.

Без Коръәннең һәр кәлимәсе Аллаһ сүзе икәненә иман китергән кавем. Ләкин ул гарәп телендә иңдерелгән дип уйлау – мәҗүсилек икәнен дә онытмыйк. Анысы Раббыбызны физик тәнле затка тиңләп күзаллаудан килә. Коръән бит Җәбраил мәләк аркылы иңдерелгән. Мөхәммәд (с.г.в.) аның белән рухи дөньяда аралашкан. Анда үзара аңлашу авазлар (телләр) ярдәмендә түгел (монысы физик дөньяга гына хас), ә фикри энергияләр алмашу юлы белән башкарыла. Рәсүлебез вәхине фикер буларак кабул итеп, адәми затка җиткерү ниятендә гарәп сөйләменә тәрҗемә иткән.

Шулай итеп, галәми информацион кыр мәгълүматы инсани телдә гарәпчә яңгыраган. Аллаһ моның хикмәтен болай аңлата: «Без аны яхшы аңласыннар һәм үгет алсыннар, дип, ана телендә иңдердек» (Коръән, 44:58). Коръән бөтен халыклар өчен ирештерелгән, димәк, аның нинди телдә язылырга тиешлеге мәсьәләсендә кайсына да булса өстенлек бирү урынсыз. Аллаһ кисәтә: «Әй иманлы кешеләр! Уйдырмаларның күбесеннән ваз кичегез. Аларның байтагы гөнаһ...» (Коръән, 49:12). Тагын: «Әгәр дә сез чынлап та иман китерер булсагыз (белегез): күкләрдәге, Җирдәге һәм алар арасындагы бөтен нәрсә Раббыдан» (44:7). Ягъни кавемнәрне Аллаһ яраткан, аларның телләре дә - Аның нигъмәте. Димәк, Хак Тәгалә сүзен (Коръәнне һәр кеше үз шивәсендә укып аңларга һәм шуның аша хакыйкатьне үз телендә танып белергә хокуклы. Мондый фикерне «Камәр» («Ай») сүрәсенең 17 нче аяте дә раслый: «Хактыр ки, Без Коръәнне уйланып, аңлар өчен кулайлаштырдык. Бу турыда уйлап бакканыгыз бармы?»

Кызганыч, ул хакта баш ватуны кирәк санамыйбыз шул. Исламның асылын аңлап эш итәбез дип тә мактана алмыйбыз хәзергә: ЮНЕСКО тарафыннан иң кирәкле вә камил саналган 14 тел арасында бары тик безнеке генә ятимлек кичерә, чөнки ул динебездән читләштерелгән. Гавамга руханилар – гарәпчә вә русча, галимнәребез һәм хакимият вәкилләре – русча, язучылар татарча эндәшә, ә, ул, мескен, аларның берсен дә кирәгенчә аңламыйча, ярым наданлыкта (һәрхәлдә, иман мәсьәләсендә) калуын дәвам итә. Милли интеллигенция исә, халкыбыз бозык, дип лаф ора. Аны кем җитәкләргә тиеш соң?

Бу уңайдан инглизләр үрнәгенә игътибар итү зарур. Алар урта гасырларда Рим йогынтысыннан арыну ниятендәге гамәлләрен Библияне үз телләренә тәрҗемә итүдән башлаган һәм тиз арада империянең иң читтәге провинциаль төбәген Бөек Британиягә әверелдерүгә ирешкән. рус православиесе чиркәве дә дин тотуда телнең нинди роль уйнаганын, татар - мөселман руханиларына караганда, күпкә яхшырак аңлый: гаммәви мәгълүмат чаралары хәбәр иткәнчә, анда да гыйбадәтне хәзерге рус теленә күчерү турында карар кабул ителгән.

Әгәр татарчабыз Аллаһ белән аралашу чарасына-коралына әверелеп, динебез теле дә булса, милләтне саклау проблемасын уңай хәл итү дә күпкә җиңеләер иде. Элекке заманнарда Идел буенда ислам татар телле булган һәм башка халыклар арасында татар дине дип аталган. Хәзер исә ул биредә рус телле, хәтта татарлар үзләре дә дини йолаларны ятлар сөйләмендә башкара. Шулай дин элек милләтне саклаган булса, хәзер аны руслаштыруга хезмәт итә. (Җәдитчеләр исламның гарәпләшкәнлегенә борчылу белдергән, бүген исә татарга бу мәсьәләдә икеләтә куркыныч яный.) Нишләргә?

– Беренчедән, Аллаһ биргән акылга таянып, исламны реформалау эшенә керешергә һәм иҗтиһат капкасын ачуга ирешергә;

– икенчедән, үз миссиябезне үтәү аркылы исламны татар телле итәргә;

– өченчедән, милли яшәеш системасын булдырырга.

Моның өчен милләттә дүрт катлам үз вазифасын төгәл башкарырга тиеш. Милли системаның башында – күмәк оешма-идеологлар төркеме; алар хакыйкатьне өйрәнүчеләр – белүчеләр. Бу – беренче катлам; ул милләт миссиясен үтәү буенча, вәзгыятьне анализлап, «нишләргә?» дигән сорауга даими рәвештә җавап эзләи һәм икенче катламга тәкъдим-күрсәтмәләр әзерли. Соңгысы сәясәтчеләрдән-башкаручылардан тора. Алар мәгърифәт дәрәҗәсендә эш итә, ягъни «хакыйкатьче»ләр күрсәтмәләрен, социологик, икътисади, юридик һ.б иҗтимагый гыйлемгә нигезләнеп, тормышка ашыра. Өченче катлам-тарикатьчеләр: язучылар, журналистлар, артистлар, галимнәр, руханилар – гомумән, зыялылар. Болары – халыкның төрле ихтыяҗлар белән яшәүче төркемнәре (яшьләре, җенесләре, профессияләре, байлыклары һ.б. аермалыклары булган группалар мөнәсәбәтләрендә дини-мәдәни нигездә гармония урнаштыручы һәм саклаучылар (күптөрлелек бердәмлеген тәэмин итүчеләр). Дүртенче катлам – гавам. Ул шәригать кушканча, татарча аралашып вә моңланып яши, шуның белән милли чикләрне саклый.

Фикерләү мантыйгы буенча, шушы төштә, югарыда әйтелгәннәргә нигезләнеп, татар исламының асылын бәян итүгә күчәргә дә булыр иде кебек. Мәгәр моңарчы бер житди мәсьәләгә тукталып үтмәсәк, укучыда ялгыш караш туу ихтималлыгы кала сыман. Сүз татарның гарәп халкына, аның мәдәниятенә вә теленә мөнәсәбәте хакында бара. Исламны реформалау, аны гарәпләшкәнлектән арындыру кирәк дигәндә, без гарәпне, аның мәдәниятен инкяр итәргә, аңа каршы көрәшергә, үзара бәйләнешләрне туктатырга һ.б.ш. теләкләр белдермибез. Милләтебез бу бөек халыкка рәхмәтле: ул үзенең тәкъдири миссиясен үтәп, Бөек Туфаннан соң яшәгән һун бабаларыбыз мирасын (ислами гыйлемне) мөшриклек чорында саклап калып, аны исраил токымының хакыйкый варисына – татарга тапшыра алган. (Дөрес, бераз бозганнар, әмма бу гарәпләр гаебе генә түгел – заманы шундый булган.) Тел мәсьәләсендә дә тарихи чынбарлыкны таныйбыз: татарның ана теле – төркичә, «ата»сы теле – гарәпчә. Шул ук вакытта тәкъдир таләбен дә онытмыйбыз: XXI йөз башында матриархат чорына кердек, димәк, шуңадыр, туган телебездәге догаларга һәм гыйбадәткә игътибар вә ихтыяҗ арта.

X гасырда гарәпләр дәүләте Болгар ханлыгын үз канаты астына сыендырып, аңа мөстәкыйльлек ялгау мөмкинлеге биргән. Хәзер без алар турында кайгыртырга бурычлы – ягъни буыннар арасында (Аллаһ тарафыннан) нинди табигый мөнәсәбәт тәгаенләнгән булса, гарәп-татар багланышларын да шуңа охшаш итеп күзаллыйбыз. Әйтик, бала кечкенә вакытта аның иминлеген ата-анасы тәэмин итә; сабый үсеп җитеп, аякка баскач, (игелекле ул вә кыз) ата-аналары турында кайгыртуны үз өстенә ала. Бу табигый хәл. Әгәр яңа буен балигъ булгач та, әнисе итәге астыннан чыгарга куркып, өлкәннәр пенсиясенә яшәп ятса, монысы гайре табигый күренеш.

Кайчандыр гайрәтле булган гарәп бүген «картайды», ислам дөньясы хуҗасы вазифасын үти алмый, шуңа бәйле рәвештә, мөселманнар хуҗалыгы да искерде, таркалу-җимерелү хәленә житте. Хәзер хак дин яшәеше турында кайгыртуны милләтебез үз өстенә алырга тиеш – татар исламы мантыйгы менә нәрсәгә нигезләнә.

Рашат САФИН.

«Татар инануы»
китабыннан.

Атнаның сәяси мизгелләре

Форумның нәтиҗәләре

Төньяк башкалада XV Петербург халыкара икътисади форумы (ПМЭФ) узды. «Яңа дөнья – яңа мөмкинлекләр» дигән девиз куелган ул җыенда, рәсми мәгълүматларга караганда, 140 ил вә территориядән вәкилләр катнашкан. Дөрес, Россия президенты ярдәмчесе Ю.Ушаков форумга 40 лап кына ил рәсми делегацияләрен җибәрүен әйткән. Әмма анда ДНР башлыгы Д.Пушилин, «Талибан» (Россиядә «террорчыл оешма» дип танылган) делегациясе кебекләр дә булган. Шуңа да карамастан, форум кысаларында җәмгысе 5,6 триллион сумлык икътисади килешүләр имзаланган. Чара үзе икътисади максатлы саналса да, игътибарны аның кайбер сәяси нәтиҗәләре дә җәлеп итә. Әлбәттә инде, мәгълүмат чараларында төп вакыйга итеп, Россия президенты В.Путинның пленар утырышта ясаган чыгышы һәм аның сорауларга биргән җаваплары күрсәтелде. Чыгышның исә шактый өлеше илнең икътисади үсеш проблемаларына багышланган. Россиягә каршы кертелгән катгый санкцияләргә карамастан, ул илдә икътисади хәлнең әкренләп нормага керүе, 2022 елда бюджет 3 триллион сум профицит белән үтәләчәге турында белдерде, чикләүләр исә Көнбатышның үзенә дә зыян салуы турында искәртте. Бүген дөньяда күзәтелә торган аяныч хәлләрне В.Путин G7 илләре инде күптәннән үткәреп килгән җавапсызлык сәясәте белән аңлатты.

Сәясәттәге кискен хәлләргә килгәндә, Россия президенты аларны салкын сугыштан соң АКШ үзен Алланың Җирдәге илчесе итеп тоюынnan күрә. Европа Берлеген исә ул үзенең сәяси суверенлыгын инде тәмам югалтып баруда да гаепли һәм мондый хәл анда радикализмның артуына, ә алга таба элиталар алышынуына да китерергә мөмкин, дип саный. Президент фикеренчә, махсус операция Көнбатыш өчен бүген бөтен бәлаләрне Россиягә аудару мөмкинлеге бирә торган «коткару бөяге» хезмәтен дә үти. Әмма В.Путинның ПМЭФ аша читләргә дә ишеттерергә теләгән уй-ниятләре хәтта форумда канашучыларда да кайнар яклау тапмады кебек. Либераль икътисад доктринасы илдә гамәлдә кала, ә хәзерге режим шартларында ул гамәлгә ашырыла алмый.

Фоат УРАЗАЙ.

Киңәшкә колак сал!

Табиб Риту Салуджа-Шарма корсактагы майдан диета тотып кына котылып була дип саный. Эксперт әйтүенчә, висцераль май бил турысында тупланса да, бу чеметеп алырлык май түгел, ул тирәндәрәк ята һәм корсак куышлыгындагы әгъзаларны каплый. Максат куеп, нәкъ менә шуңардан котылып булмый, әмма аны организмдагы майның гомуми нисбәтен киметеп азайтырга мөмкин. Иң уңышлы юл – сәламәт ризык белән туклану: җиләк-җимеш һәм яшелчәне мөмкин кадәр күбрәк ашап, зыянлы ризыктан баш тарту зарур. Мондый диета авырлыкны киметеп кенә калмаячак, туклыклы матдәләр белән тәэмин итәчәк, хроник чирләр башлану куркынычын киметәчәк һәм энергияне арттырачак. Салуджа-Шарма көненә 25-30 грамм клетчатка (азык җепселләре) ашарга киңәш итә, мәсәлән, ризыкка җиләк, фасоль яки ясмык өстәү яхшы. Клетчатка туклык хисен озак саклый, организмда инсулин микъдары тирбәлешен, шулай ук шикәр һәм холестерин күләмен киметә һәм эчәклек микрофлорасын җайга сала. Табиб ябыгырга теләүчеләргә шикәрдән бөтенләй баш тартырга киңәш итә: башта бик кыенга туры килсә дә, бераз вакыттан соң организм күнегәчәк. Баллы ашыйсы килгәндә, җиләк-җимеш ашап куярга, бер стакан су эчәргә яки кайнар душта коенып чыгарга кирәк. Салуджа-Шарма тәүлегенә өч тапкыр ашарга, крекер, печенье, чипслардан баш тартырга өнди: тәлинкәдәге ризыкның яртысы җиләк-җимеш һәм яшелчәдән, чиреге үсемлек аксымыннан гыйбарәт, чиреге көрпәсеннән чистартылмый тарттырылган он яки ярмадан әзерләнгән булырга тиеш. Чыннан да ябыгасың килсә, кичке аштан соң иртәнгә кадәр бернәрсә дә ашамаска күнегү мәслихәт. Көненә 30-60 минут тиз-тиз җәяү йөрү исә матдәләр алмашын җайга сала, майны яндыра, стрессны киметә, кәефне күтәрә, йокыны яхшырта.

(“Eat This, Not That”).

Ялгызлыкка түзеп буламы?

Мөгаен, безнең һәрберебезнең кайвакыт берьялгызы каласы, бүлмәгә бикләнеп, телефон белән компьютерны сүндереп, бөтен нәрсәдән һәм бөтен кешедән ял итәсе килгән чаклар буладыр. Британиянең Channel 5 каналы теләүчеләргә шундый мөмкинлек бирергә һәм сынау үткәрергә булган – алар биш көнгә бер кешелек камераларга ябылган. Аларга теләгән кадәр ризык бирелгән, караватта теләсә күпме аунарга, үзләре белән электроникасыз тагын өч әйбер алырга рөхсәт ителгән. Биш кешенең берсе – 28 яшьлек шәфкать туташы Шермейн ябык бүлмәдә дүрт сәгать кенә түзә алган. Икенчесе – телевидениедә эшләүче Джордж – бер тәүлектән соң сынаудан баш тарткан. Аның көн белән төнне аера алмавына ачуы чыккан, бераздан ул бүлмәдәге лампаларга кычкыра башлаган, тагын берничә сәгатькә ялгыз калса, акылдан язудан курыккан. 36 яшьлек Сара биш көн чыдаган, тик ул бик каты нервланган, курыккан, күңеле болганган. Оештыручылар үзләре, сәламәтлеге өчен кайгырып, Сара өчен сынауны туктатырга теләгән, әмма ул, бөтен куркуларын җиңеп, ахырга кадәр түзгән. Йоркширдан 28 яшьлек Ллойд, социаль челтәрләрсез яши алмый башлагач, куркуга төшкән һәм смартфонын күрмәс өчен әлеге сынауга ризалашкан. Ялгызына ничек кенә күңелсез булса да, егет түзгән, ул күп вакытын камералар белән сөйләшеп үткәргән. Экспериментта үзен сынап карар өчен катнашкан блогер Люси исә ялгызлыкны шактый җиңел кичергән, чөнки рәхәтләнеп рәсем ясаган. Яраткан эше белән шөгыльләнгәч, вакытның үткәнен сизми дә калган.

(“Интересно.cc”).



Вашингтон, Авраам Линкольн сыны.

Лондон, Биг-Бен сәгате.

Париж, Эйфель манарасы.

Афина, Акрополь.

Нью-Йорк, Азатлык сыны.

Рио-де-Жанейро, Ярлыкаучы Христос сыны.

Чиста булсын, балкып торсын!

Дөньяда һәркемгә таныш һәйкәлләр бар. Көн саен аларны күрергә (һәм тотып та карарга) дип меңләгән турист килә. Шунлыктан, ничек кенә зур булса да, аларны әледән-әле чистарту зарур. Мәсәлән, АКШ тагы Линкольн сынын елына ике тапкыр куәтле шланглардан су сиптереп юалар, колак эчләрен мамык уралган таяк белән чистарталар. Лондондагы Биг-Бен сәгатенең циферблатын дүрт альпинисттан торган махсус команда биш елга бер тапкыр чистарта, сәгатьне бу вакытта да туктатмыйлар – туристлар рәхәтләнеп күзәтә ала. Париждагы Эйфель манарасын гел җыештырып тормасалар, ул тиз арада гигант чүплеккә әйләнер иде, кырыс каравылчылар да туристларны күз уңыннан җибәрми. Елына бер тапкыр манараны яхшылап җыештыралар, моңа 10 мең шешә чистарткыч матдә, 4 тонна губка һәм 25 мең чүп капчыгы китә. Акропольдәге сыннарга химия белән зыян китермәс һәм бу гүзәллекне киләчәк буыннарга да саклап калу өчен, 2008 елда галимнәр чистартуның 40 лап вариантыннан иң югары технологияле инновацион ысулны – инфракызыл лазер белән ультрашәмәхә нурланыш комбинациясен сайлап алган. Тик ул сәламәтлек өчен дә бик зыянлы, шунлыктан белгечләр саклагыч костюмнан һәм көненә ике сәгать кенә эшли. Америкада 93 метрлы Азатлык сыны 1886 елдан бирле тора, үзен юып та булмый, шунлыктан аны эчке яктан гына чистарталар. Дөньяның яңа җиде могҗизасы исемлегенә кертелгән Ярлыкаучы Христос сыны Рио-де-Жанейро һәм Бразилия символы санала, аны карарга ел саен 1,8 миллион турист килә. 38 метрлы сынны су белән юу тыела, шунлыктан аны ун кеше бер ай буена бик вак ком һәм махсус силикон белән чистарта. Әлеге сынга елына уртача 4 тапкыр бик каты яшен суга, шунлыктан кителеп төшкән урыннарны тиз арада “ямап” кую өчен кирәкле таш запасы бер дә бетмәскә тиеш.

(“Die Presse”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

27 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Акыл батл».
16.30 «Татарлар». 12+
17.00 Телефильм о национальных праздниках народов Татарстана. 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Уроки истории». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Фәннур Сафин турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПРОЩАТЬСЯ НЕ БУДЕМ». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Мой милый друг Сандро».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Черные дыры. Белые пятна.
8.45 «КОРТИК».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Иннокентий Смоктуновский. Актер, которого ждали».
12.15 «Одинцово. Васильевский замок».
12.50 «На волне моей памяти».
13.30 «РОДНАЯ КРОВЬ».
15.05 К 90-летию со дня рождения Николая Некрасова. Концерт Академического оркестра русских народных инструментов.
15.50 Спектакль «Царь Фёдор Иоаннович».
19.15 Цвет времени. Павел Федотов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Режиссер Борис Равенских».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Цвет времени. Леонардо да Винчи. «Джоконда».
21.00 Гала-концерт лауреатов Международного конкурса имени С.В. Рахманинова.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.45 «ПЕРЕСУД». 16+

Сишәмбе

28 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 0.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.40 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
22.10 Телефильм о национальных праздниках народов Татарстана. 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПРОЩАТЬСЯ НЕ БУДЕМ». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Последний крестоносец Российской Империи».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Дипломатия Древней Руси».
8.45 «КОРТИК».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Авторский вечер композитора Евгения Крылатова в Колонном зале Дома Союзов».
12.25 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
12.55 Academia. Алексей Хохлов. «Умные полимеры».
13.45, 22.10 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
14.30 Пряничный домик. «Кавказский костюм».
15.05 К 90-летию со дня рождения Николая Некрасова. Артур Эйзен и Академический оркестр русских народных инструментов.
15.50 «Абрам Алиханов. Музыка космических ливней».
16.30 Спектакль «Горе от ума».
18.45 Цвет времени. Рене Магритт.
19.00 Письма из провинции. Плёс.
19.45 Главная роль.
20.05 «Режиссер Борис Равенских».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».
23.00 «Завтра не умрет никогда».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.45 «ПЕРЕСУД». 16+

Чәршәмбе

29 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бәргәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Сакладым сине күңелемдә». Гөлшат Зәйнашева турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЛАБИРИНТ ИЛЛЮЗИЙ». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Ода к радости и грусти».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Великий посол».
8.45 «КОРТИК».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Опознание, или По следам людоеда».
12.10 Цвет времени. Михаил Врубель.
12.25 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
12.55 Academia. Алексей Хохлов. «Умные полимеры».
13.45, 22.10 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
14.30 Пряничный домик. «Три свадьбы удмурта».
15.05 К 90-летию со дня рождения Николая Некрасова. Алибек Днишев и Академический оркестр русских народных инструментов.
15.50 «Роману Козаку посвящается...»
16.30 Спектакль «Женитьба».
19.00 Письма из провинции.
19.45 Главная роль.
20.05 «Режиссер Борис Равенских».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Драматургия одной судьбы».
23.00 «Завтра не умрет никогда».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.45 «ПЕРЕСУД». 16+

Пәнҗешәмбе

30 июнь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ 2». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Чёрное озеро». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЛАБИРИНТ ИЛЛЮЗИЙ». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Меганаука». 12+
15.30 «Битва ставок». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «АННА КАРЕНИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Охота на русского принца».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Хозяйка Европы».
8.45 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
8.50 «БРОНЗОВАЯ ПТИЦА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Вокруг смеха».
12.25 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
12.55 Academia. Юрий Оганесян. «Сверхтяжелые элементы».
13.45, 22.10 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
14.30 Пряничный домик. «Роза песков».
15.05 90 лет со дня рождения Николая Некрасова. Ирина Архипова и Академический оркестр русских народных инструментов.
15.50 «Белая студия».
16.30 Спектакль «Свадьба Кречинского».
19.00 Письма из провинции.
19.45 Главная роль.
20.05 «Режиссер Борис Равенских».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Энигма. Артём Дервоед».
23.00 «Завтра не умрет никогда».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ». 16+
21.45 «ПЕРЕСУД». 16+

Җомга

1 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Мәсгудә Шәмсетдинова турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ОПУСТЕВШИЙ ГОРОД». 16+
15.10 «Не факт». 12+
15.40 «Битва оружейников». 12+
16.25 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.25 «The Beatles в Индии». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЭКИПАЖ». 6+
23.50 «Немецкая Украина. От гетмана до гауляйтера». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.00 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Путь на Голгофу».
7.35 Легенды мирового кино.
8.05 Иностранное дело. «Дипломатия побед и поражений».
8.50 «БРОНЗОВАЯ ПТИЦА».
10.15 «КАМЕННЫЙ ЦВЕТОК. УРАЛЬСКИЙ СКАЗ».
11.40 «Мой дом - моя слабость».
12.25 «Князь Потёмкин. Свет и тени».
12.55 Academia. Юрий Оганесян. «Сверхтяжелые элементы».
13.45, 22.10 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
14.30 Пряничный домик. «Сладкая работа».
15.05 К 90-летию со дня рождения Николая Некрасова. Евгений Нестеренко и Академический оркестр русских народных инструментов.
15.50 «Энигма. Артём Дервоед».
16.30 Спектакль «Мёртвые души».
19.00 Письма из провинции.
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Тайна ожившего портрета».
21.00 «Первые в мире».
21.15 Линия жизни. Марина Лошак.
23.20 «В КЕЙПТАУНСКОМ ПОРТУ...»

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
11.05 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «Новые русские сенсации». 16+
21.50 «Концерт памяти Михаила Круга. 60».
23.50 «ОТПУСК». 16+

Шимбә

2 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Күңелем минем...» Җәвит Шакировның юбилей кичәсе. 6+
17.00 Спектакль «Алты кызга бер кияү». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Ватандашлар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ТУР ДЕ ШАНС». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Мәхәббәтем - җыр минем». Эмиль Җәлалетдинов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 Зөфәр Хәйретдиновның юбилей концерты. 6+
22.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Меганаука». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Наша марка 2». 12+
8.15 «ЛЮТЫЙ 2». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЕЛЛЬ И СЕБАСТЬЯН». 6+
14.45 «Хроника безвременья». 12+
15.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОН И ОНА». 16+
22.50 «КЛАН КЕННЕДИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
8.35 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 К 65-летию Александры Яковлевой. «Жизнь с чистого листа». 12+
11.00, 12.15 «Видели видео?»
14.00, 15.15 «ЭКИПАЖ». 12+
17.10 «Украина. Когда открываются глаза». 16+
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «СТЕНДАПЕР ПО ЖИЗНИ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.40 «Я БОЛЬШЕ НЕ БОЮСЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НЕРОДНАЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.25 «ПОРТРЕТ МАДЕМУАЗЕЛЬ ТАРЖИ».
9.35 «Обыкновенный концерт».
10.05 «БЛИСТАЮЩИЙ МИР».
11.30 Черные дыры. Белые пятна.
12.15 Музыкальные усадьбы. «Малиновый звон. Михаил Глинка».
12.45 «Дикая природа Баварии».
13.40 Елена Образцова, Владимир Атлантов, Юрий Мазурок в опере Ж. Бизе «Кармен». Постановка Ростислава Захарова.
16.15 Больше, чем любовь.
16.55 «Энциклопедия загадок».
17.25 «ДЯДЮШКИН СОН».
18.50 Искатели. «Нижегородская тайна Леонардо да Винчи».
19.40 «ЛОУРЕНС АРАВИЙСКИЙ».
23.10 Чик Кориа на фестивале Джаз во Вьенне.

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Простые секреты». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «БЛИЗНЕЦ». 12+
23.20 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

3 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йолдызлар сәламе». 6+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Наша Республика - Наше дело». 12+
12.00, 19.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.00 Спектакль «Ханума». 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.30 «Әдәби хәзинә». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
22.00 «ПРИТВОРИСЬ МОИМ ПАРНЕМ». 16+
23.35 «ВЕСЁЛЫЕ РЕБЯТА».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Галиҗәнап шагыйрь». Гамил Афзалның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә. 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.30 «Татар сүзе» нәфис сүз бәйгесенең гала-концерты. 6+
16.00 Н.Җиһанов исемендәге «Мирас» татар музыкасы фестивале. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 Илсөя Бәдретдинова концерты. 12+
22.00 Спектакль «Ай тотылган төндә». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 14.45 «Вместе по России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Эпидемия». 12+
8.30 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЕЛЛЬ И СЕБАСТЬЯН: ПРИКЛЮЧЕНИЯ ПРОДОЛЖАЮТСЯ». 6+
15.15 «ЛЮТЫЙ 2». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛИНКОЛЬН ДЛЯ АДВОКАТА». 16+
23.00 «МОСКОВСКИЕ СУМЕРКИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.15, 6.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
7.05 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.15 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Голос из прошлого. Холодная война Никиты Хрущева». 16+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
13.20, 15.15 «ВОСКРЕСЕНСКИЙ». 16+
18.25 «Джентльмены удачи». Все оттенки Серого». 12+
19.20 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ». 12+
21.00 «Время».
22.35 «БЕГСТВО МИСТЕРА МАК-КИНЛИ». 12+

«РОССИЯ»

5.35 «БУКЕТ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.40 «Я БОЛЬШЕ НЕ БОЮСЬ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.00 Мультфильмы.
7.50, 23.45 «СЫН».
10.10 «Обыкновенный концерт».
10.35 «ДЯДЮШКИН СОН».
12.00 Больше, чем любовь.
12.40 Письма из провинции.
13.10 Диалоги о животных.
13.50 «Коллекция».
14.25 «УДИВИТЕЛЬНЫЙ МАЛЬЧИК».
15.50 «Валентин Никулин. Каждый выбирает для себя».
16.30 «Домашние помощники XXI века».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Храм».
18.30 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «БЛИСТАЮЩИЙ МИР».
21.40 Большая опера.

«НТВ»

5.10 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Простые секреты». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.40 «Основано на реальных событиях». 16+
22.30 «Маска». 12+

ДҮРТЕНЧЕ КАТТА ВӘХШӘТ

Узган ел шаукымлы җинаятьләргә аеруча бай булды. Аларның беренчесе яңа ел бәйрәмнәре арасында ук теркәлде. 7 гыйнвар кичендә Казанның Маршал Чуйков урамындагы йортта сөйгәне тарафыннан кире кагылган егет кызны һәм аның әти-әнисен юк итте, пычак чәнчеп һәм 4 нче каттагы балконнан ташланып үзе дә үлмәкче булды. Бусы хак, шулай да адәм баласының әлеге ерткычлыгы бик күп сораулар, төрледән-төрле фаразлар, капма-каршы фикерләр тудырды. Һәм гади кешеләрдә, мәгълүмат чараларында гына да түгел. Ягъни тикшерү органнары, прокуратура чыгарган рәсми нәтиҗәләрне яклау ягы кире какты.

4 нче каттагы ыгы-зыгы сәгать кичке 10 тулганда башлана. Шалтыратучы булгач, Миләүшә ишекне ача, әмма чырылдап кычкырган хатын-кыз тавышы, шау-шуны ишетеп яңадан яба, тиз генә телефонын алып килә, чөнки хәвеф-хәтәр барын, полициягә хәбәр итәргә кирәк булуын сизенә. Кабат тамбурга чыккач та, подъезд мәйданчыгында яткан, канга баткан күршесе Фәридәне күрә. Янәшә торактагы өлкән яшьтәге Галина белән дә охшаш хәл килеп чыга, ул ишеген ачкач та, каршында коточкыч куяфәтле күршесе Рафаэль сыерылып төшә һәм бусаганың яртылаш эчке ягына ава.

Котлары алынган хатын-кызлар «112» коткару хезмәтенә шалтырата, шул рәвешле полиция экипажларына Чуйков урамында «пычаклы һөҗүм» дигән хәбәр ишетелә. 10-15 минуттан дүртенче катка биш погонлы кеше күтәрелә, аларның икесе тиз генә кире урамга йөгерә, чөнки рациядән шул ук йорт балконыннан ир кеше егылып төшү турында тагын бер хәбәр килә. Ләкин карлы-бозлы җирдә чалкан ятучы яшь егет янына ЮХИДИ экипажы килеп туктаган була инде. Шул арада бер-бер артлы өч ашыгыч ярдәм машинасы туктый, аларның берсе урамдагы күкрәгә, муенында кан саркып торган яралары күренеп торган, ярым өнсез хәлдәге ир-атны якындагы 7 нче сырхауханәгә алып китә. Соңрак аның 1998 елда туган Рөстәм Мөхәммәдуллин икәне мәгълүм булыр.

Югарыда калган полиция хезмәткәрләренә күрше апалар сыкранып, аз-маз кыймылдап идәндә яткан ир белән хатынның 18 яшьлек кызлары да булуын әйткәч, аларның икесе 50 нче фатирның, аяк киемнәре таралган һәм кан таплары күренеп торган коридорына кереп, каршыдагы ишекне ачмакчы булалар. Ул әчтән терәтелгән булып чыга, җыелма өстәлне этеп ишекне ачкач та тагын бер тетрәндергеч күренеш ачыла – идәндә кан эчендәге яшь кыз, аның янәшәсендә зур гына кара пычак, ак якалы ирләр курткасы ауный, һәр җирдә, хәтта ачык тәрәзә төбендә кан. Камилә сорауларга җавап бирә алмый, ыңгыраша, тиздән полиция хезмәткәрләре күз алдында соңгы сулышын ала. Аның әти-әнисе дә ашыгыч ярдәм табибләре килеп җиткәндә җан биргән була инде.

Суд-медицина экспертизасы 1958 елгы Рафаэль Төхвәтуллинда – 9, аның 1961 елда туган хәләл җефете Фәридә Хәмәтҗановада – 6, аларның 18 яшьлек кызы Камиләдә 13 яра булуын, аларның күпчелеге күкрәк, корсак тирәсенә ясалып, эчке әгъзаларны җәрәхәтләгәнгә күрә, исән калу мөмкинлеге калдырылмавын белдерә. Тикшерү комитеты ике һәм аннан да күбрәк кеше үтерү очрагы буенча җинаять эше кузгата.

Тәрәзәдән ташланган Р.Мөхәммәдуллин авыр хәлдә була. Тикшерү материалларында анда 9 җәрәхәт булуы, аларның үпкәләр, бавыр, эчәкләргә зыян салуы, шулай ук колак янында, муен һәм уң кул учында киселгән яралар бар дип күрсәтелә. Өстәвенә, югарыдан төшеп бәрелү нәтиҗәсендә оча сөяге дә чәрдәкләнә. Кыскасы, аны коткару өчен табибләргә шактый тырышырга туры килә. Үтерүченең шушы егет икәне шик уятмый, шуңа күрә сырхауханәдә дә аны полиция хезмәткәрләре саклый, ә аякка баскач, Мәскәүдәге ябык рәвештәге психиатрия клиникасына экспертизага җибәрелә. Анда озак кына тикшергәннән соң, белгечләр комиссиясе, иң беренче чиратта, яклау ягы өчен көтелмәгән нәтиҗә ясый, кыскасы, бер мизгелдә өч кеше җанын кыеп үзен үтерергә керешкән егет рухи яктан камил, җинаять кылганда акылында булган дип белдерелә.

Р.Мөхәммәдуллин тәртипле гаиләдә туып-үсә, мәктәпне тәмамлагач, урта техник белем ала, игезәк бертуганы белән бергә армиядә хезмәт итеп кайта да, берникадәр вакыттан авиация берләшмәсенә эшкә урнаша, белгечлеге буенча югары уку йортына керә. Үрнәк егетнең әлеге вәхшилеге гаҗәпкә калдыра. Ләкин психиатрлар белешмәсендә аның холык-фигылендәге кайбер кимчелекләр, әйтик, читкә этәрелү, кире кагылу ише күңелсезлекләрне артык авыр кичерүе дә күрсәтелә, ләкин болар гадиләштереп әйткәндә, йөгәннән ычкынырлык дәрәҗәдә үк түгел дип исәпләнә.

Җинаять эшендә зарар күрүчеләр итеп 37 яшьлек Артур Хәмәтҗанов һәм 1980 елгы Гүзәл Төхвәтуллина билгеләнә. Болар мәрхүм Рафаэль белән Фәридәнең башка никахларыннан тапкан, әмма аралашып, туганнарча яшәгән балалары. Хәвеф буласы көнне әтисе кызына ватсап аша хәерле иртә теләп, котлау җибәрә, икенче көнне исә чит илдән Казан аэропортына кайтып җитүе белән Гүзәлгә тетрәндергеч хәбәрне җиткерәләр. Артурның малае әби-бабай һәм апасы янында еш кунак була.

Ошбу гаилә турында, гомумән, бер начар сүз дә әйтүче юк. Рафаэль торак-коммуналь хуҗалыгында эшләп пенсиягә чыккан, 3 нче төркем инвалидлык алган, бераз аксап йөргән. Фәридә ханым лаеклы ялда булса да, редакциядә («Мәдәни җомга» газетасы редакциясе) сәркатип булып эшләгән хөрмәтле кеше. Туган-тумача 2002 елгы Камиләне татар гореф-гадәтләре нигезендә тыйнак итеп тәрбияләүләрен әйтәләр.

Инновация университетының 1 нче курсында укучы кыз белән яңа армиядән кайткан егет 2020 елның август ае башында социаль челтәрдә танышып, очраша башлыйлар. Әти-әнисе, бертуганы Рөстәмнең шатланып йөрүен әйтә. Әлеге дуслыкны ике як ата-аналар да хуплый, ләкин башлангыч чорда дип өстәргә туры килә. Чөнки көзгә таба аралар суына, ноябрь уртасында яшьләр бик каты әрләшеп аерылышалар.

Монысын егетнең көнләшүенә сылтарга кирәктер. Ләкин моның өчен дә сәбәп кирәк бит әле. Кайбер интернет-басмаларда кызның тагын бер егете булуга басым ясалган язмалар да күренде. Чыннан да, Камилә Искәндәр атлы егет белән аралаша. Әлбәттә, кызны яманлап Рөстәмне аклардай сәбәп була алмый бу. Шулай да моның гашыйк егетне чыгырдан чыгарырга этәргеч бирүен кире кагып булмастыр. Р.Мөхәммәдуллинның әйтүенчә, Камилә ошбу егеттән килгән язмаларны сөртергә кушканны тыңламый, соңрак, Искәндәр белән күрешәсем бар дип, аның белән очрашудан баш тарта. Ноябрь аендагы низаг шуннан соң чыга да инде.

Искәндәр исә якын мөнәсәбәттә булуларын кире кага, юкса, Р.Мөхәммәдуллинның эзәрлекләүләренә чик куяр идем, ди. 7 гыйнвар кичендә бик озаклап телефоннан сөйләшәләр, аннан соң да Телеграмм аша хәбәрләр җибәрешәләр. Ошбу аралашу Рөстәм алдында барган һәм аның котырынып китүенә сәбәп булган кебек. Чөнки нәкъ шул вакытта шаукым күтәрелә, «112» һәм башка хезмәтләргә хәвефле хәбәрләр килә башлый.

Аерылышу егетнең төшенкелеккә бирелеп, үз эченә бикләнүенә китерә. Монысын ата-ана, агайнесе дә күрә. Ләкин өметен өзми, Камиләнең балачак дусты Валерия киңәшен тотып чәчәк, конфет алып очрашуларга баргалый, бер тапкыр өлкәннәрнең өйләренә кертмәүләрен дә искә ала ул. Ата-анасы кызларының аннан куркып өйдә утыруларын әйтәләр. Әлбәттә, алар кызларын яклый, яшьләрнең аталары да телефон буенча сөйләшәләр, әлбәттә, дустанә әңгәмә булмый бу. Аратирә очрашсалар да, кыз егеткә чынлыкта ачык чырай күрсәтми инде.

Күрәсең, холкындагы психиатрлар күрсәткән үзенчәлекләре йөрткәндер, чынлыкта, кире кагылган егет бирешергә җыенмый. 5 гыйнварда Камиләне абыйсының улы белән урамда очрата, бергәләп малайны өенә озатып куйгач, тагын гафу үтенә. 7 гыйнварда, әйтүенчә, ялгызы сөйгәне белән бергә йөргән «кадерле» урыннарны буйлый, мәсәлән, Җиңү паркында йөри, ахыр читтә, мәхшәр чыгачак йортка таба китә.

Тикшерү комитеты ясаган нәтиҗәләргә кыскача тукталсак, 7 гыйнвар кичендә үзе белән пычак алып, кыз өенә килгән, хуҗалар рөхсәте белән эчкә узган, көнчелек аркасында, үч алу ниятеннән алдан ир-атны, аннан соң хатын-кызларны чәнчегән, шул ук корал белән үз гомерен кисәргә тотынган, соңгы теләгенә ирешә алмаган, чөнки вакытында медицина ярдәме күрсәтелгән. Шулай итеп, ике һәм аннан да күбрәк кешене аңлы рәвештә үтерүдә рәсми гаепләү белдерелә аңа.

Р.Мөхәммәдуллин күрсәтмәләре үзенчәлекле. Әйтүенчә, кыз йорты янына үзе дә сизмәстән килә ул, киоск ябык булганга, чәчәкләр алмый, хуҗа: «Нәрсә кирәк?» – дип тупас каршыласа да керергә рөхсәт бирә, үз бүлмәсендә әнисе артында басып торган сөйгәнен күрә. Шуннан соң нәрсә булганын хәтерләмим, әллә судда, әллә уңда кара шәүләләр булды, сырхауханәдә генә аңыма килдем ди.

Тәҗрибәле адвокатлар суд карамагына тапшырылган рәсми гаепләү белән килешмиләр. Мәсәлән, гаепләнүченең пычакны үзе белән алып килүе кире кагыла. Чыннан да, әлеге нәтиҗә ике зарар күрүче, мәрхүмнәрнең ике туганының сабы гына түгел, тоташтан кара пычакны күргәнебез юк дип белдерүенә корыла. Әллә нигә бер килгән кунаклар фатирдагы бар әйберне дә барлап бетерә алмый бит инде. Шул ук вакытта полиция хезмәткәрләре залда тәртип бозылмаган, бары тик сервантның бер тартмасының ишеге ачык, янәшәдә кашык, чәнечке, пычаклар сибелеп ята иде диләр. Бу инде кара пычакның шуннан алынуына ишарәли һәм кем алган дигән сорау тудыра.

Адвокатлар исә кеше үзенә-үзе бу кадәр җәрәхәт ясый алмый диләр, аның учындагы киселгән урынны да һөҗүмнән саклану нәтиҗәсе дигән фикерне алга сөрәләр. Ягъни гаепне читкә этәрергә тырышалар.

Әлбәттә, яклаучылар төп максатны амнезия, ягъни хөкем ителүченең өч кешегә тән җәрәхәтләре ясавын хәтерләмим дип баруына юнәлтәләр, ягъни ул аффект, үз-үзен белештермәгән хәлдә булган дип танытырга тырышалар. Тикшерү органнары бу мөһим сорауны психиатрларга алдан ук бирә. Җавапны гадиләштереп китерик: Р.Мөхәммәдуллин саташу, галлюцинация хәлендә булмаган, ә амнезия, оныту мәсьәләсе уйлап чыгарылган диелә анда, ягъни өйгә кергәч кенә хәтер югалырга тиеш түгел дип санала. Бу инде – җинаять аңлы рәвештә кылынган дигән сүз.

Җинаять эше Татарстан Югары судында карала башлады. Ләкин хөкем утырышлары озакка сузылачак әле.

Наил ВАХИТОВ.

ТАТАР КУРЧАГЫНА нәрсә җитми?

«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында куелган «Русалочка» спектакле кулга каләм алып, кайбер фикерләр белән уртаклашырга этәрде. Г.Х.Андерсен әкияте һәркемгә бала чактан яхшы таныш, спектакль белән шаккатырып булмый, дияргә мөмкиннәр. Әмма тамашачы премьерада бу әкияткә яңа күз белән карагандыр.

Залга кергәнче фойеда ук ишетелер-ишетелмәс килгән диңгез тавышы спектакльгә әзерли. Режиссер Светлана Озерская инсценировканы да үзе эшләгән. Әкият су буенда кер чайкаучы кызлар авызыннан бәян ителә. Чырык-чырык килеп сөйләгән вакытта алар үзләре үк су кызлары – русалкалар роленә кергәнен сизми дә каласың. Вакыйгалар тыгыз, спектакль исә барлыюклы бер сәгать дәвам итә. Актерлар үзләре сәхнәдә күренү өстенә, курчак та уйната. Кайбер вакыйгалар анимация аркылы да тасвирлана. Курчакларны һәм сәхнә бизәлешләрен бөртекләп, нечкәләп эшләмәсәләр дә, спектакльдә һәрнәрсә бик күркәм. Аерым детальләргә кирәгеннән артык әһәмият бирмәү тамашаның өслүбен ахыргача сакларга мөмкинлек биргән һәм ул бербөтен булып күз алдына килеп баса. Спектакльнең темасы гаять авыр булуын игътибарга алганда, рәссам Е.Спиридонов, анимация режиссеры Е.Дегтярева, ут көйләүче оста А. Кузнецова һәм композитор К. Федорованың уңышка ирешүен билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Вакыйгаларның башлыча диңгездә барганын онытмыйк. Диңгезне тамашачыга ничек итеп күрсәтергә соң? Өстәвенә, спектакль театрның кечкенә залында түгел, зур сәхнәдә бара. Авырлыкка да карамастан, сәхнәдә диңгезнең төрле сурәтләрен – кышкы диңгезне, давыл чыккан вакытны, кояшлы, матур чагын күреп шаккатарлык иде. Кер чайкаучы кызлар – Ю.Василишина, И.Гайнуллина, Е.Кладова, А.Жукова, Е. Дмитриева ничек чырык-чырык килеп әкият сөйләгән булса, тулаем тамашага әнә шундый җиңеллек хас. Юкса вакыйгалар да бик күп. Давыл вакытында корабның батуы, патша улының русалкага гашыйк булуы, русалканың диңгез пәриенә барып тавышын калдыру бәрабәренә аяклы булуы, русалканы коткарыр өчен, сеңелләренең шул ук диңгез пәриенә чәчләрен калдыру бәрабәренә хәнҗәр юнәтүләре, патша сараенда туй һ. б. Шул арада диңгез пәрие курчагы куркыныч булып күз алдына килеп баса (А. Хайсарова). Әкияти су асты дөньясын матур итеп сурәтләргә дә осталыклары җиткән (Л.Пасынкова). Әллә гел хатын-кызлар иҗат иткәнгә, спектакль бик нечкә хисле килеп чыккан.

Кесә телефоннары, интернет заманында да кызыклы тамашалар сәхнәләштереп була икән бит. Үткән гасырның 70 нче елларындагы курчак театры чаралары белән татар спектакльләрен куйгач, әлбәттә, татарчаны карарга йөрмиләр, дип сыкранырга гына кала. Татар әсәрләрен куйганда, режиссерларга ярату җитенкерәми икән. Сөю-сәгадәтле көндәлек тормыш, «Русалка» спектаклендәге кебек тере күренешләр ярала. Сәхнә «тере» булып, андагы сурәтләү чаралары заман рухына туры килә икән, татар тамашаларына да ябырылып йөриячәкләр.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазлаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратыгыз

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 24.06.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2730 данә

Заказ 2758

16+